РАВИЛ ШАММАС

Гомер учагының кузлары



ЛИСТОК СРОКА ВОЗВРАТА

КНИГА ДОЛЖНА БЫТЬ
ВОЗВРАЩЕНА НЕ ПОЗЖЕ
УКАЗАННОГО ЗДЕСЬ СРОКА

Колич. пред. выдач ....

28/12 - ТАС



Жырым - сиңа
Равил Шаммас

С(Башк)
Ш20

РАВИЛ ШАММАС

Гомер агымының күзләре

Шигырьләр, поэмалар, балладалар

Уфа
«Китап»
1999

ББК 84 Баш
Ш 29

НБ РБ
0000171277

Шаммас Равил

Гомер учагымның кузлары. Шигырьләр, поэмалар, балладалар. — Уфа: Башкортстан «Китап» нәшрияты, 1999. — 192 бит.

Җыентыкка танылган шагыйрьнең лирик, публицистик һәм фәлсәфи, сатирик һәм юмористик шигырьләре, поэма һәм балладалары тупланды. Бу аның татар телендә чыккан беренче китабы, һәм ул поэзия сөючеләрне битараф калдырмас, дип ышанабыз.

ТП — 97

ISBN 5-295-02286-2

147299

© Шаммас Равил, 1999

Национальная библиотека
... Заки Валиди

Укучыларыма

Балачактан шигырьләр язып, туган районым Стәрлебашта мәктәптә һәм гәзиттә эшләгәндә аларны республика матбугатында бастырып торсам да, әдәбиятка поэма белән килеп кердем шикелле. Моннан утыз биш еллар элек, «Кызыл таң»ның журналисты чагымда, «Утлар» исемле поэма язып, «Ағиҙел» («Әҙәби Башҡортостан») журналына бирдем. Аны укып чыкканнар да икеләнебрәк утыралар икән. «Поэма ярыйсы. Тик әлегә бу яшь авторның шигырьләр шәлкемен генә әзерләргә кирәктер. Поэма кадәр поэма...» — дигән сүзләр ишетелә. Баш мөхәррир урынбасары Вәзих Исхаков баса да: «Әйдәгез, поэманы бергәләп кычкырып укып чыгабыз», — ди. Һәм укыйлар. «Бирергә» дигән карарга киленә һәм минем күләмле әсәрем журналга кереп тә китә.

Бераз соңрак Башкортстан китап нәшриятында әдәби совет утырышы чакырыла: «Башкорт поэзиясе антологиясе»нә керәчәк авторларның исемлеген карыйлар. Анда инде иң абруйлы әдипләр, галимнәр катнаша һәм «Олы

китап»ка бик танылганнар, Язучылар берлеге әгъзасы булганнар гына кертелә. Исемлектә әлегә әгъза итеп алынмаган берничә яшь автор да бар икән. Минем хакта сүз чыккач: «Аның «Утлар» поэмасы бар. Шуның өчен генә дә ул керергә тиеш», — диган сүз әйтелә, һәм мәсьәлә уңай хәл ителә.

«Утлар»дан соң күп поэмаларым басылды, Уфада һәм Мәскәүдә унбишләп китабым чыкты. Ә шулай да йөрәгемдә ялкын дөрләткән, илебезгә авыр сынау булган сугыш чорында әниләрнең, дөнья йөген иңнәренә салып, батырлыкка омтылуы, көчле рухлы булып калуы сурәтләнгән «Утлар»ым бик кадерле миңа. Татар телендә чыккан бу китабымның поэмалар бүлеген шуның белән ачып җибәрәм.

Җыентыкка әсәрләремне сайлаганда, «бармакның кайсын тешләсәң дә, авырта», дисәләр дә, укучы күңеленә якынрак булырдайларын алырга тырыштым: алар миннән нәкъ шуны көтә, дигән ышаныч белән хәзерләдем.

Гомер башлыча Уфада үтте. Башкортстан китап нәшриятында, Республика тынычлык комитетында, «Һәнәк» журналы редакциясендә, Язучылар берлеге аппаратында эшләгәндә дә хезмәтем гел иҗат белән бергә үрелеп барды. Аллага шөкер, «шигъри утлар»ым сүнмәде, сүрелмәде.

Кадерле укучыларым! Шулар сезнең күңелегезне дә җылытса, уйландырса, моңландырса, мәхәббәт лирикам дәртләндерсә, сатира һәм юморым елмайтса икән.

Автор

ШАГЫЙРЬ-ЙӨРӘК САЙРАМАСА

Бер минут

Бер карасаң, кеше гомерендә
Нәрсә генә инде бер минут?
Ә уйласаң, шушы бер минутта
Кеше бар дөньяда, кеше — юк.

Кайберәүләр җирнең күкрәгендә
Йөзәр еллар яшәп китәләр,
Шул йөз елның бары минутында
Гасырлардан гасырларга барыр
Олы иҗат бүләк итәләр.

Бер минутлык очрашулар була,
Күзгә-күз караша бер минут.
Шул минутта күчеп йөрәкләргә,
Гомер буе дөрләп йөри ут.

Шул бер минут сине бәхетле итә,
Я бәхетсез итә гомергә.

Шул бер минут җирне ямьгә күмә,
Әйләндерә ала күмергә.

Бер карасаң, кеше гомерендә
Нәрсә генә инде бер минут?
Ә уйласаң, гомер үзе бер ут,
Янды, сүнде, —
Гомер — бер минут.

Яшәү кадере

Без, адәми затлар, кызык инде:
Бер яшибез, дибез, тормышта —
Кырык үлеп, кырык тереләбез
Һәрбер ялгышлыкта, борылышта.

Бер гөрләшеп утыру — бер гомер, дип,
Куанышып канат кагабыз.
Бар дөньяны онытып, иртәгәгә
Мәңге яшәр сыман багабыз.

Бер яшибез, дибез, — дөрес түгел.
Мең яшибез, — кадерен белсәкче.
Изгелекләр эшләп бер-беребезгә,
Бер алманы бишкә бүлсәкче.

Беребез абынганда икенчебез
Кулын сузып тартып алсачы,
Мең яшәүгә торыр гомеребез
Бер шәм булып янып калсачы.

Бер шәм булып — якты бер шәм булып
Кешеләргә юллар ярсачы.
Синнән соңгылар да һәрбер көнен
Мең яшәүгә тиңли алсачы.

Без, адәми затлар, кызык инде:
Бер яшибез, дибез, мең яшәп.
Яшәү белән үлем бер үк юлда,
Уңыш белән ялгыш янәшә.

Һәрбер сулыш — яшәү. Мең яшибез,
Яшәү кадерләрен белсәкче.
Тик изгелек теләп бер-беребезгә,
Бер алманы бишкә бүлсәкче.

Ак сөлге

Сабый чакта иңнәреңә
Әнкәң ак сөлге сала,
Ак бәхетләр тели-тели
Җылы куенга ала.

Бәйгедәге чабышларда
Ак сөлгеләр бирәләр.
Килен төшкән өйләргә дә
Ак сөлгеләр эләләр.

Көрәшләрдә сөлге була
Батыр ирләр билендә.
Ак сөлгеләр сөртеп ала
Маңгайларның тирен дә.

Хәтта кабергә кешене
Ак сөлгеләр төшерә:
Димәк, аклык юлдаш булган
Гомеренә, эшенә.

Иртән кояш бага сиңа
Сөлгеләр сузып, балкып.
Күрәсең, дөнья кешегә
Һәрвакыт тели аклык.

Ахры, бер теләк гомергә
Озата килә ирне:
Карайта күрмә күңелне,
Карайта күрмә Җирне.

Кадерен беләсеңме?

Тома сукыр әгәр күтмәгәндә
Күзен ачса азга, бик азга,
Ул шул минут,
Якты көнгә карап,
Сүзсез калыр иде беразга.

Әверелер иде бер рәссамга,
Җирне, күкне, дөнья төсләрен
Ул сурәтләр иде тиңе булмас
Рәсем итеп, ташып хисләре.

Ишетә калса әгәр саңгырау кеше
Җирнең моңын, гөрен, тавышын,
Онытылмаслык бер җыр итәр иде
Хисләренең бөтен агышын.

Бер могҗиза туып,
Ике кулсыз —
Куллы булса?
Улмы? Шул мәлне
Бакча итәр иде бу җирне,
Ә соңыннан,
Шатлыгыннан елап,
Назлап йөрер иде гөлләрне.

Ә син мәхрүм түгел берсеннән дә,
Бары да бар: кулың, аягың,
Күзләрең бар,
Ишетер колагың бар, —
Гүзәллеккә тулы һәр ягың.

Бары да бар, әйе, бары да бар.
Уйлаганың бармы син бераәр:
«Кадерен беләмме соң?»
Уйласаң бит,
Шул сүзләрдән йөрәк тетрәр.

Тормыш арбасы

Бу тормыш арбасы
Җилдерә, җилдерә.
Юлның үз законы —
Шартына китерә.
Кеше бит, юл булгач,
Калдырмый нәмәсен:
Арбага төялә
Тапканның һәммәсе.
Төзеге, һәйбәте
Өскәрәк салына.
Лагуны-дегете
Арткарак тагыла.

Юлның үз законы —
Туңдыра, яндыра.
Борылма үткәндә
Ташлап та калдыра.
Җырлап та барасың,
Җылап та аласың.
Ә арба тәгәри —
Барасың, барасың.

Үрләрне менәсең
Тартышып, булышып.
Юл китсә тау түбән,
Чабасың узышып.
Бик кызып барганда,

Шап җиргә күчәрең:
Сизми дә калгансың
Чәкүшкәң төшкәнен.
Юл, атың тугартып,
Үзеңне җиктерә —
Барасы җиреңә
Барыбер җиткерә.

Юл бара артыңда
Тасмадай сузылып.
Эз кала маңгайда
Сызылып, сызылып.
Үткән юл — синеке,
Яманмы, яхшымы.
Эчкән су — синеке,
Әчеме, татлымы.
Калган эз — синеке,
Такырмы, матурмы.
Артыңнан кем килер —
Куркакмы, батырмы?

Уйла гел яхшысын,
Юрама яманын.
Яхшыга юрасаң,
Яхшылык яралыр.
Әй, тормыш арбасы,
Келтердә, келтердә.
Тик барыр җиреңә
Яманлык китермә.

* * *

«Өлгерермен әле таратырга,
Куәт барда, җыям», — дип йөреп,

Матурлыкны төйнәп кулъяулыкка,
Үтеп китсә гомерең йөгереп, —

Сусап яңгыр көткән җиргә яумый,
Узып киткән җәйге болыт син.
Җирдән алган бөтен матурлыкны
Җиргә сипсәң, —
Асыл егет син.

Өмет

Тормыш бит ул, төрле чаклар була:
Ниләр генә килми кешегә —
Кайвакытта күңел җырлый, көлә,
Кайвакытта күңел өши дә, —
Ниләр генә килми кешегә.

Шундый авыр чаклар була, хәтта
Үзеңне дә килми күрәсең:
Ялгыш адымыңа үкенә биреп,
Үз-үзеңне үтереп сүгәсең, —
Үзеңне дә килми күрәсең.

Шундый чакта берәү, бер сүз әйтеп,
Күңелеңне синең эретә.
«Бетте инде!» — диеп, кул селтәгән
Өметеңне кабат терелтә, —
Өметләргә, дуслар, ни җитә!

Әнием фәрештәсе

Бүген дә әле, һай, бик кирәк
Әнинең дәресләре —
Бу тормыш «әлифбасының»
Иң тәүге хәрефләре.

Әйткән иде: «Юлларында
Фәрештәң ташламасын».
Изге теләктә озата
Һәр ана үз баласын.

Ул чак көлеп карый идем
«Фәрештә» дигәненә.
Әле инде шул сүзләре
Якынайды җаныма.

«Фәрештә» дигән сүзенә
Никадәр мәгънә сыйган:
Шул сүз кеше акылының
Бар матурлыгын җыйган.

Нишләр идең, мәхрүм булсаң
Намус дигән иманнан?
Беләм, намуслы бул, дигән —
Ул бит шуңа инанган.

Шул иманым саклаган бит
Тугрылыгымны Илгә.
Максатыма атлаганда,
Таудай йөк салып иңгә,

Шул иманым юлдаш булды,
Бүген дә миңа юлдаш.
Ул булмаса дөньялыкта
Ни күрмәс иде бу баш?

Шайтан котыртты алдарга —
Алдашмый кала алдым.
Адаштырырга теләде —
Адашмый кала алдым.

Бала өчен ана — иман,
Син аңа — мәңге бала.

Кеше бөтен гомере буе
Үз асылында кала.

Уразайның тугаенда
Аунап үскән мин — бала,
Ярты гасыр аша атлап,
Һаман алга юл ала.

Күзләремә һаман карый
Уразай кәрешкәсе.
Эзләремне барлап бара
Әнием фәрештәсе.

* * *

Яхшылыкны әгәр эзләсәң,
Күңелең белән күңел бизәсәң,
Салкын кар да сиңа җылы булыр,
Табигатьнең серле җыры булыр.
Бозлар хәтта нурлы гөлсәр булыр,
Укып туймас яңа әсәр булыр.
Һәрбер яфрак сиңа назлар бирер,
Кошлар сайрап, яңа язлар бирер.

Әгәр баксаң яман күз белән,
Сердәш булып яман сүз белән,
Табигатьнең холкы бик кырыс, —
Көтмә инде аннан син ырыс.
Салкын кары җаның туңдырыр,
Ыжгыр бураннарын туздырыр,
Яшел яфрак сиңа эндәшмәс,
Кошлар сиңа җырлар өләшмәс.
Салкын карар кайнар кояш та,
Сәлам биреп бармас как таш та.

Тик яхшылык сине үз итәр,
Ә яманлык җанны боз итәр.

* * *

Стаканда гына су кайнаттым,
Һә дигәнче чыкты сикереп:
Нәни дулкын әнә ничек шашып,
Ыргый-таша шартын китереп.

Стаканда гына сикергәнен
Белми инде,
Шушы — дөнья, ди.
Бу тормышның барлык хикмәтләре
Нәни стаканга сыйган, ди.

Нишләр иде икән, күрсә әгәр
Диңгезләрнең ярсып кайнавын.
Бар кешеләр — «стаканда кайный», —
Зур дөньяны уйлау кайда ул.

* * *

Чыккан чакта ябып ишекне
«Кайтмам» дигән сүзең ишеттем.
Тәнем буйлап салкын боз үтте...
Төн чигенде. Яңа көн җитте.
Кире кайттың, ачтың ишекне.
«Китмәм» дигән сүзең ишеттем.

...Ишекләрне япкан чакта да,
Ишекләрне ачкан чакта да,
Уйлау кирәк артың-алдыңны —
Кисмә, берүк, кунар талыңны.

Түгәрәклимен дип

Кара диңгез буе — Җир сәхрәсе.
Җылы дулкын ала кочакка.
Шулчагында кеше кинәнә дә
Рәхәтлеккә, бага як-якка.

Барысын да онытып әйтеп куя:
«Дөньям бүген нинди түгәрәк!»
Шул рәхәтлек гүя бер туп булып
Диңгез буйлап йөри тәгәрәп.

Хәтта ташлар монда гел түгәрәк, —
Диңгез аны шулай шомарткан.
Агач кисәген дә түгәрәкләп,
Бәллүенә салып уйнаткан.

Бу тормышны түп-түгәрәк итү —
Гомер буе кеше хыялы.
Ә нигә соң дөнья хәнҗәр булып
Кеше бәгырьләрен кыя әле?!

Түгәрәклимен дип бар тормышны
Яшәмиме кеше ут йотып?
Тик нигә соң һәрбер адымында
Һәлакәтләр тора куркытып?

Ул гынамы?
Кайчак кеше баса
Кылдан нечкә кылыч йөзенә.
Җанны, тәнне кыяр кытыршылык,
Кырыкмаса кырык төсенә
Килеп каршы ала юлларында, —
Чыда гына, атла, бирешмә.
Түгәрәклимен дип бар дөньяны
Кеше яши шушы килеш тә...

147299
Национальная библиотека
имени Ахмет-Заки Валиди

Җылы диңгезләрнең кочагында
Кеше тора үзен онытып.
Гүя диңгез сине бала итеп
Бер тирбәтеп ала, оетып.

Бер язмышлы

Җәй уртасы.
Ә үләннәр
Күзгә күндәй сап-сары:
Сары булып җиргә күчкән
Яңгырсыз җәй аһ-зары.

Әй, Ходаем, яңгырыңны
Ник кызгандың адәмнән?
Булды мәле: яуды, койды
Ел буенча әрәмгә.

Җәй уртасы.
Яфрак сары —
Сары яфракта каен.
Сары яфраклы каенга
Барып сарыла кайгым.

Сары яфраклы каенга
Сөялгән яп-яшь хатын.
Йөзендә — сары сагышы, —
Сорама исем-атын.

Ялгыз хатын, чибәр хатын —
Сутлары уйнар чагы.
Мәхәббәт яшеннәрендә
Яшьнәр һәм дулар чагы.

Кайда мәхәббәт яңгыры?!
Ходаем, ник жәлләдең?!

Күрәсең бит,
Беләсең бит
Бу чибәрнең хәлләрен.

Мәхәббәт ялкыннарына
Коендырсаң, ни була.
Ул — сагышта.
Шул сагыштан
Баскан җире убыла.

Җирем көя.
Мәхәббәтсез
Йөрәк көя — сагышлы.
Яңгырсыз җәй,
Ирсез хатын —
Икесе бер язмышлы.

Иртә әле

Туктап калган сыман кайчак гомер —
Бер мәгънәсез үтә көннәрең.
Бер файдасыз йокыга сала сыман,
Башкаеңны кочып, мендәрең.

Бөтен дөньяң тына.
Ят гамьсезлек
Биләп ала бөтен булмышны.
Шушыннан да яман хәтәррәк мәле
Була микән, димен, тормышның?

Бер борчылу җанны кимерә башлый,
Җимерә башлый гамьсез мәлеңне:
«Әзерләндең мәллә тапшырырга
Җәһәннәмгә тынмас җаныңны?!»

Йөгереп килә уйлар, ярсу уйлар.
Рәхмәт инде шушы уйларга.
Туктап калган сыман гомеремне
Алып чыгам тагы юлларга.

Камчыларга керешәм үз җанымны:
«Син — аргамак, җилдер арырак.
Гамьсезлекнең упкыннарын сикер.
Иртә әле сиңа арырга,
Оялмыйча туктап калырга».

* * *

Бәйләп кенә элгән асыл шәлнең
Берәм-берәм күзе киткәндәй,
Тәрәзләрдән тамчы йөгерә, чаба.
Уйларым да чаба шуңа карап,
Гомеремнең көзе җиткәндә.

Ашыга тамчы җирнең куенына —
Яшәү, яшьнәү биргән җиремә.
Күккә түгел, җиргә ашыга.
Мин дә «җирем» дидем, яндым-көйдем,
Ачкыч эзләп яшәү серенә.

Көмеш тамчы үлән тамыры белән
Кавышып елый яшәү хакына.
Тамчыкайның шундый шат елавын,
Яшәртәм, дип, җирне, куануын
Җыр итәргә җаным талпына.

Борчымагыз

Тегеләй бул, болаерак бул, дип
Борчымагыз минем җаннарымны.

Башкаларда булган сыйфатлардан,
Башка күпләр үткән сукмаклардан
Эзләмәгез минем гамьнәремне.

Тик әйткәнчә генә яши китсәм,
Үземчәдән, дуслар, нәрсә калыр?
Үтелгән дә, алда үтәсе дә —
Үземнеке булсын һәммәсе дә, —
Булса да ул авыр, мең кат авыр.

Тик яшәвем якты эз калдырсын
Яктылыкны сөйгән җиркәемә.
Кирәк түгел миңа һич тә зур дан,
Үзем киткәч әйтсен хәтта дошман:
«Ямь өстәде, — диеп, — җир ямен ә».

Гомер гөлләмәсе

Кырык яшең тулгач,
Үкенә биреп,
Егермеңне бетереп әрлисең:
Нинди чаклар иде,
Кадерләрен
Белмәдем шул, үтте, жәл, дисең.

«Егет» дигән исемем җитәр иде
Яулар өчен кызлар карашын.
Яшьлегемне елгыр канат итеп,
Җирне, күкне иңләп барасым

Калган икән,
Калган бик күпләре.
Кайда калган җилдәй җиләр чак?
Җимешләрен әле уйламыйча,
Чәчкәсенә исереп йөрер чак?!

Егермеңне шулай сагынасың.
Кырыгыңны әле уйлау юк.
Ул да, әнә, чабып үтеп бара,
Сагындырыр әле шулай ук.

Алтмышыңа җиткәч:
«Кайда китте
Кырык яшьлек уттай чакларым?!» —
Диеп сагынырыңны уйламыйсың,
Юрта бирә гомер чаптарың.

Шулай инде,
Һәрбер матурлыкның
Үтеп киткәч арта кадере.
Егермең дә,
Кырыгың, алтмышың да —
Үз төсендә булып һәрбере,

Гөлләмәсе булып гомереңнең,
Күңелеңдә бара җыелып,
Карурманнар аша, таулар аша
Ишетелер моңлы җыр булып.

Төн

Ялга китә ак көн.
Ә төн кала,
Ана бөркет сыман ояда.
Утыра төн саклап тын дөньяны,
Көн — йомырка әле дөньяда.

Сакта бөркет,
Утыра сабыр гына:
Көн язмышы өчен җаваплы.
Керфек какмый көтә,

Япь-яшь көннең
Тууын көтә, кагып канатны.

Таң сарысын ярып ак көн туа,
Һәр тарафны манчып нурларга.
Канатында алып чыга күпме
Кешеләрне озын юлларга.

Мин дә җиләм
Әкият батыры сыман,
Әйтерсең лә барам алышка.
Эзләп барам гүя әкият кызын,
Ашыктырып көнне, ярсып җиләм
«Мин мондамын!» дигән тавышка.

Сабырлык

Кичтән ишеттем авыр сүз —
Авырның да авыры.
Күкрәгемә сыймый, дулый
Әрнү-җәбер давылы.

Шушы давыл бар дөньямны
Җимереп китәр сыман,
Гомеремнең бакчаларын
Күк сөрем итәр сыман.

Мәрхәмәт тә, мәхәббәт тә
Коткара алмас кебек.
Пыяланы чытырдатып
Алгандай алмас телеп,

Җәбер кисә бәгыремне.
«Кайда син, — дим, — сабырлык —
Гарасаттан, һәлакәттән
Йолып кала алырлык?»

«Нигә әле төн буена
Йөрәгемне яндырам?
Иртә кичтән хәерлерәк,
Иртәгәгә калдырам», —

Тәкрарлыймын шуны кат-кат,
Үзем белән көрәшәм.
«Сабыр, сабыр, сабыр!» — диеп,
Кара төнгә эндәшәм.

Иртән тагы сүз ишеттем:
Җанга җан өрердәен,
Сүнеп барган өметеңә
Канатлар бирердәен.

Бу мәл үтте...
Әмма кабат
Килмәс дип ышандырма.
Сабырлыгым, тик шулчакта
Ялгызымны калдырма.

Җыр чакыра

Мин үземне кайчак, ни өчендер,
Идел ярында дип хис итәм.
Дулкын-дулкын аккан елга аша
Таныш түгел бер җыр ишетәм.

Җыр чакыра мине.
Ашкынамын:
Җырлаучысын килә күрәсем.
Елга яры якын тоелса да,
Җырчы бигрәк ерак, күрәсең.

Сихри бер моң булып талгын гына
Ишетелә ул җыр.

Җилкенеп
Тыңлыймын мин.
Хыялым алда оча,
Җырлаучыга ашыга җил кебек.

Ашыкса да хыял,
Җиңел генә
Булмас аңа барып җитүе.
Идел — тормыш, тирән упкыннары,
Ансат түгел кичеп үтүе.

Җыр чакыра. Барам. Идел кичәм.
Киләчәгем чакыра җыр булып,
Юлым авыр, әмма кайтасым юк
Чыккан юлларымнан борылып.

* * *

Фани дөньяларда ниләр генә
Тетрәндерми адәм баласын.
Тик кайчакта шуңа чын ачкычны
Таба алмый йөдәп каласың.

Андый чакта кайтам асылыма,
Кайтам кабат чишмә башына.
Утырамын ерак яшьлегемнең
Капка төбендәге ташына.

Ата-бабам йөргән сукмаклардан,
Ат-ат уйнап үскән урамнан
Кабат-кабат үтәм:
Һич зыян юк
Үз юлыңны кат-кат ураудан.

Гел сафлана бара тойгыларым,
Кайнарлана бара хисләрем.

Мин бит шунда тәүләп иңгә салдым
Озын сәфәремнең биштәрен.

Ачкыч алам шигырь юлларыма:
Үземнеке ләсә бары да.
Тетрәндергән уйны кешеләргә
Әйтеп бирер сүзләр табыла —
Сәфәремә чыгам тагы да.

Самавыр

Фатиха әби өстәлендә
Ике самавыр тора.
Кайсы кадерлерәк, диеп
Сора әле, бер сора.
Әйтеп бирер, сөйләп бирер,
Сүзләре җырлар кебек:
Берчә сөйләр күз-яшь сөртеп,
Берчә кеткелдәп көлеп.
«Монысы, — дияр, — электрлы,
Улларым бүләк иткән.
Мәшәкатьсез, үзе кайный,
Җаны эчендә икән.
Икенчесе — күмернеке.
Ансы инде — бар дөньям.
Ялгыз гына булган чакта
Гелән шунысын куям.
Җырлап китә, гөрләп китә —
Бигрәк ягымлы сердәш.
Көйләп бирер барысын да,
«Дускай» диеп бер эндәш.
Күмер самавырларына
Җитәме инде, балам.
Ут-күмергә тамырым тоташ —
Яшьлеккә кайтып алам.

Бабаң мәрхүм исән чакта
Бергә токкан самавыр.
Ах, бу гомер, ах, бу яшьлек —
Мәңге озата барадыр.
Йөрәгеңнән кайнар каның
Тамчы-тамчы тамадыр.
Самавырга кушылып үзем
Җырлап та алам, балам.
Җылап та алам, балам.
Әйтерсең дә шикәр ватып
Янда утыра бабаң...
Күмер самавырларына
Җитәме инде, балам.»

Гомерем, күңелем

Гомерем — көннәрдән ясалган
Кәрәз сыман.
Күңелем — урамга караган
Тәрәз сыман.

Кәрәземне азлап-азлап
Китә торам,
Кешеләргә аны бүләк
Итә торам.

Күңелем-тәрәз якты көннән
Нурлар ала,
Кешеләргә шул нурлардан
Юллар сала.

Гомер-кәрәз, күңел-тәрәз
Тынмый бер дә:
Димәк, мин бар, димәк, яшим,
Яшим җирдә.

Шагыйрь-йөрәк сайрамаса

Сыерчык — йөрәкле кошчык,
«Йөрәк»не шагыйрь куйган.
Бер сайравы — бер могҗиза,
Аны кем тыңлап туйган?

Йөрәксез соң сайрау бармы,
Йөрәк бит үзе — кошчык.
Нинди ут-сулар кичми ул,
Җир шарын кочып, очып.

Шагыйрь-йөрәк сайрамаса,
Кошчык сайрамас иде.
Шушы икәү һәлак булса,
Җирдә моң калмас иде.

Җирдә кошлар күп булса да,
Шагыйрь «кошчыгы» берәү:
Җиргә, күңелгә ут биреп,
Гомергә яшьнәү-күкрәү...

Шагыйрь йөрәген саклагыз,
«Сыерчыгын» саклагыз.
Очарга чыккан галәмгә,
Җырсыз канат какмагыз.

КҮҢЕЛ МОҢЫМ БУЛЫР ҖИРЕМ МОҢЫ

Минем йолдыз

Катлы-затлы башваткычлар эзләп
Үткәрмәмен гомерем әрәмгә:
Күңелемдәге моңны
Мин көйләрмен
Адәм теле белән адәмгә.

Алтын-көмеш вәгъдә итмәмен мин,
Өләшермен бары яхшылык.
Күңеленә күчсә кешеләрнең
Күңел шәмемдәге яктылык,

Утлар-сулар кичеп үткән чакта,
Җиңеләйтсәм алар адымын, —
Җитә миңа.
Төпсез күккә түгел,
Яшел җиргә минем бар моңым.

Күктән йолдыз чүпләп бирәм, диеп,
Шапырыну миңа нигә ул?!

Якты йолдызы да,
Тир тозы да
Барысы да җирдә, җирдә ул.

Күңел моңым булыр җирем моңы —
Кешеләргә әйтер бер сүзем.
Галәм киңдер,
Күптер йолдызлары.
Минем йолдыз — җирем, җир үзе.

Җырым туды

— Шагыйрь иптәш, бүген сиңа нәрсә булды —
Йөзең-күзең шатлык нуры белән тулы?

Елмаясың, һәрнәрсәгә сөенәсең,
Тәмле-татлы, назлы сүзләр сөйләнәсең.

Әллә сиңа бүген шундый зур бәйрәмме?
Котлап дуслар китергәнме гөл бәйләме?

Әллә бүген синең тәүге улың туды?
— Әйе, дуслар, улым туды — җырым туды,
Җырым туды!

Кайтам, китәм

Дөнья сәер генә, кайчагында
Охшап куя көйсез хатынга.
Кайтсаң — кит, дип тия теңкәләргә,
Китсәң чакыра тизрәк кайтырга.

Үземнең дә гадәт шуңа күнгән:
Кайтсам, көтәм кабат китәсен.
Көтәм сәфәремнең яңа юллар,
Яңа җырлар бүләк итәсен.

Гомер җебем бермәл өзелеп калса,
Бүленеп калса кайтыр сәфәрем,
Барыбер кайтыр, көтегез, кайтмый калмас
«Кайталмады» дигән хәбәрем.

Каршыламагыз аны боек итеп,
Каршылагыз күреп үземдәй.
Хәбәр булып кайтып кергәндә дә,
Әйтсен кешеләр: «Гомере юлда узды,
Һәм елмаю булды йөзендә».

Дөнья юлында

Бакча балалары тезелешеп
Урам аша чыгып баралар.
Ашкынышып килгән машиналар
Кинәт кенә туктап калалар —
Балалар бит чыгып баралар.

Тере чәчкә сыман шат балалар,
Рульдәге олы абыйлар...
Йөрәгемне минем сискәндереп,
Уйларыма уйлар ялгыйлар.
Машиналар усал карыйлар.

Ярсып килгән явыз машинаны
Тыймасалар олы абыйлар,
Нишләр иде тере чәчкә сыман
Бер гөнаһсыз шушы сабыйлар?
Тыймасалар олы абыйлар.

Рульләрдә утыра зур абыйлар —
Машиналар алар кулында.
Дөнья — ыгы-зыгылы олы бер юл.

Миллион бала дөнья юлында.
Миллион бала минем уемда.

Күңелләре чәчкә,
Уйлары да.
Бер эчкерсез бала.
Балалар
Явыз машиналар каршысыннан
Тыныч кына чыгып баралар.
Тыныч түгел әмма абыйлар.

Миллион бала — дөнья юлында.
Миллион бала — минем уемда.

Ана күңеле

Төннәрендә елап уянганда
Бүлгәнмендер татлы йокыңны.
Йоклап китсәм, күзең йомылгандыр,
Басып кына куеп утыңны.

Өсләремә торып япкансыңдыр,
Әллә ничә кабат уянып.
Күкрәгеңә кысып сөйгәнсеңдер,
Көлгәнемә хәтта куанып.

Соңгы кабымың да миңа булды:
«Син тук булсаң, мин дә тук», — диден.
Яңа булса, «аңа булсын», диден,
Искергән инде син киден.

Өйдә юкта, «аның өлеше», дип,
Бер кисәкләп җыя белдең син.
Кайсы бармагыңны тешләсәң дә,
Авырта ул, дия идең син.

Ул вакытта сиңа рәхмәтне дә
Әйттек микән, әллә юк микән?
Әле генә белдем: ана күңеле —
Баласына җылы өләшә-өләшә
Гомер буе янган ут икән.

Син әйтәсең

Син әйтәсең: еш-еш абынасың,
Бер дә юньләп йөри белмисең.
Туып килгән шигырь ләззәтенә
Исерәм мин, шуны сизмисең.

Син әйтәсең: кайчак исәнләшми,
Хәтта күрмичә дә үтәсең.
Шигырь туган чакта күз нурын да
Күңел тартып ала, күрәсең.

Дәвам итә

Менә тагын таңда уяндым,
Таң туугa чиксез куандым.
Нур балкытып шәмем кабынды.
Яңа көнгә яңа юл ярдым.

Минем кебек меңнәр уяна,
Минем кебек меңнәр куана.
Яшәү хозурлыгын игълан итеп,
Меңнәр бүлмәсендә шәм яна.

Шул минутта кемдер уянмый,
Аның бүлмәсендә ут янмый.
Дөнья, дөнья! Кемне уята,
Мәңгелеккә кемне йоклата:

«Тормыш» дигән олы фронтта
Солдатларын шулай югалта.

Җирдән шулай кеше китә, дигән
Бер авыр уй җанга шом сала.
Чү! «Яшәү!» дип, әнә, сөрән сала
Таңда гына туган бер бала.

Тояк тавышы

Урам уртасыннан бер ат юрта:
Тояк тавышы кала яңгырап.
Арбасында да шул юньле йөкме —
Буш әрҗәләр бара шылтырап.

Олы урам кайный,
Күп кешеләр
Такси белән генә сыздыра.
Атны узып киткән чакта алар
Машинаны юри кыздыра.

Көлеп үтә алар,
Телеп үтә
Җирәнкәйнең йөрәк ярасын:
«Нинди көнгә төштең, кала аты,
Буш әрҗәләр төяп барасың...»

Тояк тавышы яңгырый так-ток, так-ток —
Машиналы, шаулы урамда.
Шул тавышка ияреп минем уйлар
Уралалар ерак буранда.

Алга баса кышкы карлы юлда
Тройканың елгыр җилүе,

Илгә ирек яулап алган мәлдә
Атлыларның күкрәп килүе;

Туй атлары урам ураганы,
Моңлы кыңгырауны зыңлатып,
Карлы юлда буран уйнатып.
Тояк тавышы барын уятып,
Сискәндереп куя:
Онытма, ди,
Безнең дә бит булды шәп чаклар.
Ничә гасыр буе заманнарны
Тартып алып килде шул атлар.

Менә ничек атлый гасырлар...
Әллә кая чаба уйларым:
Кеше берчак, ракетада йөреп,
Үткәрмәсме, димен, туйларын.

Һай, заманнар...
Заман агышы...
Колагымда яңгырый так-ток, так-ток,
Так-ток, так-ток тояк тавышы...

Карбыз һәм дус

Базар кыдырып йөрим синең белән.
Тау-тау булып карбыз өелгән.
Барысы да сылу, түп-түгәрәк,
Буй-буй бизәк асыл киемнән.

Киеме кием дә бит,
Эче нинди?
Безгә кирәк алы, баллысы.
Сатучысы чибәр.
— Әйтче, — дибез, —
Туры карый безгә кайсысы?

Тау-тау карбызларны урыйбыз да
Әлеге җиргә кабат барабыз.
Кыз елмая:
— Бик күп сайланмагыз,
Шикләнсәгез, ярып карагыз.

«Карбызларны ярып карап була.
Ә кешене?...» —
Уем эндәшә.
Насыйбыдыр — ярып карамадык.
Кыз тәбрикләп калды:
— Мең яшә...

«Карбыз түгел кеше...»
Булды дуслар —
Юл үткәндә сатты, сынатты.
Алларыңа гөлләр чәчәр мәлдә
Койма аша утлы ук атты.

Алар да бит тыштан караганда
Мөлаем иде, асыл киемнән...
Кулда карбыз.
Киләм берәм-берәм
Дусларымны барлап күңелдән.

Син дә эндәшмисең.
Синең уй да
Әллә кайда йөри адашып.
Син сыналган, ярып карау нигә —
Һичберәүгә булмый алмашып.

Табигатем шундый

Һич уйламаганда, көтмәгәндә
Мин калдыра яздым дөньяны:
Әллә нинди ямьсез төскә кереп,
Күз алдымда әҗәл уйнады.

Мондый мәлнең берчак киләчәге
Башыма да хәтта кермәгән.
Әйтерсең лә инде, мин берзаман
Җирдән китәр өчен килмәгән.

Әй яратам сине, тормыш, диеп
Җырлап кына йөреп ятканмын.
Исәнлекләр дигән байлыкны мин
Уңга-сулга алып атканмын.

Карлы-бозлы юлга тараткнмын, —
Кайда аны үлчәү, кадерләү.
Шушы саксызлыгым, әйтерсең лә,
Сөрән сала минем бәгырьдә:

«Яратуың гына җитми әле,
Кадерен дә бел, — ди, — гомернең.
Кызган самавыр да кайный алмый,
Янып, көлгә калса күмерең...»

Хәл шәбәйгәч, теге хәтәр чагым
Истән чыккан, тәмам онытылган.
Ерып барам тагын карын, бозын,
Тагын үтәм зәһәр утыннан.

Нишлимен соң, табигатем шундый,
Үпкәләп тә булмый беркемгә.
Хыялымны алсу җилкән итеп,
Мин һаман да алга җилкенәм.

Яңа кала коям

Йозаклы әле дөнья.
Бу тормышта
Күпме нәрсә бикле, йозаклы.

Күңелемә керде шундый бер уй:
«Бу йозаклар яшәр озакмы?»

Ил чикләре — йозак.
Ишекләрдә
Күпме тимер тора эленеп.
Дөнья домнасында
Барысын да кабат эретеп,
Кала коясым килә,
Йозаксыз кала —
Киләчәкнең Ышаныч каласын.
Йозаксыз яши алыр дәрәҗәгә
Күтәрсәкче адәм баласын.

Йозаклы әле дөнья.
Ил чикләрен
Бикләмәсәң, дошман ажгыра:
Ак чәчкәләр япкан гүзәл җиргә
Пычрак кулын әзер салырга.

Ишекләрне әгәр бикләмәсәң,
Бар явызы, карак-угыры.
Затлы савытларны, сандыкларны
Йозак саклый, йозак тугры.

Күп күңелләр бикле.
Шакшы җаннар
Бәреп керергә әзер карактай.
Йозак кирәк тә бит.
Ә шулай да
Йозакларны җаным яратмый.

Хыялымда яңа кала коям,
Ышаныч каласы, —
Дуслар, килегез,
Ачык ишекләргә, күңелләргә
Колач җәеп, әйдә, керегез.

Тел ачкычы

«Әлифба» тотып чыкканда
Ачып авыр ишекне,
Әниемнең талгын гына
Йомшак тавышын ишеттем:

— Балам, сиңа — тел ачкычы... —
Юлым шулай башланды.
Әниемнең шул сүзләре
Гел күңелдә сакланды.

«Тел ачкычы» нәрсәдер ул?
Бу тынгысыз йөрәкме?
Күңелгә гел тугры юлдаш —
Намус дигән терәкме?

Җирнең матурлыгын эзләп,
Сөеп баккан күзме ул?
Кемнәргәдер әйтеләчәк
Берәр җылы сүзме ул?

Кешеләрне сөендереп
Сузылган кулыммы ул?
Очы-кырые күренмәгән
Бормалы юлыммы ул?

Яхшылыкны яманлыктан
Аерып бирер телемме?
Мине үзенең улы иткән
Һәм ир иткән Илемме?

Ни булса да, «тел ачкычы» —
Бәхет ачкычымдыр ул.
Ил түренә алып менәр
Гомер баскычымдыр ул.

Дәвамым

Алмаска

Улым, синең күзләреңә карап,
Гомер юлларымны барладым.
Шигыремдәге соңгы сәламемне
Синең килереңә арнадым.

Чакрымнарым өзелеп калыр мәлдә
Сиңа күчә минем дәвамым.
Мине газаплаган сорауларга
Син ишетерсең тормыш җавабын.

Кар яктысы

Һәр мизгелнең бар яманы,
бар яхшысы.
Салкын кыш. Төн. Алда бары
кар яктысы.
Тын. Кара төн. Шомлы дөнья,
шикле дөнья,
Бар серләрен яшереп яткан
бикле дөнья.
Мин барамын. Туктап калсам,
гомер туктар,
Дөньям кабат уянмаска
ятып йоклар.
Салкын тынлык. Шомлы тынлык.
Әйди бары
Кар яктысы. Артта, алда —
гомер яры.
Бер яктың да калмаганда,
кар яктысы
Көч-дәрт бирә: исәнмен бит,
Шунысы бүген иң кадерле,
иң татлысы.
Алга әйди кар яктысы.

Тәрәз уйдым, ишек куйдым

— Кеше нигә тәрәз уйган?
— Кояш күрер өчендер.
— Кеше нигә ишек куйган?
— Кеше керер өчендер.

Ишек-тәрәз уелмаган
Өйгә китә кеше бер:
Тудыра да, кабат үзенә
Ала сине шушы җир.

Ишек-тәрәз уелмаган
Өйгә киткәнче әле
Кешенең дөнья шаулатып
Яшьнәп яшәрдәй мәле.

Шушы яшәү миндә әле.
Кадерен беләмме соң?
Юлларымда нурлар булып
Төннәрне теләмме соң?

Җир көйгәндә, гөл шиңгәндә,
Чишмә була алмасам,
Илем әйтер: «Ник туган?» — дип,
Әгәр гомер ялгасам

Чәчкә-гөлгә дым-сут биреп,
Минә бу яшәү булыр:
Ишегемнән кеше йөрер,
Тәрәзгә нурлар тулыр.

Кешеләргә ишек ачам,
Кояшка тәрәз ачам.
Шушы тәрәз һәм ишегем
Ябылмасын һичкайчан.

Серле сандык

«Серле сандык»тан башланды
Минем күңел дөньясы:
Яманлыкны куа килде
Яхшылыкның кояшы.

Әби сөйли серле әкият:
«...Ыжгыр салкын буранда
Үги анасы сабыйны
Адаштыра урманда.
Салкын бабайның йөрәге
Салкынын салкын, зәһәр.
Изге күңелле баланы,
Юк, әрәм итми мәгәр, —
Адаштырмый.
Сандык төяп
Менә ятимә кайта.
Явызлык кала җиңелеп —
Үги ана шакката.
Серле сандыктан алтыннар,
Мәрҗәннәр чыга җырлап...»
Ятимәнең куанычы
Безгә бер бәйрәм сыман.
Әбекәйне кочаклыйбыз,
Авыз колак артында.
Ул, тамагын кырып алып,
Дәвам итә тагын да:
«...Үги ана үз кызын да
Ашыктыра урманга.
«Серле сандык» алып кайтып,
Алтыннарга урарга.
...Сандыктан чыга ажгырып
Явыз кара еланнар...»
Әбекәй сөйли...

«Ах!» итәбез
Без — биш яшьлек оланнар.

Сабый чаклар артта инде,
Әкият тыңлый бүтәннәр.
Тик шул «сандык» алга килеп,
Чымырдап китә тәннәр.
Дөнья һаман күз алымда,
Әйтерсең «серле сандык» —
Көне-төне тарткалаша
Яхшылык һәм явызлык.
Яшел үсенте шикелле,
Яхшылык яфрак яра,
Яшел корт булып яманлык
Аңа үрмәләп бара.
Берәүләр сайрый кош булып,
Моңга күмеп Җир шарын.
Берәүләр усал мәчедәй
Аңа суза тырнагын.
Берәүләр Җиргә нур кушып
Орлык чәчә: үссен, ди.
Берәүләр Җиргә ут чәчә:
Орлык янсын, көйсен, ди.
Берәүләре оран сала:
«Әй, тормыш, яратам!» — ди.
Икенчесе сөрән сала:
«Мин асам да атам!» — ди.
Яхшылык бага дөньяга
Изге, саф олан булып.
Яманлык йөри дөньяда
Агулы елан булып.
Яхшылыкны туңдыралар —
Ул уҗым булып чыга.
Кара зинданга күмәләр —
Ул чишмә булып туа.
Яхшылыкны яндыралар —

Ярала корыч булып,
Яманлыкның тамырларын
Кыркырлык кылыч булып.
Мин инанам,
Күрә киләм
Яхшылыкның җиңүен,
Җир-анага чыңгырдатып
Энҗе-мәрҗән тезүен.

Күз алдымда дөнья шулай
Гел «серле сандык» кебек.
Ә үзем әкият тыңлаучы
Беркатлы сабый кебек.

Тукайга

Еллар аша килдең, Тукай,
Күңелемә.
Җырың белән ямь өстәдең
Гомеремә.

Шигырьләрең минем җанда
Чәчәк ата.
«Пар ат»ларың юрта-юрта
Алга тарта.

Эштән кайтсам, шигыреңне
Сөйләп кайтам.
Ял иткәндә «Әллүки»не
Көйләп ятам.

Синең җырың миңа сулар
Һавам кебек.
Һәм ягымлы, яңа туган
Балам кебек.

Рәхмәт сиңа, юлдаш миңа
Моңлы сазың.
Күңелемнән мәңге китмәс
Шигъри назың.

Гаҗәпсенмә

Авыр кайгы килгән чакта әгәр,
Күзләремдә яшьләр тапмасаң,
Башны түбән иеп катып калмый,
Тешне кысып алга атласам,
Юк, рәнҗетмә мине, таш бәгырь, дип, —
Тормыш үзе шулай өйрәтте.
Баш имәслек итеп кайгы алдында,
Таштан каты итте йөрәкне.

Нәни генә куаныч килгәндә дә,
Күзләремдә яшьләр күренсә,
Таңгы чыклар кебек ике тамчы
Керфегемә кушылып үрелсә,
Гаҗәпсенмә һич тә, һәр шатлыкны
Шулай тоям, шулай кичерәм,
Зур кайгыга башым имәсәм дә,
Нәни шатлыктан да исерәм.

Гаҗәпсенмә, мине кече яшьтән
Тормыш үзе шулай өйрәтте:
Җирнең назын ныграк тояр өчен
Йомшак итте минем йөрәкне.

Ярый әле

Ярты гасыр ашу сөйрәп киләм
Бураздадан тормыш сабанын.
Ычкындырмый тормыш дилбегәсен,
Тукый тора ачы сабагын.

«Тегеләй булмый, болай була, — ди ул, —
Тегеләй ярый, болай ярамый».
«Ярамые» кайчак ярап куя,
Ә «ярые» йөрәк яралый.

Яши-яши кеше белә икән,
Тоя икән тормыш серләрен,
Берчә өшеп, берчә утта пешеп,
Яулый икән аның үрләрен.

Шунысына сөенәм: үз төсендә
Күрә килдем хагын, ялганын.
Ярый әле, гомер сабак алып,
Үзем булып кала алганмын.

Бала

Бала, бала...
Арыган чаклар була,
Кузгаласың килми урыныңнан,
Кайгылы чак була,
Өметсез чак,
Адашасың барган юлыңнан.

Шулчак нәни куллар,
Йомшак куллар
Муеныңа килеп сарыла —
Юкка чыга бөтен арыганнарың,
Кайгыларың-ниең — бары да.

Бала, бала...
Ана кеше аны
Мең газаплар белән
Алып килә дөнья йөзенә.
Юк, сыкранмас ана
Шушы нәни күзне
Ачар өчен әгәр үзе язса
Көн яктысын күрер күзеннән.

Ана
Һич кызганмый
Үз йөрәген бирер
Типсен өчен нәни бер йөрәк,
Дөнья куяр:
«Калдырам, — дип, — җиргә бер бүләк»...
Бала, бала...

* * *

Шагыйрь күңелендә кыш булмый...

Габдулла Тукай

Бүген иртән баксам тәрәз аша,
Яшел үләннәргә ак кар яткан.
Саубуллашыр мәлдә көзләр белән,
Гүя гөлләр ап-ак чәчкә аткан.

Көзләр алып китәр гөлләрне дип,
Юкка гына икән борчылуым.
Тәүге карга әнә басып килә
Илһамиям минем — ут сылуым.

Таулар кадәр шатлык алып килә —
Күңелемдә кояш балкып китте.
Картлар таягына үрелер мәлдә
Өзә басар яп-яшь егет итте.

Билләреңне биштән бу, узаман,
Заман синнән яңа җырлар көтә.
Юлларыңа кара: ак чәчәкләр
Кояш нурларында җем-җем итә.

* * *

Нигә әле болай елларымны
Китап бите сыман актарам?

«Мин — монда!» — дип хәбәр биреп кала,
Тере кеше сыман ак-карам.

Табигатем болай гомер буе
Эзләсә дә акны, яктыны,
Тормыш юлларымда кайчакларда
Күмеп китте яман яхшыны.

Үткәннәрне, китап бите сыман,
Актарып та була, барлап та.
Юлларыңны, елкы ялы итеп,
Яманнарын була тарап та.

Алдагысы — ачылмаган китап,
Үтелмәгән сукмак, караңгы.
Үз-үземә һаман тәкрарлыймын:
«Абайлап бар акны-караны.

Актарганда ансын китап итеп,
Каралары булсын азрак.
Яңгырлары булсын шифалырак,
Ә гөлләре булсын назлырак.»

Озатмадык

Сине озаткан көн кояшлы иде.
Табигать бит көчле: барына
Шартын таба — кара болытларын
Китермәде гомер ярыңа.

Туган көнең нинди булганлыгын
Тик әниең генә белгәндер.
Рауза гөле — кояш гөле диеп,
Рауза дип исем биргәндер.

Үзең дә бит минем йөрәгемә
Кояш гөле чәчеп калдырдың.
Барыр юлларыма сүнү белмәс
«Өмет» дигән шәмдәл яндырдың.

Бураннарда, юлдан адашканда
Шул шәмдәлгә карап юл табам.
Мин картәти хәзер,
Синең өчен
Сабый булып калам мин һаман.

Сине озаткан көн кояшлы иде.
Җаным тетрәп әйттем: «Озаттым...»
Ә фәрештәм әйтте: «Озатмадың.
Күңелеңдәге кояш гөлең белән
Әниеңнең гомерен озайттың».

* * *

Иңемә әнием камзулын
Салдың да тетрәттең.
Ни булды?
Әйтерсең, яңадан терелеп,
Ул минем тәнемә кагылды.

Дөньядан китте, дип уйласам, —
Ул һаман янымда икән лә.
«Ул вафат, ул китте», — дияргә
Ашыкмый торыгыз, исәннәр.
Рухыңның сафлыгын сакласаң,
Җаныңны ташламый якыннар.
Тәнемдә ул биргән кан йөри,
Җылыта ул биргән ялкыннар.

Рухыңның сафлыгын сакласаң,
Яшәүнең тамыры тирәндә, —

Әнием кагылды иңемә,
Ул һаман, әйтерсең, эргәмдә.

Кешенең гомере вакытлы,
Тәндәге тамырлар бер шиңә.
Рухи тамырлар үлми шул.
Рухи йөрәгең гел тибә.
Иңемә әнием камзулын
Салдың да тетрәттең. Яңадан
Яшәүгә көч алып, хис алып
Кайтамын әнием яныннан.

Йөрәк

Ертып ачтым күкрәгемне,
Йолкып алдым йөрәгемне.

Рәшит Назаров

Мин өемдә ялгыз калдым, —
Бик табигый андый хәлем.
Азмы җырлар бүләк итте
Шундый ялгыз калган мәлем.

Әле менә нишләдем мин?
Үз-үземә сыялмыймын.
Өйрәтмәгән тай шикелле,
Йөрәк дулый, тыялмыймын.

Ишегемне бәреп ачтым —
Чыктым дөнья кочагына.
Йөрәк иңли җирне, күкне —
Лачын булып оча гына.

Әйтә: «Тыныч булалмыймын.
Бик күп тоттың мунчагыңда.

Җир урыймын. Җибәрмәсәң,
Ташлап китәм ул чагында.»

Китте йөрәк, очты йөрәк:
Утлы учакларга керде,
Яуда ауган яшь солдатка
Шәфкать булып, сулыш өрде.

Тәгам көткән ач сабыйга
Үз кисәген бүлеп бирде.
Кайнар канын чишмә итеп,
Сугарды ул көйгән җирне.

Кавыштырды Сак-Сок кебек
Очрашалмый интеккәнне.
Авызлыклап бикләп куйды
Җанны кыяр явыз җанны.

Урап кайтты күкрәгемә,
Хәлдән таеп, тынычланып.
Ялкын аша үткән коштай,
Беткән үзе көеп-янып.

Утлар чәчеп әйтте йөрәк:
«Инде риза нишләтсәң дә,
Бикләп куеп, соң чиккәчә
Көне-төне эшләтсәң дә».

ТЕРЕ ЧИШМӘ БУЛЫП БАР, БАЛАМ

Чишмәле тау

Беркөн таулар телгә килделәр,
Һәркайсысы әйтте үз сүзен.
Сөйләр сүзләр бик күп иделәр,
Мактап үтте һәркем үз-үзен.

Сүз башлады тәүләп Бакыртау:
— Байлыгыма, — диде, — багыгыз.
Бәрәкәтле минем хәзинәм —
Күпме кирәк, әйдә, алыгыз.

Зыңлап китә шулчак Тимертау:
— Тимер тапкан, диләр, тилмермәс.
Кешеләргә биргән тимерем
Күпме куанычлар китермәс.

Ялт-йолт килеп әйтте Алтынтау:
— Тимер-томыр хакы кыйммәтме?

Алтын бизи бөтен дөньяны —
Алтында ул җирнең хикмәте...

Алмаш-тилмәш бары да мактанды.
Тик Күкрәктау гына тын калды.
Ул масаеп бер сүз әйтмәде,
Ерак-еракларга укталды.

Башка таулар аңа бактылар,
Төрле-төрле сүзләр аттылар.
— Әйтер сүзе юктыр, эндәшми...
«Эндәшмәс» дип исем тактылар.

Күкрәктауның йөрәге тын түгел,
Кайный иде дөнья хәстәре:
Күрә иде ерак болындагы
Суга сусап кипкән чәчкәне.

Таң алдыннан шундый хәл булды:
Күкрәктаудан чишмә ургылды.
Башка таулар кинәт тын калды:
Ни булды соң кинәт, ни булды?

Бакыр төсен, тимер ныклыгын,
Җем-җем иткән алтын ялтлавын
Алып чыкты чишмә
Дөньяга,
Матурлыгын җырлый тауларның.

Чишмә акты, акты моң булып,
Туфракларга сеңәр дым булып,
Чәчкә-гөлгә яшәр сут булып,
Йөрәкләрдә янар ут булып.

Шул чишмәгә карап уйланам,
Шул чишмәгә карап моңланам.
Җырым-балам,

Калма шул чишмәдән,
Кешеләрнең чәчкә күңеленә
Тере чишмә булып бар, балам.

Чишмәле тау — туган җиргенәм —
Гомер буе җырлар җыргынам.

Кечкенә сыерчык оясы

Түгелдер бу, ахры, сабантургай,
Бу йөрәгем, ахры, шулай җырлый.

Рәми Гарипов

Мин тагы авылымда.
Каршымда
Ачылган яшьлегем дөньясы.
Шул бакча, шул капка, шул кыек.
Кыекта сыерчык оясы.

Кошчыгы чыккан да, әй, сайрый.
Сайравы өзә шул үзәкне.
Йөрәгемме әллә бу кошчык?
Чыккан да ул ярып күкрәкне,
Җиһанга тарата моңнарын.
Уйларым урыйлар җир шарын.

Уйласаң, үзе бер могҗиза
Кечкенә сыерчык оясы.
Сыерчык оясы шикелле
Тоташ җир, кешелек дөньясы.

Җир шары тирбәлә галәмдә —
Үз заңы, үз моңы, үз гаме,
Кайгысы, шатлыгы, үз яме,
Зур кояш астында — үз шәме.

Кадерен белгәндә бу оя —
Бер дөнья, шәп дөнья, зур дөнья.
Кадерләп саклама — һәлакәт:
Караеп ачылган зур уя.

Йөрәгем — кошчыгы ояның.
Ояны чайкалтып җил иссә, —
Оя бит кечкенә, кыекта, —
Кыектан ычкынып ук китсә,
Ни булыр?!
Тәннәрем жу итте,
Әйтерсең йөрәктән ук үтте.

Сыерчык әй сайрый талпынып,
Сайраудыр аның бар дөньясы.
Каршымда шул капка, шул кыек.
Кыекта — сыерчык оясы.

Оныттылар, ахры

Тауның битен җылы яңгыр юа,
Яңгыр куа тауның карларын.
Гөрләвекләр чаба,
Күлгә чаба, —
Чыдап кына торсын ярларың.

Җылы яңгыр язны ашыктыра.
Кыш чигенә, ни хәл итәсең.
Көтә язны барысы да,
Әйтми:
«Кышым, — диеп, — нигә китәсең?»

Кыш килгәндә күпләр сөенә-сөенә
Каршылаган иде ак карны:
«Тәүге карлар ява, назлы карлар,
Мамык карлар!» — диеп мактады.

Әле шуны оныттылар, ахры,
«Яз килә!» — дип шашып баралар.
Эх, бу тормыш:
Иске онытыла,
Яңа шулай шаулап ярала.

Яз бит әнә яшь кыз сыман килә,
Сокландырып килә һәммәсен.
Ә кыш китә, әби булып китә.
Туры әйткәнгә хәтере калмасын.

Таң каламын

Таң каламын кайчак табигатьнең
Шундый көчсез, йомшак булуына:
Салкынча җил тиеп киткәндә дә
Чәчкә-кыякларның сулуына.

Таң каламын кайчак табигатьнең
Шулкадәрле көчле булуына:
Өрсәң бөгелер яшел кыякларның
Асфальтларны ярып чыгуына.

Таң каламын, шушы нәни кыяк
Хәтерләтә адәм затларын.
Булмыймыни минем шундый көчсез,
Шундый көчле булган чакларым.

Диңгез көче

Хәйран калып олы диңгезгә,
Гайрәтенә аның, көченә,
Киңлегенә, тирәнлегенә,

Сорадым мин:
— Диңгез, диңгезем,

Кайдан алдың андый гайрәтне?
Кайдан килде киңлек, тирәнлек?
Бер чайкалды диңгез һәм әйтте:
— Мул суларым ташып торса да,
Дулкыннарым ярсу булса да,
Барысын да алам елгадан.
Көч-куәт ул, әнә, елгада.

Мин ашыгып килдем елгага.
Дулкын кага-кага ул ага.
— Елга, — димен, — шушы дөресме?
Олы диңгездән син көчлеме?
Һич тартынмый әйтче, елга, — дим. —
Килдем шуны белер өчен мин.

— Эшем кызу — ашыгып су ташу,
Зур диңгезгә барып тоташу.
Ә көчне мин алам чишмәдән,
Зәңгәр чишмә минем юл башы.

Чишмә чыга менә ургылып.
Мин утырам чишмә буенда.
Дәү дулкыннар бәреп шаулаган
Ярсу диңгез минем уемда.

Сорашмадым, көчең нидә, дип.
Чылтыр-чылтыр җырын тыңладым.
Диңгез күрә олы елганы,
Ташлар ярып чыккан чишмәне
Белә микән, диеп уйладым.

Үз мизгеле

Бар гөлләр дә бермәл чәчкә атмый.
Һәрберсенең бар үз мизгеле.

Көзгеләре көзне көтеп ала,
Язны каршы ала яз гөле.

Салкын челләләрне көткәне бар,
Кышкы гөл дип атап йөртәләр.
Ә кактуслар чәчкә атар көнне
Тоташ гасыр буе көтәләр.

Кеше дә бит көтә үз чәчкәсен,
Белеп көтә ул көн киләсен.
Кеше түзем, сабырлыгы җитә,
Тик өмете хыянәт итмәсен.

Кар сулары китә

Көлә-көлә яңа язлар килә.
Карлар китә безне калдырып.
Ни өчендер, шушы «китәләре»
Йөрәгемне үтә яндырып.

Бер уйласаң, карлар нәрсә инде,
Ялкыннарга тисә — бары су.
Су гынамы? —
Китә кайтмаслары.
Озатулар барыбер ямансу.

Саубуллашып йөрим карлар белән.
Яз эндәшә: «Нигә боектың?
Күрәсеңме, үтеп китте ләса
Баш очыңнан кышкы болытың.
Күрмисеңме, әнә ничек карый
Синең йөзгә минем алтын көн.
Ишетәсеңме, колак төбеңдә бит
Яңгырап тора минем дәртле өн.

Бүләк итәм сиңа зур хәзинә,
Гүзәллекләр сиңа, ал, әйдә.
Кар суларын оныт,
Чәчкәләрнең
Исен, төсен җырлап бар, әйдә.

Барысы да сиңа, барысы да». —
Яз шулай ди ярсып, ашкынып.
Ә алдымда минем
Бер көй булып
Кар сулары ага ашыгып.

Карлар китә.
Карлар нәрсә инде? —
Ялкыннарга тисә, бары су.
«Китәләрне», кабат кайтмасларны
Озатуы барыбер ямансу.

Яшьлек төсе

Уралымда үсә карагайлар.
Җир аларны зәңгәр күкләргә
Яшел ялкын итеп чөйгән, гүя
Яшьлек төсе итеп күтәргән.

Әйтә сыман җирем бар галәмгә:
«Мәңгелек ул яшьлек: күрсеннәр,
Кешеләрем, белми картаюны,
Гел яшьлекне уйлап йөрсеннәр».

Тоташ урман аша яңгырый, гүя
Уралымның мәгъруր тавышы.
Әй тантана итә югарыда
Яшел белән зәңгәр кавышып.

Ә түбәндә — карагай тамырлары,
Калкып чыккан җирнең өстенә.
Охшап тора алар карт ананың
Кулындагы тамыр төсенә.

Җирем минем шундый:
Җиһан йөзен
Яшьлек төсе белән бизи дә,
Онытылып яши, ана кебек,
Картаюын үзенең сизми дә...

Уралымда үсә карагайлар...

Яз башы

Артка чикте карт кыш.
Килде яшь яз.
Күкрәк киереп йөри март башы.
Зур мәйданга биергә дип төшкән
Кызга охшатам бүген кояшны.

Туксан яшьлек күршем Гимай бабай
Сыйпап куя ап-ак сакалын:
— Исән булгач, балам, шөкер әле,
Менә тагы язга атладым.

Шат тавыклар көлеп карап тора
Ак әтәчнең канат какканын.
Тәүге тамчы яп-яшь борыны белән
Чукып, челтәр итә карт карны.

Кар нык әле.
Әмма тамчы көчле:
Киләчәге бар шул, куәтле...
Нәни малай чыккан яз күрергә,
Эләктереп алган көрәкне.

Чукый карны тамчы.
Үзе җырлый:
— Шатланса да язга бабаең,
Безгә кордаш,
Яңа юлда юлдаш
Кирәк тоткан шушы малаең.

Кар бөртеге хакында уйлану

Сихри бизәк,
Гади кар күзәнәк —
Кар бөртеге минем учымда.
Сөйләшәсем килә аның белән,
Күптән күргән якын дусымдай.

Тиздән эрер,
Тамчы я бу булыр...
Эрегәнче гомере бар әле,
Бар булмышы белән яши әле,
Әлегә ул үзе — кар әле.

Кар күзәнәк,
Бөек табигатьнең
Нәни генә иҗат җимеше,
Яңа елның яңа якты көнен
Үзе белән алып килеше.

Гүзәллеге кала күз алдымда,
Рәсем булып кала, җуелмый.
Кала, димәк, яңгырый бер җыр булып
Сандугачның сихри моңыдай.

Һәр тарафны ничек таң калдырып,
Аклык булып баккан дөньяга.
Зур кояшны хәтта гашыйк итеп
Сафлык булып баккан дөньяга.

«Һә» дигәнче менә күз алдымда,
Җылы учымда карым эреде.
Яңа ел таңында
Тик уемда
Сихри бизәк сүнмичә йөрде.

Мин үзем дә, хәер, Җир учында
Түгелмени шундый күзәнәк?
Тик бер балкып,
Тиз үк сүнәремне
Ул да микән шулай күзәтә?

Ә миңа соң шуны уйларгамы?
Сүнгәнче бит гомер бар ласа.
Мин яшәрмен Җирдә аклык калса,
Җыр яңгыраса Җирдә,
Җыр калса.

Көз балкуы

Көзге урман үзе бер могҗиза.
Җәйгесен син аны тоймыйсың.
Җирнең бөтен яме, матурлыгы
Чәчкәле җәй, диеп уйлыйсың.

Гөл-чәчәкләр шиңә,
Көзләр килә.
Шулчак урман әйтә үз сүзен:
Үзенчә бер сихри төсләр белән
Әй балкытып ала җир йөзен.

Ныклабрак баксаң, урмандагы
Көз төсләре хәйран калырлык.
Гөлләмәләр ясап яфраклардан,
Нур балкытып туйга барырлык.

Тик бу балкыш түгел бик озакка.
Хикмәт мени озак балкуда?
Бөтен хикмәт: җәең үтеп киткәч,
Аз гынага җирне кабат ямьләп,
Бер гөлләмә булып калкуда.

Тынлык

Агачларны ап-ак карлар сырган.
Тып-тын булып калган бар урман.
Хуҗа монда бары тынлык, тынлык.
Үзе бер музыка бу тынлык:
Әллә нинди залны шаулатырлык
Зур оркестрларга торырлык.

Кар шыгырдап куйды. Сискәндереп
Кош сайрады.
Сабыр, сабыр ит!
Дертләп куйды күңелем, шул тынлыкны
Кемдер хәзер тартып алыр дип.

Чак кынага сабыр! Ә аннан соң
Бар урманым, әйдә, шауласын.
Кыш көне дә урман кошсыз түгел,
Әйдә, кош та ярсып сайрасын.
Тик әлегә, менә чак кынага
Килә минем тып-тын каласым,
Тынлыктан җыр-моңнар аласым.

Туган ягым

— Туып-үскән ягың нинди? — дисең.
Туган ягым,
Туган ягыммы?
Акланнары аның хәтерләтә
Яшел палас җәйгән табынны.

Карт имәннәр утыра эре генә
Кодалардай табын түрендә.
Ак каеннар алар эргәсендә
Кодачалар кебек күренә.

Шомырт куаклары, кызлар сыман,
Төренәләр ап-ак ефәккә.
Шаян бөрлегәннәр бөгелә-сыгыла
Серен сөйли анда җиләккә.

Сандугачлар сайрый.
Шундый җирдән
Сандугачлар читтә булырмы?!
Җирне, җырны сөйгән юлчы монда
Туктап яллар итми узармы?!

Йөгерә сыман иген дулкыннары,
Ә үзләре җиргә тотынган.
Тагын алар миңа әйтә сыман:
«Аерылма җирдән, шушыннан...»

Тауларымы? Бар, бар.
Берсе аның
Күкрәккәйтау дип атала.
Борын-борыннан ук телдән-телгә
Чишмәләре белән мактала.

Таң атканда шушы чишмәләрнең
Җиргә ятып җырын тыңладым.
«Алтын җирдә туып үскәнмен», — дип,
Куанычтан ярсып җыладым.
Җыладым да шушы тавымдагы
Чишмәләргә кушылып җырладым.

Менә шундый минем туган ягым.
Чакырам сине шунда, туганым.

Акыллырак мәллә?

Кешеләрдән акыллырак мәллә
Агачлар, дим.
Үсәләр дә карап югары,
Күккә үреләм дип,
Үз җиреннән
Аерылганнары юк әле.

Ә кешеләр,
Онытып үз асылын,
Дым-сутсыз ук торып калырын
Уйламыйча,
Җирдән аерыла
Һәм югалта яшәү тамырын.

Туган өен оныта,
Телен оныта,
Эчкән суын, җыйган ризыгын.
Әйтерсең ул инде күк баласы —
Ашып китә чама сызыгын.

Һәрбер яфрак үзенең төсен саклый —
Табигатьтә күпме тугрылык.
Ә кешеләр керә ничә төскә —
Гаҗәпләргә калып торырлык.

Кеше иканлеген оныта хәтта,
Язмышына куя төкереп.
Ә соңыннан: «Нәрсә эшләдем?» — дип,
Кылганына йөри үкенеп.

Кешеләрдән акыллырак мәллә
Агачлар, дим.
Ирексездән шуны уйлыйсың.
Табигатьнең иң камиле, кеше,
Нигә алай, онытып асылыңны,
Үзең белән үзең уйныйсың?.

Кояш кошы

Гыйнварның әче чилләсендә
Иртә белән бер үк сәгатьтә
Билгесез бер кошның җырын тыңлау
Кереп китте минем гадәткә.

Күренми дә, үзем күрмименме,
Күз ягыннан булмый мактанып.
Агачына төшкән кояшны ул
Каршы ала сайрап, шатланып.

Хикмәтмени үзен күрүемдә,
Сайравы бит хикмәт — кояшлы.
Кояш төшү белән җыр башлана:
«Әллә, — димен, — сайрый кояшмы?»

Кояш барда гына сайрый да ул,
Кояш китү белән югала.
Болыт көнне, сәер, сайрамый кош,
Кояш кошы дидем шуңа да.

Сокландым мин: кышкы чилләдән дә
Кояш табып сайрау — батырлык.
Бәлки, язлар бер дә килмәс иде,
Китермәсә шулар чакырып.

Соңгы яшеллекнең авазы

Кинәт кенә салкын җилләр исте.
Дертләп куйды яшел яфраклар.
Әйтте алар:
«Көз, юк, ашыкма әле,
Безнең әле яшәр вакыт бар.

Йолыкмачы яшел җәебезне,
Һәр минуты безгә кадерле.
Болай да бит гомер, һай, бик кыска,
Өзгәләмә әле бәгырьне.

Без сөйликче әле бергәләшеп
Җиргә җәйнең сөю сүзләрен.
Күзәтикче әле тып-тын калып
Йолдызларның сихри күзләрен.

Балкытыйкчы җәйнең бар ямьнәрен.
Ашыкма, көз, килер үз мәлең.
Күреп туйганмыни әле дөнья
Җәй-җиңгине — җирнең гүзәлен.

Өркетмә әле җырчы кошыбызны,
Бер сайравы аның ни тора.
Талпынуы була бер тирбәлеп —
Бар бакчаны моңга тутыра...» —
Җәй эндәшә көзгә.

Аңласа да
Соңгы яшеллекнең телләрен,
Көз-әбекәй мыштым-мыштым гына
Җир-сәкегә яңа урын түши,
Кабарткалап сары мендәрен.

Әби. Кәҗә. Ташлытау

Зур да түгел, үзе күркәм, мөлаем —
Бер авыл бар Нөгеш буенда.
Сыенган ул, назлы кәләш сыман,
Ташлытауның җылы куенына.

Ә Ташлытау каен-карагайлы
Карурманга китә кушылып.

Нәбирә әби яши шул авылда
Шөкер итеп барына, хуш кылып.

Балалары илнең күп ягында,
Таралышты — нихәл итәсең.
Чакырдылар, шундый җәннәт җирне
Ничек итеп ташлап китәсең?
Янында бар дусы — ак кәҗәсе:
Печән көйши, чәйлек сөт бирә.
Ил инәсе булып яшәп ята —
Авыл күрке, диләр, Нәбирә.

Тик ак кәҗә беркөн гаеп булды,
Суга төшкән кебек югалды.
«Ташлытауда гына йөри иде.
Әй ходаем, ахры, бүре алды!»

Әй каргады әби, әй каргады
Бүреләрнең ата-бабасын:
«Байныкына тими, бер кортканың
Бердәнберен, кыргыр, аласың».

Эзләренә текләп кәҗәсенең,
Эзләмәде түгел, эзләде.
Өмет өзде.
Менә үтеп китте
Сөтсез җәе, сөтсез көзләре.

Бирәм дисә, китереп бирә икән —
Шунда булды моның мәзәге:
Тәүге карга тәүге эзләр салып,
Кайтып керде беркөн кәҗәсе.

Үзе генә түгел,
Өчәү булып —
Әнә тора ничек мекердәп.
Бәрәчләрнең матур күзләренә

Карады да әби, җылады.
Көлеп куйды шуннан кеткелдәп.

«Тимәгәннәр...
Бүреләр дә изге.
Ташлытавым, изге икәнсең...
Чакырдылар...
Шушы изге җирне
Ничек итеп ташлап китәсең.
Кәҗәкәем миннән бәхетлерәк:
Балаларын алып кайталган.

Әллә ниләр бирер идем хәтта,
Йөгереп кенә барып, балаларны
Авылыма алып кайталсам».

УТЛЫ ЕЛЛАР ҮТӘ ЙӨРӘК АША

Умырзая белән сөйләшү

Шамун Фидаига багышлыйм

— Җир туңы да эреп бетмәгән бит,
Як-ягыңда калын кар ята.
Элпә генә ап-ак чәчкәләрең
Һәр тарафка сибеп яшәү дәртен,
Бар галәмне үзенә карата.

Салкын бозны тишеп чыккан чакта
Туңмадымы япь-яшь сабагың?
— Туңулардан куркыр түгелмен мин,
Бозлар аша, менә яңа язга
Тәүге чәчкә булып багамын.

— Андый көчне кайдан алдың, чәчкәм?
Кайдан синдә андый батырлык?
— Тәүге булу — көчем, кыюлыгым
Мең-мең гомерләргә торырлык.

— Бозлар аша ямьгә юллар ярдың,
Тәүге назын алдың кояшның.
Умырзаям, бөек эшең булып,
Гомереңнең якты төсе булып
Язым яши, – язны уяттың...
Карлы-бозлы, утлы юллар ярып
Ерак-ерак китә уйларым.
Хәтерләтә гомерең җир йөзенә
Тәүге булып язлар алып килгән
Яшьли киткән илем улларын.

Сөйлә, әнкәй, әткәй хакында

Тумый калды...
Туктар вокзалларга туктамыйча,
Эшелоннар чабып уздылар.
Эшелоннар ярып үткән җилгә
Ана толымнары туздылар.

Күреп калмаммы дип кәтә-кәтә
Ана керфекләре талдылар,
Эшелоннар үткән рельсларга
Тәгәрәшеп яшьләр тамдылар.

Йөкле ана шулай күз талдырып
Күпме составларны озатты,
Исән булса кайтыр, кайтыр, диеп,
Үз күңелен үзе юатты.

Әйе, тумый калды...
Рельслардан узган эшелондай
Еллар һаман алга чаптылар.
Бала туды.
Сабый карашлары
Ана күзләренә бактылар:

— Сөйлә, әнкәй, әткәй хакында...
Сөйлә инде тагын, тагын да...

Ана күңеле аша эшелоннар
Дөпелдәшеп чабып уздылар.
Рельслар итеп гомер җебен
Һаман алга, алга суздылар.

Үсте малай.
Кайтты мәктәбеннән
Ал галстук бәйләп муенына:
— Сөйлә, әнкәй, әткәй хакында, — дип
Сыенды ул ана куенына.

Бүген алар өчәү:
Ана, улы
Һәм оныгы — әнә баралар.
Ак толымын сирпеп чабып узган
Составларга карап калалар.

Улы һаман сорый:
— Сөйлә, әнкәй,
Сөйлә инде әткәй хакында...
Ана күңеле аша
Солдат төяп
Эшелоннар үтә тагын да.

Илдә ир-ат бар

Явыз сугышларын каргый-каргый,
Чалгы тапар кеше таба алмый,
Авыл буйлап йөргән еракмы?..
Әле менә күреп шатланам
Һәрбер өйдән, һәрбер капкадан
Атлап чыгып килгән ир-атны.

Нәниләргә «әткәй!» дияргә,
Әбиләргә «бәбкәм» дияргә
Сөлек кебек таза ир-ат бар.
Мәҗлесләрдә ашлар бүләргә,
Олы киңәш сорап килергә
Һәрбер өйдә ир-ат, ир-ат бар.

Сөенегез, әйдә, хатыннар,
Сөелегез, әйдә, матурлар,
Арысландай асыл ир-ат бар.
Елмаегыз, әйдә, сабыйлар,
Куаныгыз кала-авыллар,
Куаныгыз: илдә ир-ат бар!

Типсә, тимеренне өзәрлек,
Эше белән дөнья бизәрлек
Алтын куллы батыр ир-ат бар.
Ир-ат булган өйнең яме бар,
Ашар ашларының тәме бар.
Нинди куаныч: илдә ир-ат бар!

Таллар тып-тын...

Су таралган таллар арасына.
Таллар тынган.
Алар ни тыңлый?
Минем җаным гына диңгездәге
Дулкын сыман ярсу, һич тынмый.

Су эчендә калган яшел таллар
Малай чагым мәллә югыйсә?
Китап-дәфтәр тулы букча асып,
Уразай-тугай аша су кичә?

Таллар түгел алар — әллә инде
Авылымның зифа кызлары?

Кер чайкыйлар мәллә Күндерәгем
Ташып чыккан мәлдә язларын?

Зифа таллар әллә җиңгәмнәрме
Яуга озатып калган ирләрен?
Ил язмышы итеп зәңгәр күкне
Күтәргәнме әллә иңнәре?

Түгел, түгел...
Таллар таллар гына.
Тик йөрәктә сүнмәс куз ята.
Таллар тып-тын.
Мин бит үзем һаман
Гомерем учагында базлап торган
Кисәүләрне кабат кузгатам.

Икмәк

Авыз тутырып икмәк капкан саен,
Әнкәм сүзе килә хәтергә:
«Ватмый аша, балам, икмәгеңне.
Валчыгын да аның кадерлә».

Ул вакытта, бәлки, икмәк ягы
Булгангадыр артык кысынкы,
Бишебезгә бүлеп биргәнгәдер
Беребезгә җитмәс сыныкны,

Әнием безгә шулай дип әйткәндер.
Сабый чак бит, аңлап җитмәссең.
Азмы булган алар дәверендә
Җир сыкраган чаклар икмәксез.

Әмма сүзләрендә әнкәемнең
Тик мохтаҗлык кына чагылмый.
Икмәк кадерен белү күңелемә
Сеңгән шулай сабый чагымнан.

Гади икмәк кадере,
Шул икмәкнең
Нинди җирдә, ничек үскәне,
Игенченең тире еллар аша
Кырау булып чәченә кучкәне

Таныш миңа.
Таныш. Күз алдымда
Әтиемнең арып кайтканы,
Көн буена иген игеп, тиргә
Якасының каеш катканы.

Көнгә ярылып көйгән иреннәре,
Сөялләнеп беткән куллары.
«Икмәк кадере», — дигән чакта гелән
Хәтерлимен әнә шуларны.

Икмәккә юк хәзер мохтаҗлык та,
Бары да бар, җитеш тормышым,
Нәрсә тотсам, шуңа кулым бара,
Күңел дә көр, иркен сулышым.

Ә шулай да,
Икмәк капкан саен
Әнкәм сүзе килә хәтергә.
Шул сүз китми һич тә колагымнан:
«Валчыгын да аның кадерлә!»

Хәтерләтә

Һич тә көтмәгәндә карлар явып,
Яшел яфракларга сарылды.
Агачларның башын җиргә иеп,
Урамнарга ятты сырынты.

Кар кҮтәрер өченмени инде
Шундый нәфис яшел яфраклар?!
Үткәннәрне сөйләп, җирдә ята
Каерылып төшкән ботаклар.

Яшел яфрак сыман чаклар иде...
Сугыш-афәт җанны тетрәтте.
Каерылып төшкән ботак сыман,
Яшьтәшләрне сугыш имгәтте.

Хәтерләрне карлар күмә алмый:
Чәнчеп куя йөрәк, әченеп.
Агачларны кагып йөри кешеләр.
Урам кала кардан әрчелеп.

Авырлыгы төшкәч иңнәреннән,
Торып баса агач тураеп.
Тик ботаклар сынган, җирдә кала,
Өемнәргә өелә туралып.

Әниемнең гадәте

Таңнан торып әниемнең
Салкын мичен якканы,
Чи утынның, булар бөркеп,
Чарт-чорт килеп янганы,
Таңнан торып,
Без, сабыйлар,
Тезелеп утырганнар
Күз алдында,
Күз алдымда
Сабый чактагы таңнар.

Ашыга-ашыга киенер дә
Әнием китәр иде,

Салкын магазин төбендә
Ул икмәк көтәр иде.

Чарт-чорт килгән утыннарга
Ялкын йөгерер иде.
Тәрәзләрдәге боз-үлән
Эреп, терелер иде.

Менә берчак ишегебездә
Әнкәй күренер иде,
Йөзебезгә, күзебезгә
Шатлык сибелер иде.

Уч аядай кара икмәк
Бишкә бүленер иде.
Безнең куллар тыйнак кына
Шуңа үрелер иде.

Чи утыннар күптән янды, —
Бик еракта калганнар.
Ә йөрәктә,
Күз алдымда
Сабый чактагы таңнар.

Әле дә мин таңнан торам,
Гүя мин дә мич ягам.
Чи утыннар чарт-чорт килә...
Мин таңда шигырь язам.
Мичем кыза. Тәрәз эри —
Боз-үләннәр терелә.

Юк, мич түгел, үзем янам,
Таңым — шигырь сәгате.
Сабый чактан калган, ахры,
Әниемнең гадәте.

Төнге авазлар

Бүген төндә йоклый алмый яттым.
Ишетелә төрле авазлар.
Төнге юлчы сыман, төнге уйлар
Күңелемнең ишеген кагалар.

Өске катта тора яшь гаилә —
Күптән түгел генә арттылар:
Ата-ананы төнен биетергә
Бер музыка алып кайттылар. —
Бала елый.

Төнен бала елый.
Күзе кара булыр, еласын.
Көләр чаклары да җитәр әле,
Ата-ана, әйдә, чыдасын.
Яшь ана ни һаман: «Бәлли-бәү», — ди.
Колагыма керә шул аваз,
Күңелемә керә татлы наз.

Бер ягымда минем артист тора,
Матур-матур көйләр уйната.
Төшләремдә гармун уйнаттырып,
Уята да мине, уйлата.

Бу да бер наз минем күңелемә.
Шундый музыкалар тыңлап кына
Яшәсәмче, димен, гомеремә.
Ә юк,
Менә каршы стена аша

Ыңгырашу авазы ишетәм.
Гарип күршем култык таякларын
Тукылдатып төнен ишектән
Үзе килеп керер сыман була.
Ыңгыраша, сызлый аягы.

Чирек гасыр тешен кыса-кыса,
Тузып беткән инде яңагы.

Ыңгырашу тына.
Шөкер, димен,
Тынып кына азрак йокласын.
Тагы бала елый.
Анасының
Кочагында, әйдә, еласын.
Үскәч көлсен, әйдә, елмайсын.
Артист сыман гармун уйнасын,
Моңга күмсен бөтен дөньясын.
Ыңгырашмасын, берүк,
Җырласын.

Ә хәзергә,
Әйдә, еласын —
Ана кочагында еласын.

Таштагы чәчкәләр

Баллада

Ташлар, ташлар...
Крепость бу.
Тын калган уйчан ташлар.
Шушы ташның асларында
Югалган газиз башлар.

Югалмаган, шөһрәтләре
Күтәрелгән югары:
Корыч калкан була алган
Ил-ананың уллары.

Минем алда Брест-герой
Сәхифәләрен ача.

«Без өчәүбез. Без үләбез.
Үләбез батырларча...» —

Уеп язган бер таш ята
Каршымда — тере сыман:
Корбан булган егетләрнең
Гүя бар серен җыйган.

Бу сүзләрне язган егет,
Учка салып йөрәген,
Кемгә әйтсен,
Кемгә ачсын
Соңгы сүзен, теләген?

Ташка әйткән.
Ташлар, ташлар...
Тын калган уйчан ташлар.
Таш астында газиз башлар.
Баш ия ватандашлар.

Ташка уеп язган гына
Соңгы сүз булмагандыр.
Батыр егет тагы нидер
Әйткәндер, уйлагандыр.

Бу ташларга күпләр килде.
Коралдашлары килде:
«Егет соңгы сулышында
Тагы ни әйтте?» — диде.

Кызлар килде —
Исән булса,
Яр да булырлар иде:
«Соңгы минутында егет
Ни диде? Нәрсә диде?»

Уйчан ташлар эндәшмәде.
Килгәннәр ары китте.
Уеп ташка язылганны
Замана тарих итте.

Кара шәл салып иңенә
Беркөнне килде әнкә.
«Улым кайда?» — дип сорады,
Ташларга салды чәчкә.

Шунда ташлар ачылдылар,
Ташлар да телгә килде:
— Соңгы сулышында улың:
«Әнкәм, кадерлем!» — диде.

Брест ташларына ятып,
Әнкә кайнар яшь түкте:
«Балам, бәгърем, синме бу?» — дип,
Брест ташларын үпте.

Туган көнендә улының
Һәр елны килде әнкә.
Кырык ел буе ташларга
Ул салды алсу чәчкә.
Кырык ел буе шушында
Кайнар яшьләрен түкте.
«Балам, бәгърем, синме бу?» — дип,
Брест ташларын үпте.

Быел әнкә килалмады —
Ул дөнья куйды үзе.
Чәчкәләрен без китердек:
Чыклар булып яше тама, —
Чәчкә ул әнкә күзе.
Ташларга әйтер сүзе...

Ташлар, ташлар...
Уйчан ташлар.
Ташта — мең-мең чәчкәләр.
Җирдән китми, чәчкә булып
Көнгә бага батырларны
Илгә биргән әнкәләр.

Дулкыннар сөйли

(Волга дәфтәреннән)

1. Олы ярлар буйлап

Агыйделем инде артта калды,
«Тукай» яра Волга суларын.
Дулкын-дулкын булып чабып китә
Ерак-еракларга уйларым.

Шушы ярлар буйлап агып үткән
Күпме аһ-зар, күпме каргышлар,
Хакыйкатьне даулап, бәхет яулап,
Өзелеп калган күпме язмышлар.

Бурлакларның үзәк өзгеч моңы
Кала сыман бермәл ишетелеп.
Еллар булып ярга дулкын кага,
Иске ярлар төшә ишелеп.

Күз алдымда менә яңа ярлар,
Шат авыллар,
Якты калалар.
Һәйкәлләрне төргән бакчалары
Сәлам биреп озатып калалар.

Ак дулкыннар ашыга зур ГЭСларга,
Әверелергә тизрәк нурларга.

Кан-яшь булып аккан иске Волга
Бүген керә безнең җырларга
Елмаючы дулкын һәм нур булып,
Йөрәк кагышы булып Илемнең.
Волга, Волга!
Халкым күкрәгендә — көч-куәтең,
Халкым күңелендә — киңлегең.

Агыйделем инде артта калды.
Алда ята зәңгәр юлларым.
Агар сулар киңәйгәнгә микән,
Киңәйгәндәй булды уйларым.

Әмма күңел үзенекен итә:
Юлга чыкканга да аз гына,
Яшел яулык болгап озатып калган
Агыйделне инде сагынам.

Чү! Туктале,
Әнә йөгерә ләса
Агыйделдән килгән дулкыннар.
Ничек бара алар, ярсып-ярсып,
Аларда да колач, куәт бар.

Алар гүя мине сәламлиләр,
Сүз кушалар гүя;
«Без монда
Күп елгалар кушылып, киңәйтәбез
Зур Иделне.

Һәрбер дулкында,
ГЭСлар Илгә биргән ак нурларда
Балкый безнең уртак йөзебез.
Бердәм гайрәт белән колачлыбыз,
Бердәм куәт белән көчлебез.

«Тукай» бара зәңгәр юллар ярып,
Шагыйрь исемен әйтеп портларга.
Мин таң калып киләм һәйкәлләргә,
Зур Иделгә баккан йортларга.

Агыйделем бара минем белән,
Ишетәм аның дулкын кагышын.
Эх, кушасым килә зур Иделгә
Бер җыр итеп аның тавышын.

2. «Улым, бүген Волга ни төстә?..»

Волга яры буйлап көймә килә,
Көймә килә салмак тирбәлеп.
Канат җилпеп оча акчарлаклар,
Акчарлаклар оча кинәнеп.

Ә көймәдә икәү:
Кара тасма белән
Күзен бәйләп алган бер бабай,
Тәү кат канат каккан яшь бөркеттәй,
Ишкәк ишеп барган бер малай.

Бабай уйчан,
Нидер тыңлый сыман,
Дулкын моңын тыңлап барамы?
Шушы ярлар буйлап күкрәү булып
Үткән гомерен искә аламы?

Малай ишә.
Бабай сорап куя:
— Волга бүген, улым, ни төстә?
Соңгы кабат мин күргәндә ул бит
Кызыл иде...

Улмы, ул кичтә...
Сталинградка ул көн фашистларның
Гарасаты килде ажгырып.
Ил-анабыз оран сала иде
Оланнарын яуга чакырып.
«Яшәү яки үлем!» —
Бары шуны
Сугышчылар алла иттеләр.
Күпме ирләр йөрәк каны белән
«Җиңү!» сүзен язып мәңгелеккә,
Мәңгелеккә җирдән киттеләр.
Яна иде ул көн монда ташлар,
Яна иде Волга сулары.
Таш янганда, тимер бөгелгәндә,
Бөгелмәде Илнең уллары.

Утлы дулкыннарны яра-яра
Ул ташыды яшәү бу ярга.
Шул кичтә дә ядрә килә иде
Фашистларны ныграк «сыйларга».

Менә-менә, яр бик якын иде,
Баржа янды, баржа шартлады.
Ярсып-ярсып янды Волга суы,
Һәр тарафны ялкын ялмады.

Хәтерендә салкын землянкада
«Су, су!» — диеп көеп ятканы.
Аның өчен кояш мәңгелеккә
Кабат чыкмас булып батканы...

Бабай уйчан.
Йөрәген авырттырып
Бары да үтә кат-кат тезелеп.
— Бүген, улым, Волга нинди төстә? —
Тагын сорый, сорый өзелеп.

— Зәңгәр төстә, бабай,
Аңа юл салынган
Тасма булып кояш нурыннан.
Без барабыз шушы нур-тасмадан,
Без барабыз кояш юлыннан...

— Кояш юлыннан?
Якты, матурдыр ул.
Тоеп торам аның җылысын...
Бабай уйчан.
Дулкын моңы аның
Телеп үтә йөрәк ярасын.
Көймә килә.
Зәңгәр дулкыннарга
Салмак кына килә бәвелеп.
Акчарлаклар оча канат җилпеп,
Акчарлаклар оча кәелеп.

3. Бәвелчәк бәвелгән бакчада

Яшь разведчик Саша Филипповны фашистлар җәзалап, асып үтергәннәр. Волгоградның шул урынында хәзер бакча.

Бәвелчәк бәвелтә балалар
Гөлләргә күмелгән бакчада.
Бәвелчәк, шыгырдап, күңелгә
Ниндидер бик сәер моң сала.

Бәвелчәк бәвелтә балалар
Кошлардай чыркылдап, ут яныл.
Ә култык таяклы бер агай
Аларга караган укталып.

Бәвелчәк шыгырдый — җырлыймы?
Әллә ул үзенчә җылыймы?
Таяклы бу кеше, тукталып,
Үткәннең юлларын юллыймы?

...Нәкъ менә шушында фашистлар
Сашаны асканнар, дар ясап.
Бәвелчәк моңына ачыла
Йөрәктә уңалмас җәрәхәт.

Коточкыч дәһшәтле көннәрдә
Саша бит шуышкан шул җирдән,
Фашистлар тылыннан штабка
Бик кирәк хәбәрләр китергән.

Сашаның саф гөлдәй гомере
Бөредә көенчә өзелгән.
Бу җирдән баш салып узыгыз,
Ул менә шушында күмелгән.

Дар булган урында бәвелчәк...
Гөр килеп уйныйлар балалар.
Бәвелчәк шыгырдый, моң сала.
Әрни шул уңалмас яралар.

4. Исемнәр

Искә алу залы.
Нәүбәт җитә.
Кереп тулды тагын кешеләр —
Заман йөген бүген иңгә салган
Синең белән минем ишеләр.

Кешеләр
Шул минутта өскә шинель киеп,
Постка баскан солдат төслеләр.

Зал тын.
Җирдән күтәрелгән кулда
Тере ялкын гына гөлкелди.
Күкрәкләрне бәреп чыгар булып
Йөрәк кенә дөп-дөп дөпелди.

Зал эндәшми.
Эндәшмиме?!
Эндәшәләр меңнәр, йөз меңнәр;
Мамай курганында
Стенага
Уеп язган үлмәс исемнәр.
Эндәшмиме?!
Йөрәгем ярсып сорый:
— Исемнәр!
Сез кемнәр?!
...Васильев, Титов, Искәндәр...
Соликидзе, Ломако, Алтынбай...
Эндәшәләр миңа бер хор булып,
Тавышлары корыч чыңыдай.

Эндәшмиме?!
Исемнәргә карап
Ана сөртә кайнар яшьләрен,
Чәченә чал төшкән чибәр хатын
Стенада күрә сөйгән ярын,
Өйләналмый киткән яшь ярын.

Алтын йолдыз таккан бер узаман
Исемнәрдән эзли атасын,
Бер яшүсмер эзли картәтисен.
Исемнәр, исемнәр...
Сөякләре
Бар дөньяга таныш бу курганның
Кайсы катламында ята соң?!

Зал тын, тып-тын.
Кеше кулы тоткан
Тере ялкын гына гөлкелди.
Күкрәкләрне ярып чыгар булып
Йөрәк кенә дөп-дөп дөпелди.

Ул эндәшә:
— Исемнәр, исемнәр?!
Сез кемнәр, без кемнәр?!

5. Юлдаштыр гомергә

Көн дими, төн дими,
Йөзәбез җай гына.
Ашкынам, кош сыман,
Мин туган ягыма.

Волгадан, Камадан
Күп сәлам алганмын.
Сагынып киләмен
Агыйдел ярларын.

Кич килде офыкка.
Ябынып ал шәлен.
Агыйдел каршылый
Кабызып ак шәмен.

Ямь-яшел ярлар да
Бик якын, бер колач,
Өздереп-өздереп
Сайрый бер сандугач.

Һәм аңа кушыла
Мең кошы урманның.
Бу нинди тойгы син,
Күңелдә уяндың?

Туган як кош булып
Эндәшә күңелгә.
Бу тойгы кешегә
Юлдаштыр гомергә.

ЯНДЫР ЯКТЫ ШӘМНӘРЕҢНЕ



Сөю сүзе

Мин тугач та, кояш көлә-көлә
Бишегемә иелеп караган.
Тормышны сөй, диеп, назлый-назлый
Чәчләремнән сыйпап тараган.

Зәңгәр күгем үпкән күзләремнән,
«Төсем синдә, — дигән, — онытма».
Сандугачлар әйткән тәрәз аша:
«Җырлап яшә, — дигән, — боекма».

Төннәрендә ай да юрган итеп
Нурын япкан, әйткән: «Өшемә».
Йокласам да янда саклап торган,
Елмайганмын аңа төшемдә.

Минем белән бергә аунап үскән
Болыннарда шаян чәчкәләр.

Шулар бары да минем күңелемә
Сөю орлыкларын чәчкәннәр.

Шуңа, ахры, якты кояш нурын
Кара болыт килеп капласа,
Йөзләремә күчә караңгылык.
Көлеп торган чәчкә тапталса,

Гөлнең күзләреннән яшьләр тамса,
Минем йөрәгемнән кан тама.
Алар көлеп торса,
Җырлап торса,
Минем өчен дөнья — тантана.

Кешеләрнең җылы карашында
Кояш кайнарлыгы бар сыман,
Күңелләрдә яткан яхшылыклар
Чәчкәдәге татлы бал сыман.

Ташларны да хәтта эретер сыман
Кешеләрнең җылы карашы.
Кешеләрнең шушы саф карашын,
Күңелләрдә яткан бал кәрәзен
Бөтен җир шарына өләшә-өләшә
Эх, барасы иде, барасы!

Тик күр генә

Авыр язмыш башларыңны
Игән чакта,
Барысы да бетте, диеп
Йөргән чакта,
Утыр, уйла,
Сукыр булма!
Як-ягыңа күзеңне сал:
Күпме дуслар.

Кайгыларың күтәрешер
Әнә шулар.
Тик күр генә,
Тик бел генә.

Бөтен эшең барган чакта
Гөрләп алга,
Исемеңне күтәргәндә
Даннан-данга,
Утыр, уйла,
Сукыр булма.
Як-ягыңа күзеңне сал:
Күпме дуслар.
Бары шулар белән данның
Кадере бар.
Тик күр генә,
Тик бел генә.

Йөрәгеңә юлдаш тапмый
Йөргән мәлдә,
«Мәхәббәтем, кайда син?», — дип
Җилкенгәндә,
Ян һәм уйла,
Сукыр булма.
Як-ягыңа күзеңне сал:
Күпме дуслар.
Арасында сине сөйгән
Берәүсе бар.
Тик күр генә,
Тик бел генә.

Нур

Икебез дә калдык күләгәдә.
Арабыздан тик бер нур үтә.
Без бакканбыз аңа:

Бары шул нур
Юаныч та безгә, өмет тә.

Артта — хата.
Шул хаталар өчен
Җәберләшсәк, һич юк кавышу.
Колак төбеннән һаман китми сыман
Үткәннәрнең әче тавышы.

Икеләнеп шулай торган чакта,
Бала килеп керде нур булып:
— Әткәй! Әнкәй!
Нур таралды өйгә,
Шик-шөбһәләр бары да җуелып.

«Әткәй! Әнкәй!»
Калды күләгәләр.
Без атладык шулчак нур аша.
Язмышлар бит түгел күләгә аша,
Якты нурлар аша тоташа.

Ярата — көтә

Ян тәрәзгә кемдер килеп
Кагылды мәллә?
Бакча яклап кече капка
Ачылды мәллә?
«Аның аяк тавышлары
Ишетелде бугай...» —
Кызның йөрәгендә ярсып
Бер давыл дулай.
Ярата — көтә.

Оялчан йөз сыман, әнә,
Алсу кызарып,
Шәфәкъ тә бит кулын салды

Офыкка барып.
Тәрәзләрдә нурланышып
Кабынды утлар.
«Менә килер, менә керер...» —
Татлы минутлар.
Ярата — көтә.

Кичке тынлык һәр тарафка
Бер моң тарата —
Япь-яшь ана кечкенәсен
Назлый, ярата:
«Йокла, балам, йом күзеңне.
Әлли-бәлли, бәү...» —
Көндезен дә, төннәрен дә
Гөрләшә икәү.
«Бу минутта әтиеңнәр
Кайларда икән?

Диңгезләрдә йөзә микән,
Тауларда микән?
Тыным белән тартып алып
Булмый шул, балам.
Белмисең шул, бәләкәчсең,
Сагынам, янам...»
Ярата — көтә.

«Көне җитә, солдаткынам
Кайтыр бер, кайтыр.
Таңгы сандугачым булып
Сайрап уятыр.
Көндәй балкып, ул елмаеп,
Керер ишектән.
Ул да сагына — йөрәгенең
Тибешен ишетәм...»
Ярата — көтә.

Чәчләренә көмеш ялкын
Ялатты инде.
Кошчыкларын төрле якка
Таратты инде...
«Исән генә йөрсеннәр, — ди, —
Балакайларым...»
Көнен саный, төнен саный,
Саный айларын.
«Әнкәм, бәгърем...» диеп иртән
Яңгырый җырлар.
Ике күзе гел тәрәздә:
Менә кайтырлар...
Тарата — көтә.

Ярата — көтә...
Тарата — көтә...
Хатын-кызның бу сыйфаты, —
Ахры, бер тылсым.
Шуннан башка без — ирләрдә
Нинди ут булсын?
Йөрәкләрдә ике канат:
Көтү — ярату.
Шул булмаса, булмас иде
Җирдә таң ату.

Юлда

Бер әбекәй калды кул күтәреп —
Утыртмады шофер, ашыкты.
Үзсенмәде, ахры, бөкрәйгән һәм
Йөзе җыерчыклы карчыкны.
Очрады аңа бер чибәр кыз —
Елмаюы үзе ни тора:
Назлы керфекләрен сирпә-сирпә
Эргәсенә шул кыз утыра.

Ә машина җилә.
Егет өчен
Сикәлтә юк юлда,
Урау юк.
Көннәр буе арып килгәнен дә
Онытты ул, аны уйлау юк.

Төшеп калды сылу рәхмәт әйтеп.
Карап калды егет укталып.
Карап калды,
Кызый ары китте —
Матурлыкны булмый туктатып.

Җилә егет.
Килә күз алдына
Әбекәй торып калган тукталыш.
Җилә егет, уйлап килә егет.
Күңелендә яңгырый бер тавыш:

«Нигә утыртмадым әбекәйне?..»
Намус өйки егет бәгырен:
«Торып кала микән шулай чатта
Бердәнберем, әнкәм, кадерлем?..»
Борыла да егет кире җилә.
Тик әбекәй киткән, күренми...
Яшьлек җилкенүе тиз сүнсә дә,
Намус газабы шул сүрелми.

Нишләтим соң сине?

Җитте сиңа ярсып, шашып чабу! —
Авызлыклап куйдым йөрәкне.
Авызлыкка гына юк ышаныч,
Йозаклап ук куйдым күкрәкне.

Торып калдым үзем тар бүлмәдә,
Ишекне дә тыштан бикләттем.
Һәм гакылны шунда сакка куйдым.
Ни могҗиза, нинди хикмәттер:

Тәрәз аша керде бер моң булып
Бер яшь кызның кычкырып көлгәне,
Тавышның иң сафы — ничә еллар
Хыялымда гына йөргәне.

Авызлыгын чәйнәп өзде йөрәк,
Челпәрәмә итеп күкрәкне,
Бөркет булып очты тәрәз аша,
Тәүге күкрәү булып күкрәде.

Кыз янына килде егет булып,
Салып ташлап еллар чылбырын,
Ул укыды аңа үз шигырен,
Ул җырлады аңа үз җырын.

Кызның күзләреннән чаткы алып,
Ул тотынды дөрләп янарга,
«Сөям» дигән сүзне ишетер өчен
Әзер иде көлгә калырга.

Шашкын йөрәгем, синең белән миңа
Ничек итеп дөнья көтәргә?
Сине, дускай, мөмкин көл итәргә,
Мөмкин түгел тоткын итәргә.

Мәхәббәт диалогы

— Берәү сине, коры кеше, диде,
Аңа сөю-назлау ят, диде,
Ул алдаган яки аңламаган.
Бар булмышың менә наз инде...

— Сатып алып булмый назны, дускай,
Боерып булмый кеше күңеленә.
Җан яратса, ярсу дәрья сыман,
Хисләр әзер ташып түгелергә.

Сөю булмаганда назлар көтү
Чыкмас кояш белән пар икән.
Коры кеше булмый бу дөньяда,
Сөю-сөймәү генә бар, иркәм.

Яндыр якты шәмнәреңне

Ялтлар итсен бүлмәләрең,
Яндыр якты шәмнәреңне.
Җитен чәчең җем-җем килсен,
Ал иңеңнән шәлләреңне.

Килдем сиңа.
Икеләнмә,
Йөрәгемә йөрәгең ач.
Тик ашыкма, сабыр, җаным,
Кочагыңны ачма.
Кач, кач!

Куркам, җаным, көйдерермен,
Бигрәк янып барган мәлем...
Янсын, әйдә, якты шәмең.
Ал иңеңнән кара шәлең.

Гөрләшикче, серләшикче,
Бу көнне мин күпме көттем.
Сиңа мине алып килде
Мәхәббәтем — нур-өметем.

Вакытлары җитмәс борын
Тик чәчкәләр коелмасын.
Йөрәкләргә уңалмаслык
Авыр яра уелмасын...

Һич тартынма,
Мин – синеке.
Йөрәгеңне ач, ач, җаным.
Кочагыңны ачма, җаным,
Кач, кач, җаным!

Матурлык

Атлаулары — үзе бер моң,
Йөрәгең яндырырлык.
Карашлары — алкын чишмә,
Сусынны кандырырлык.

Ә тавышы — чулпы чыңы,
Җаннарыңа җан өрә.
Бар булмышы — сихри дөнья,
Яшәвеңә тәм бирә.

Кем тудырган асыл затны
Бу гүзәл җир йөзенә?
Бик белсәм дә чибәркәйнең
Түгеллеген үземә,

Ләззәт табам, җырлап барам:
«Матурлык бар, — дип, — җирдә».
Шул матурлык булган җирдән
Китәсе килми бер дә.

Телендә кем булыр?

Ир кеше булганда
Юлларда,
Көч-куәт нык чакта
Кулларда,

Иң тәүдә кемне соң
Хәтерләр?
Ул кемнең исемен
Кадерләр?

Әйтер ул: «Сөйгәнем,
Ярым, — дип. —
Сагындым, сагынам,
Җаным», — дип.

Ә авыр хәлләргә
Калганда,
Иң соңгы сулышны
Алганда,
Шул булыр өзелеп
Әйткәне:
«Әнкәем,
Әнкәем!»

Асыл затлар

Хатын-кызга бәхәс ябышып бетми.
«Мохтаж түгел» алар киңәшкә.
Күп кияүләр балда-майда йөзә,
«Әйе» диеп торса кәләшкә.

Ул затларны алла без — ирләрне
Ашкындырыр өчен яраткан.
Шулар диеп ирләр утка кергән,
Шулар диеп шашкан, җан аткан.

Ялгыз калсаң, барыбер сагынасың
Алар белән бергә чакларны.
Йокылардан язган төннәр азмы,
Юксынганда асыл затларны.

Ул затларга мин дә гомер буе
Бер сокландым, берчә уфтандым.
Киңәш бирер булдым, туктап калдым,
Тотып калдым бәхәс нуктасын.

Ни өчендер шушы асыл затлар
Җигелергә тырыша уртага.
Юл башлыйсың ары таба диеп,
Борып ала алар бу таба.

Бәхәсләшеп кара, алларына
Чыгам диеп инде уйлама.
Ир затлары шуннан үз тезгенен
Үзе тарта, туктый, уйлана.

Һәйбәт кияүләрчә, «синеңчә» дип,
«Син хаклы» дип, аңа баш кага.
Асыл затлар ул чак тик синеке,
Тәтемиләр инде башкага.

Бары сөю дәва

Яшьлек дәртем шашып, яныл-ярсып,
Зәңгәр кыяларга ук аттым.
Сине таптым, әмма сакламадым,
Аткан угым кебек югалттым.

Угым очты ерак-еракларга.
Җәяләрем калды иңемдә.
Синең карашларың яралаган
Яраларым калды күңелемдә.

Аткан уклар кире кайтмагандай,
Кире кайтмас кебек идең син.
Кайтмас угым сыман югалсаң да,
Яңа таңым булып килдең син.

Җәяләрем иңдә, син — эргәмдә,
Уңалдылар инде яралар.
Йөрәктәге сөю яраларын
Бары сөю генә дәвалар.

Табышу

Тау-ташларны ярып бара-бара,
Чишмә елга белән кавыша.
Зур суларга кушылып ага-ага,
Олы ярлар белән таныша.

Җырчы кошлар урман моңы аша,
Сайраулары аша кавыша.
Бу дөньяда, әйе, барысы да
Үз сукмагы аша табыша.

Ә без, иркәм, ничек табыштык соң?
Сәбәпчесе синең күзләрдер,
Шушы күзләр аша күңелемә
Нурлар сузып үткән эзләрдер.

Әйе, синең сихри караш аша
Барысын да сүзсез аңлаштык.
Икебез генә белгән эздән китеп,
«Сөю» утравында адаштык.

Без табыштык.
Бу утраудан инде
Кире чыгар юллар булмасын.
Утрау гына түгел,
Бөтен җиһан
«Табыштылар» көен уйнасын.

Ялгыз булма

Җирдә була өшеп-туңган чаклар,
Янган чаклар — тәнне ут ала,
Өшегән тәннәр җылына.
Вакыты җитеп,
Яралар да барыбер уңала.
Тик бар микән ялгызлыктан артык,
Авыррак яра дөньяда?

Иңнәреңә салган куллар була,
Болай гына, күңел табам дип,
Янәшәңнән бераү барган була,
Болай гына, бер ял алам дип, —
Юкка тиңнәр бары да,
Ялгыз булса җаның.
Ялгызлыктан зуррак каза юк.
Бирсен дөнья җәза —
Ялгыз гына булма,
Ялгызлыктан авыр җәза юк.

Авырлыклар килсен.
(Ник куркырга?!)
Кыл өстендә торсын гомерең,
Әгәр тойсаң җаның-тәнең белән
Ялгыз түгеллеген күңелең,
Син юк түгел,
Син бар, куәтлесең —
Рухың белән олы җиңүче.
Сут китергән тере тамыр сыман,
Син кемгәдер яшәү бирүче.
Ана кешенең шундый тәүге моңы
Бәвелдерсен бәллү сиртмәсен.
«Җан юлдашы булсын йөрәгендә,
Балам юлга ялгыз китмәсен...»

Син калдырган бозлар

Эреп бетә кар да,
Җир ачыла.
Ә йөрәктә һаман боз ята.
Эремәс бозлар хәтәр бозлар икән —
Йөрәгемне ничек сызлата.

Син калдырып киткән бозлар алар.
Алар өчен язлар яз түгел.
Табигатьтә әнә яз уяна.
Ә миндә бит һаман боз күңел.

Һәрбер җәйнең көзе булган кебек,
Һәрбер кышның була үз язы.
Һәр тугайның була үз тургае,
Һәр йөрәкнең була үз назы.

Ул бозларны синең караш кына,
Синең кояш кына эретер.
Ә ят итсә алар,
Йөрәгем чыдам,
Гомер буе саклап йөретер.

Ак карлардан әнә җир ачыла.
Калын бозлар эреп агарлар.
Кайнар язның, җәйнең җылысын тоймый,
Син калдырган бозлар яңа көзгә
Эремичә, ахры, барырлар.

Миләшем*

Яшел җәйләремне давыл алды,
Җаннарымны давыл өшетте.
Өшегән җаным белән сиңа килдем.

---

* *Салават Низаметдинов* музыкасы.

Аһларымны тик син ишеттең,
Җаннарымны җаның иш итте.

Күзләремне сары сагыш япты,
Сары яфрак җиргә сибелә.
Сагыш тулы йөрәгем сиңа килде.
Каршы алдың, әйттең: «Кил генә...»
Сабырлыклар бирдең син генә.

Карлар япты бөтен тирә-якны,
Карлар ятты синең иңеңә.
Карлар ярып тагын сиңа киләм.
Чакырасың һаман: «Кил генә...»
Юанычым, миләш, син генә.

Карлар аша алсу тәлгәшләрең
Өмет булып миңа эндәшә.
Тәлгәшләрең — шиңмәс сөю төсе,
Алар миңа: «Кил...» — дип эндәшә.
Өметем син, Миләш-Миләүшә.

Килдең күзгә урманыма

Гөлсемгә

Сине тәүләп каршылады
Күзге урманым.
Килеп кердең ярып сары
Яфрак буранын.
Без атлыйбыз. Бер моң булып
Яфрак кыштырдый.
Колагыма килеп шулчак
Язым пышылдый:
«Юлдашыңны, жан дусыңны
Чакырсаң миңа,
Яшеллеккә күмәр идем,
Соңладың нигә?

Чәчкәләрдән чәчләренә
Асыл таҗ үреп,
Кочагымда йөрер иде,
Күбәләк кебек.»

Без атлыйбыз. Бер моң булып
Яфрак кыштырдый.
Колагыма назлы гына
Җәем пышылдый:
«Миңа килсә, аунар иде
Ефәк үләндә.
Авыз итәр иде минем
Ал бөрлегәннән.»

Алар сөйли. Мин атлыймын.
Ә син очасың.
Көзге яфрак гөлләмәсен
Алып кочасың.
Шул чагында яфрак-ялкын
Гөлтли урманда:
«Нинди соңлау, минем кебек
Көзең булганда?!
Алтын тәңкәләрем сибәм
Менә алдыңа.
Бер генә бак миләшемә,
Баланнарыма.
Көзге җимеш ал булса да,
Бераз әчерәк.
Ә шулай да бик күпләрдән
Сез бәхетлерәк».

Сине шулай каршылады
Көзге урманым.
Без атлыйбыз ярып сары
Яфрак буранын.

Канатым

Йөрәгемә каршы килеп, бүген
Бармый калдым сиңа,
Эш, эш дип,
Үз-үземә кат-кат тәкрарләдем:
«Син бармаска тиеш, тиеш!» — дип.

Эшем тәмам.
Әмма барысын да
Мин югалттым сыман капылда.
Берни шатландырмый:
Булган эш тә,
Йөрәгемне тыйган акыл да.

Акыл миңа һаман акыл сата:
«Ул дигәндә, онытып һәммәсен,
Баш бирмәс бер шаян малай сыман,
Чабып чыгасың да китәсең.
Мине тыңлап, күпме файда күрдең,
Шатлан, әйдә, эш ул югалмый».
Сине сагынып, урын тапмый йөргән
Йөрәгемне акыл йөгәнли.

Япа-ялгыз утырам.
Күңелем буп-буш.
«Кайда йөрәк, — димен, — канатым?»
Янып китте йөрәк, ярып салды:
— Оч тизрәк аңа, ашкынып оч!
Канатың бит — аны ярату...

Туй көнендә

Уңган кояш келәм тукып
Үзенең алтын нурыннан,
Җәеп куйган бу икәүнең
Атлап барыр юлына.

Алар бара.
Туй күлмәге
Салынмаган өсләрдән.
Болай да шат йөрәкләргә
Яңа шатлык өстәлгән.

Күктә кояш.
Җирдә нур-юл.
Күңелдә тик наз әле.
Алар өчен кыш-көзе юк,
Гел чәчкәле яз әле.

Ә һавада язмышлары
Аккош булып талпына.
Күлгә төшеп йөзә дә ул,
Күккә менә тагын да.

Язмыш-аккош канатыннан
Алсу тасма сузыла.
Алсу тасма — язмыш тасма
Ике яшьнең кулында.

Аккошны да, тасманы да
Алар уйламый әле.
Тормышның шул татып туймас
Исерткеч татлы мәле.

Аккош гелән нурга чумган
Тыныч күктә очмас бит,
Гелән генә көзге сыман
Тонык күлләр булмас бит.

Зур суларны кичкән чакта
Талмасын канатлары.
Ялкыннардан үткән чакта
Янмасын канатлары.

Әткәйләре арттан килә
Менә шуларны уйлап.
Киләчәккә барып урый
Алсу тасмалар буйлап.

Аларга бит күчкән

Чәчләренә инде кырау төшеп,
Маңгаена сырлар ятканын,
Шаян яшьлек белән саубуллашып,
Гомерләрнең алга атлавын

Онытып микән,
Ире хатынына
Озак карап торды тын гына,
Әйтә салды:
— Һай, бичәкәй, җаным,
Матурлыгың китә шым гына.

Бар иде бит һуштан яздырырлык
Авылда бер чибәр чакларың.
Булды сине тик бер күрер өчен
Эштән арып-талып кайткан көйгә
Ун чакрымга җәяү чапканым...

Хатыны да көлде аңа карап:
— Ялгышасың, картым, бүген мин,
Җаным-тәнем белән сөенә-сөенә,
Чибәрләрдән-чибәр үзем, дим.

Кара әле кызың-улларыңа:
Төс-башларын гөлләр көнләрлек,
Сөен генә,
Аларга бит күчкән
Синең белән минем чибәрлек.

Гашыйклар дәфтәреннән

Көткәндә

Көткән чакта — көнең айдыр,
Төнең елдыр.
Вакыт — үгез җиккән арба,
Даңгыр-доңгыр
Чак кузгала, җан көеге,
Нишлисең бит.
Йөрәк түзә: килер, ди, көт,
Сабырлар ит.

Очрашканда

Очрашканда вакыт гүя
Аккош була:
Канатларын иңгә салып,
Сиңа куна,
Сәгатьләрне ашыктырып,
Очып үтә.
Минут итеп көнне сүтә,
Төнне сүтә.
Йөрәк ялына: аккошкаем,
Ашыкма, ди.
Кызган әзрәк, без бит, җаным,
Гашыйклар, ди.

Аерылышканда

Аерылышу — гашыйкларга
Газап инде.
Әрнүләрең, сыкрауларың
Азак инде.
Вакыт сыный: мәхәббәтең
Сакланамы?
Озаграк көткән саен
Сафланамы?

Үзәк өзелә: «Юк шул минем
Башка чарам —
Уем белән аңа көнгә
Җитмеш барам.
Нишлимен соң, йөгереп җитәр
Түгел арам.
Очрашырмын, төзәлер бер
Йөрәк ярам.»

Шикләнгәндә

Шик-шөбһәләр килеп керсә
Йөрәгеңә,
Чыда инде: кирәгеңне
Бирә генә —
Ничә тапкыр салып ярын
Ят кочакка,
Кертә сине җитмеш кабат
Ут-учакка.
Янып-көйгән йөрәгеңә
Кайда бальзам?!
Ах, авырдыр, әгәр андый
Хәлгә калсаң.

Күз яшьләрең дәвалармы
Йөрәгеңне?!
Киңәшем шул: якын итсәң
Сөйгәнеңне,
Шик-шөбһәгә урын бирмә
Җаннарыңда.
Шулчак сиңа тугры калыр
Җан-ярың да.

АУМА-АУМА, ТУП-ТУРЫ ТОР

Бик яшь әле

Өч-дүрт сәгать киңәш бара.
Көр тавышлар колак яра:
Бер урынга хуҗа кирәк,
Тик кемне соң куймак кирәк?..

Менә Ильяс: оста, зирәк.
Аның кебек бездә сирәк.
Тик шунысы: Ильяс әле
Бик яшь әле, бик яшь әле.

Ун ел үтте. Тагын кара,
Шул турыда киңәш бара:
Хуҗа кирәк, хуҗа кирәк.
Тик кемне соң куймак кирәк?..

Тәүдә ныклап уйлау кирәк.
Ильяс ярый. Белемле дә,

Зиһенле дә. Андый сирәк.
Тик шунысы: яшьрәк, яшьрәк.

Тагы ун ел. Бара киңәш:
Ильяс ярый, һәйбәт иптәш.
Бары да берчак тынып калды.
Шунда берәү әйтә салды:
— Яше җитүен җитә инде.
Тик шул ягы: иртәгәдән
Пенсиягә китә инде...

Бишминутлык

Ишекләрдән ишекләргә
Зур чиратлар тезелеп киткән.
Тугыз тулды. Кабинетлар
Ачылмыйлар. Нигә икән?

Коридордан коридорга
Зарланулар йөреп ята:
— Эш калдырып килгәнбез бит,
Уйлыйлармы шушы хакта?

— Шул көтүе җанга үтә,
Моннан артык бармы хитлык.
Секретарь кыз: «Түзегез, — ди, —
Әле бара «Бишминутлык»...

Түзәләр бит.
Төш тә уза.
Халык кыза. Халык туза:
— Бынагаеш,
Бу ниткән эш?! —
Зарланулар, сукранулар
Коридорда кайный башлый:

— Безнең эшне кем соң эшли?!
Йомышларны кем йомышлый?!

Монда бардыр берәр мутлык...
— Тсс... Шымыгыз... Бишминутлык...
Эш сәгате бетеп бара,
Ачу тәмам кызып җитә.
«Бишминутлык» барган җиргә
Бермәл халык кереп китә...

Эчтәгеләр шаккаталар:
— Ни тамаша?! Бу ни кылык?!
Безнең монда әле яңа
Кызып бара «Бишминутлык».

Бүреклеләр һәм яулыклылар

Юллар кирәк, юллар кирәк.
Юл хәстәрен юллау кирәк,
Тәүдә план сызу кирәк,
Аннан җирен казу кирәк.
Планчылар табылдылар,
Зур корсаклы папка асып,
Юллар буйлап агылдылар.
Бәләкәйрәк папкалар да
Аларына тагылдылар.
Гаҗәп менә, планчылар
Барысы да бүреклеләр.
Тегермәннәре шәп тарта —
Бары да зур-зур күреклеләр.

Вакыт җитте юл салырга,
Ком алырга, җир казырга.
Носилкалар берләшәләр,
Көрәкләр дә серләшәләр.
Ташлар килә чатыр-чотыр —

Бар тирә-як чокыр-чакыр.
Кемдер көен көйләп ала,
Кемдер мәзәк сөйләп ала.
Аркалардан тирләр ага:
Асфальт җәю китте менә,
Битум хушбуй сипте менә.
Юл түшәлеп кенә бара.
Эй, эш китте тәмам кызып
(Карап тору гына кызык),
Уңганнарга нәрсә чыдар?
Тик шунысы аңлашылмый:
Барысы да яулыклылар.

Юллар әзер.
Менә хәзер
Эшне кабул итү бара.
Олы-олы папка тоткан
Бүреклеләр колак яра:
— Һай, шәп булган!
— Һай, шәп булган!
(Яулыклылар төзегәнгә
Бүреклеләр бик шат булган.)
Бүләкләр дә пәйда булды.
Бар тирә-як бүләк алган
Бүреклеләр белән тулды.
Зур бүрекле: «Яхшы!» — диеп,
Башын кагып-кагып ала.
Яулыклылар хөрмәтенә
Коньягын да кәгеп ала.

Төшенеп кенә булмый шуңа:
План сыза бүреклеләр,
Олы-олы күреклеләр.
Җирен казый, комын сала
Яулыклылар,
Яулыклылар!

Нокта

Зур түрә өске катта.
Баскычтан менгән чакта
Тез буыннарым тала,
Маңгаемнан тир тама.

Ярсып килеп менәмен,
Кабинетка керәмен,
Зур түрәгә узамын,
Кәгаземне сузамын.

Зур түрә башын бора,
Шуннан тамагын кыра:
— Җитешми, — ди, — бер өтер,
Өтерен куеп китер...

Ах, бу өтер-мөтере,
Кырылып кына беткере, —
Түбән чабам тек тә тек,
Җиде катны селкетеп.

Тагын менәм әлсерәп,
Зур түрәгә күз терәп, —
Тир ага яңак буйлап.
Ә түрәм тора уйлап.

«Була, — димен, — эш худта.»
— Юк, кирәк, — ди, — бер нокта...
Йөрәгем дөп-дөп кага.
Аркалардан тир ага.
Шулай кайтып китәмен, —
Зур түрәне тетәмен.

Иртәгәсен киләмен.
Бәй, мин нәрсә күрәмен:
Приказ тора көлеп,
Түрәм утыра бөлеп.

Кайгы чыккан йөзенә.
Бу ни хикмәт? Ни булган?
Зур түрәнең үзенә
Олы нокта куелган.

Белгеч «тәҗрибәсе»

Пенсиягә китә өлкән белгеч,
Тәҗрибәсен сөйли яшьләргә:
— Белгечлекнең сере үз түрәңнең
Күзенә генә карап яшәүдә.

Әйтә икән: «Кара ягы кирәк»,
Син табарга тиеш карасын.
Агы булса, аны күрмә, белмә —
Гел аскарак күмеп барасың.

Куша икән хуҗаң асфальттан да
Олы, тирән ярык табарга —
Син тиешсең нәни ярыкка да
Микроскоп аша карарга,
Ә тиешсең ярык табарга.

Әйтә икән хуҗаң сыерны да:
«Сыер түгел, бу бит үгез», — дип,
Син торырга тиеш башың кагып:
«Әйе, түрәм, әйе, дөрес», — дип.

Яшь белгечләр әйтте:
— Абзый, җитте.
Без башкача яшәп карарбыз.
— Анысын инде үзегез карагыз.
Авызыгыз пешкәч, хәтерләрсез
Ни әйткәнең шушы агагыз...

Түрә «эш күрә»

Начальнигы юлдан чыккач,
Хуҗалыкны тәмам еккач,
Габделвәли көйде, янды:
Министрга жалу язды.

Министр ни бик зур кеше,
Әйтеп булмый, күптер эше,
«Жалу җитди, тикшер», — диде.
Замына ул әмер бирде.

Замминның да эше тыгыз,
Помга сузды : «Хәл кылыгыз.»
Помы ныклап укып чыкты,
Укып чыккач, башын тотты
Һәм утырды: «Так, так, — диеп, —
Тикшерергә мотлак», — диеп,
Районга шылтыратты
Һәм жалуны шунда озатты.

Инде райондагы түрә
Тирләп-пешеп чара күрә:
Жалу йөри, жалу чаба,
Жалу оча түбән таба:
Габделвәли начальнигы
Кулына ук килеп каба.

Кәгазьне алгач, начальник
Тиз тотынды «эш күрергә»,
Габделвәли агагызны
Төкерек чәчеп өшкерергә...
Габделвәли йөри янып,
Өр-яңадан жалу язып.

Шәләй-вәләй

Үзе әйтмешли, тәмен белеп,
Теттереп яши Җәләй —
Мөдир исемен күтәреп
Йөрми ул шәләй-вәләй.

Фермадагы мал-туарны
Әвеш-тәвеш иткәли.
Дус-ишләре бозау биреп,
Сыер алып киткәли.

Бөкре счеты Җәләйнең
Чарт та чорт йөреп тора:
Сыеры да, сарыгы да
Башка-баш килеп тора.

Мөдир Җәләй отчет яза,
Счетын тарта-тарта:
«Мөгезле мал саны бездә
Фәләнчә башка арта...»

Отчет яза. Ә фермада
Мөгезсез маллар гына:
Әвеш-тәвеш итә торгач,
Калган бозаулар гына.

Шөреп

Көн яралса, Сәүдә әби
Картын талый, ай-һай-һай:
— Кран ага. Утың янмый...
ЖЭУга чаба бабай:
— Энем, слесарь давай...

— Хәзер яңача эшлибез,
Булыр, тынычлан, бабай.
Озакламый барып җитәр
Яңа слесарь Ямай.

Килә Ямай. Утны карый.
Краннарны боргалый.
«Баш төзәтми, төзәтеп булмас», —
Сөйләнгәләп куйгалый.

Әйтә бабай:
— Яңача бит.
Җитте йөрү төшереп...
— Яңачамы? Ярый инде,
Куям яңа бер шөреп.

Моннан соң да кран ага.
Әби дулый, ай-һай-һай.
Аптырагач, магазинга
Йөгерә безнең бабай.

Килә Ямай.
Әйтә бабай:
— Искечә төзәт, давай.
«Төзәткәч» ни, эш көйләнә.
Слесарь йөри көлеп:
— Үз гомереңә җитәр, — ди, —
Куйдым, — ди, — алтын шөреп.
Во! — дип куя, төшереп.

Китә Ямай.
Кран акмый.
Әби тына, таламый.
Җилкәсен кашый бабай:
— «Яңача»ның хикмәте, — ди, —
Һаман искечә, малай...

Бакчада

Яшел яз һәм җәй кавышкан
Шат кичләрнең берсендә
Өч-дүрт әби очраштылар
Бакчаның иң түрендә.

Очраштылар — гәп саттылар:
— Бу чактагы балалар...
— Оялмыйча кайсылайрак
Кочаклашып баралар...

Әбиләрдә эшләре юк,
Яшьләр үтә парлашып.
Шырык-шырык йә көлешеп,
Йә былбылдай сайрашып.

Зәңгәр сирень куагында
Әнә икәү тукталды.
Бер әбекәй йөрәген тотты,
«Ах» диеп телсез калды.

Икенчесе бөгелеп төште:
— Үбешәләр... Кара әле...
Әлдә генә яннарымда
Валидолым бар әле...

Өченчесе елмайды да
Кайтты яшьлек чагына:
«Үләр идем, үләр идем
Шул егет кочагында...»

«Үсте» кызлар

Туа торды, үсә торды
Кызлар тупылдашып.
Күтәргәннең иң авыры
Булды олы кашык.

Барысын да алларына
Нәнәйләре ташып,
Җилкәләре кычытса да,
Шул бер нәнәй кашып,
Үсте кызлар тупылдашып,
Ярышып-ярышып.

«Сабыйлар»га китте менә
Унсигез дә ашып.
Күтәргәннең иң авыры
Һаман олы кашык.

Сиксәнен дә тутырмады,
Нәнәй вафат булды.
Өйдә җылаш, өйдә гауга,
Гүя җир убылды.

Имә торган бозаулардай
Бакыралар кызлар.
«Мәм-мәм» диеп нәнәйләрен
Таптыралар кызлар.

Шушы кызлар «сабыйлык»тан
Кайчан икән чыгар?..
Шуңа күрә тәмамланмый
Кала минем шигырь.

Шәп булгач ни...

Бакча эче гөрләп тора,
Пычкы-балта зырлап тора,
Юнышкылар оча, малай.
Тирләп-пешеп дүрт-биш бабай
Танцплощадка ясый,
Эшләр кызу, ай-һай-һай-һай...

— Габделкәрим, давай, давай.
Күбрәк йөри синең малай...
— Синең кыз да коры калмый,
Тарт пычкыңны, тарт, тарт, Гыймай...

Клубта да эшләр харап:
Аһ-ваһ килеп, билне каргап,
Идән юа әбекәйләр,
Биесен дип «бәбекәйләр».

Аякларны шыкылдатып,
Анда-монда күз уйнатып,
Карап тора «бәбекәйләр»,
Шәп булгач ни әбекәйләр.

Автобус

Чәч бөдрәсе маңгаена
Төшкән иде.
Бит алмасы алсуланып
Пешкән иде.

Бер елмайды — кояш чыкты,
Миңа бакты.
Шулвакыт ни автобус та
Ишек япты.

Ишек япты. Утыртты да
Алып китте,
Йөрәгемә сүнмәс ялкын
Салып китте.

Автобус ни йөрәксез шул,
Янмый, көйми.
Шуннан бирле автобусны
Җенем сөйми.

Гата, диләр

Гата, диләр,
Кеше җилкәсен кимереп
Ята, диләр.
Кешемени — торам абый
Җилкәсендә.
Һич чит түгел, үземнеке
Җиңгәем дә.

Гата, диләр,
Көн дә исереп, ава-түнә
Кайта, диләр.
Көн дә түгел, ике-өч көнгә
Бер генә лә.
Дөрес сөйли белми халык
Һич кенә дә.

Гата, диләр,
Исереп килеп, тәрәзләрне
Вата, диләр.
Юк, белмиләр, тәрәз түгел,
Ишек ваттым.
Шулчак төшкән тәрәзе дә
Гөлбанатның.

Гата, диләр,
Гаепләрең җинаятькә
Тарта, диләр.
Гаебем юк, бу сөйләүләр
Гайбәттер ул.
Гайбәт сүзен ишетүе
Һәйбәттер шул.

Лифт ябылган арада

Хатын һәм ир.
Тагы берәү —
Кара мыеклы егет.
Хатын белән мыек-егет
Өлгерде генә кереп —
Лифт ябылды шап итеп.
Ир торып калды тышта.
Егетне күргәч, хатынкай
Язарга әзер һуштан:
Үбештеләр...
Килештеләр...
Ир соңлады минутка.
Хатын белән ир арасы
Әйләнде зәһәр утка.

Минут тәүлеккә әйләнде,
Тәүлек — айга, елларга.
Хәзер инде бу хатынны
Кай тарафтан юлларга.

Иргә почта хат китерә:
«...Гафу ит, җан кисәгем:
Теге кара мыеклыны
Мин мичәүгә мичәдем...»

Улының «хезмәтләре»

Ах-вах килеп тротуардан
Бер әбекәй үтеп бара.
Үзалдына мөңгер-мөңгер
Алласынмы, баласынмы,
Шайтанынмы сүтеп бара:

— Каһәр төшкер, кырылып беткер!
Иманыннан җәяү качкан...
Мескен әби иңбашына
Зур корсаклы сумка аскан.

— Әбекәй, — дим, — кайда болай?
Ераккамы сәфәр тоттың?
Чак киләсең, бик авырын
Күтәрткәннәр, — димен, — йөкнең?

— Язгач, күтәрми нишлисең,
Бу — улымның хезмәтләре, —
Кулын селти әбекәем, —
Өйдә аның хикмәтләре...

— Хезмәтләре зур күренә,
Атлый мәллә докторлыкка?
— Духтырлардан башы кайтмый,
Салды инде безне утка...

— Үзе язгач, үзе илтсен,
Йөртә ул нигә Сезне?
— Хак Тәгалә үзе язгач,
Күрәм инде күрмәгәнне —
Нишләтим соң ул юньсезне...

Шулчак сумка — шалтыр-шолтыр!..
Әбекәем билен тотты.
— Кырылып бетсен, җир йотсын! — дип
Шешәләрне тибеп екты.

Гөлнәркәз үтә урамнан

Гөлнәркәз үтә урамнан
Терт тә мерт басып кына.
Ах, дип калалар егетләр,
Тәрәзә ачып кына.

Ә Гөлнәркәз берсенә дә
Күз дә сирпеп карамый.

Гөлнәркәзгә, чибәр кызга
Берәүсе дә ярамый.

Камилны ул, бик озын, ди,
Миңа колга кирәкми.
Йомагол да ошап җитми,
Кулы олы, көрәк, ди.

Габделхәйнең буй-сын һәйбәт,
Тик очлы, ди, ияге.
Гайфулласы да ошамый,
Бигрәк гади кигәне.

Гөлнәркәз үтә урамнан
Танавын чөеп кенә.
Ах, дип калалар егетләр,
Тик яньп-көеп кенә.

Ничә туфли туздыргандыр
Гөлнәркәз урам тапап —
Сизмәде дә, айлар, еллар
Үтте дә китте атлап.

Гөлнәркәз бара урамнан,
Танавын чөйми генә.
Берәр егет булмасмы, дип,
Эзли дә эзли генә.

Тик егетләр моны һич тә
Сизми дә сизми генә:
Парлашып үтеп китәләр
Сәлам дә бирми генә.

Егетләрне җен суктымы —
Берәүсе дә ах итми.
Танау маңгайга җитсә дә
Терсәк авызга җитми.

Кемнәр боза?

Улыбызны җандай күреп
Яратабыз.
Ул гына дип, бер генә дип
Җан атабыз.
Үзебез дә кимәгәнне
Кидерәбез.
Ни сораса, шуны эзләп
Йөгерәбез.
Бала булып, тау чаклыны
Таптыра ул,
«Давай!» — диеп, аяк тибеп
Акыра ул.
Җаным әрни, җаным сыза:
Урам боза,
Урам боза.

Сәбәп табып, авыруга
Башны салам —
Шул бала дип кайчак эшкә
Бармый калам:
Вакытында йоклаганмы?
Ашаганмы?
Юынганмы? Чәчен тарый
Башлаганмы?
Аптырыймын, әнә, тагын
«Ике» алган.
Дәресенә дә кермичә,
Качып калган.
Җаным әрни, җаным сыза:
Мәктәп боза,
Мәктәп боза.

Сыйга күмеп, туган көнен
Үткәрәбез.

Бичә белән олы тавыш
Күтәрәбез.
Икәүләшеп тезләнешеп
Алдына без:
«Эчмә, тартма инде», — диеп
Ялынабыз.
Аптырыймын, бозыла бала:
Эчә, тарта.
Кайчак өйгә ава-түнә
Чак-чак кайта.
Җаным әрни, җаным сыза:
Кемнәр боза,
Кемнәр боза?

Җәннәт йорт

Бер ана ул үстерде,
Тәрбияләп, укытып.
Авыр чакны үткәрде
Су йотарда — ут йотып.

Улы хәзер зур кеше.
Яши олы калада.
Ана күңеле — баллада,
Бала күңеле — далада.

«Бала»ның бар дөньясы,
Фатиры — иркен ялан.
Бүлмәләрдә адашып
Куя күрмәсен «балаң».

Фырт кәләше берүзе
Били ике бүлмәне,
Хәтта шушы «бала»га
Шакып кына кермәле.

Аш бүлмәсе, эш бүлмәсе —
Һәммәсе дә бар анда.
Бер бүлмәдә — зоопарк,
Этләр, песиләр анда.

Ул аллары, ул заллары —
Егермеләп урындык.
Әмма шушы җәннәт йортта
Бер анага урын юк.

Энә — җеп

Энә кайдан — җеп шуннан, дип
Өлкәннәр гомер иткән.
Шуны Вәли һәм Вәлимә
Нигә аңламый икән?

«Син — энәме, мин — энәме?» —
Хикмәт менә бит нидә.
Вәлимә әйтә: «Мин җеп булып
Йөремәм, — ди, — энәдә.»

«Алай булгач, — диде Вәли, —
Икебез дә энәбез.
Ике киемне икебез
Ике өйдә тегәбез.»

Вәли — энә яңа өйдә.
Өр-яңа җеп энәдә.
Ә Вәлимә тутыгып беткән
Иске генә энәгә:
«Җеп булам», — дип инәлә.

Ике «тиеш»

Буйдаклыкка чик куярга
Исәп итеп берзаман,

Болай егет тә кыз булып
Йөрмәбез бит, дип, һаман,

Өйләнешергә уйлады
Гөлҗимеш белән Биеш.
Менә шулчак очраштылар
Ике уй — ике «тиеш».

— Ир кеше булгач, акыллы,
Тыйнак булырга тиеш.
Хатынының тирәсендә
Биеп торырга тиеш.

— Ирләр халкы наз ярата —
Хатын аңларга тиеш.
Кемнең ире — аның ире,
Гел олыларга тиеш.

— Ир кеше һич тә эшеннән
Соңлап кайтмаска тиеш.
Анда-монда күз атмаска,
Хәмер капмаска тиеш.

— Хатын кеше ир кайтуга
Көлеп торырга тиеш.
Ирнең бөтен уй-теләген
Белеп торырга тиеш.

Сөйләштеләр, килештеләр:
— Шулай булырбыз, яме.
Күрсәтербез башкаларга
Бергә яшәүнең ямен...

Өйләнделәр. Шулчак тагын
«Тиеш»ләр килеп басты.
Элек килешкән «тиеш»ләр
Үзара сугыш ачты.

Тормыш бит ул, безнең Биеш
Соңга да калып кайтты.
Була бит ул, кайчагында
Хәмер дә кабып кайтты.

Гөлҗимешнең айдай йөзен
Кара болытлар япты.
«Җаным» сүзе урынына
«Явыз» сүзен дә атты.

Ике «тиеш», басмадагы
Ике тәкә шикелле,
Әй сөзешә, әй сөзешә —
Мөгез-мөгезгә килде.

«Тиеш» кызды. Мөгез сынды.
Ике «тиеш»тә — суда.
Ике гомер ике җирдә
Инде «тиеш»сез уза.

Шул кирәк

Мин очраттым шундый бер чибәрне:
Сусыз кашык белән йотарлык.
Гомер буе үзен кулларыңда
Чәчкә генә итеп тотарлык.

Без таныштык.
Кызый бер елмайды:
Табаныма хәтле эредем.
Бик шәп булган булып,
Тирәсендә
Ата күркә кебек йөредем.

Сумкасын да алдым кулларыма,
Йөк, дим, күтәрмәсен гүзәлем.

Сумка авыр, кулны өзеп бара,
Сер бирмимен, атлыйм, түзәмен.

Кавказ тавы текә,
Баскыч текә.
Без үрлибез һаман югары.
Алда — кыя, менеп җиту кая —
Баскычларның чиге юк әле.

Чәчи-чәчи бара бу агагыз.
Ә кыз инде — болан баласы.
Ах, шулвакыт ташка утырып кына
Бераз яллар итеп аласы.

Юк, туктамый кызый:
— Әлеме, — ди, —
Яртысы бар юлның, әнә, — ди. —
Күрәсеңме, тауның түбәсендә
Тәрәзәбезнең уты яна, — ди.

Менеп җиттек. Кызый эргәсендә
Мышнамаска тырышам —
Мышната.
Сөю дигән нәрсә ир затларын
Менә бит ул, малай, нишләтә.

Буын калтырый,
Әмма сиздермимен.
Татлы уйлар килә башыма.
Шулвакытны яп-яшь сылу егет
Пәйда булды безнең каршыда.

Егет суза кызга ал чәчкәләр.
Менә алды аны култыклап.
Кызый миңа иелеп рәхмәт әйтте.
Ә мин торам шунда ык-мыклап.

Китми торам катып.
Сылу тагын
Кабатлады матур рәхмәтен.
«Сау бул, абый» булып яңгырады бу,
«Шушы гына сиңа хөрмәтем!»

Шул чагында яшен ялтырады да,
Тауны ярып күкләр күкрәде.
Яңгыр коя. Суык.
Әмма минем
Ялкын белән тулы күкрәгем.

Нигә инде буе җитмәс тауга
Күтәрелә икән бу йөрәк?
Әле менә түбән төшеп киләм...
Шул кирәк ул миңа, шул кирәк.

Төпчек кызга өйләнәм

Төпчек кызга өйләнәм...
Әби-бабай сөйләнә.
Әби әйтә: «Кияү, — ди, —
Йөртә күрмә җәяү, — ди.
Үстердем сөеп кенә,
Нәнием диеп кенә...»

Бабай әйтә: «Әби, — ди, —
Кәләш — түгел бәби, — ди. —
Кызны тота бел, кияү,
Әйдә, йөрсен ул җәяү.
Авырын да күтәрсен,
Җиңелен дә үткәрсен.
Тормыш гел бәйрәм түгел,
Уйламагыз бик җиңел...»

Әби һаман сөйләнә:
«Картым, — ди, — җүләрләнмә.
Балабыз алма кебек,
Үстердек җандай күреп.
Кияү, шаулаша күрмә,
Авыр эш куша күрмә,
Төреп кенә йөрет, — ди, —
Өреп кенә йөрет», — ди.

«Әби, — димен, — алайса,
Кызың артык җәл булса,
Үзеңдә калдыр, — димен, —
Миңа табылыр», — димен.
(Арабыз нык кыз белән,
Шуңа эре чирттерәм.)

Әби тагын сөйләнә,
Мине тели көйләргә:
«Юк, кияү, кырын китмә,
Кызны, — ди, — читкә типмә».

Бабай әйтә: «Постой, — ди, —
Кияүгә бир покой», — ди.

«Әби, — димен, — кызыгыз
Өчен тыныч булыгыз.
Өреп кенә йөртмәм,
Ә шулай да хур итмәм:
Матур тормыш корырбыз,
Во иттереп торырбыз».

Әби авызын ера,
Бабай мыегын бора.
Ә үзләре сөйләнә.
Төпчек кызга өйләнәм...

Аума, аума

Урам буйлап икәү килә —
Охшашканнар шулкадәр, —
Халык телендә әйтелә:
Суеп каплаган мәгәр.

Берәүсе ир уртасында,
Берәүсенә — яшь ярым.
Яшь ярымы туры атлый,
Олысы — кырын-ярын.

Яшь ярымы җитәкләгән
Әзмәвердәй атасын.
Тәтелди ул: «Тулы атла,
Нигә кылга талтасың?..»

Кырын салган әти кеше
Җиргә утырды капыл.
— Аума, аума, туп-тулы тол,
Төз утыл, яхшы утыл...

Кыям микән?

Зур түрәләр, Кыям, диләр,
Әйтерсең дә, куян, диләр.
Посып кына тыңлый, диләр,
Маңгаена таш атсаң да,
Каршы әйтергә кыймый, диләр.

Үз тиңнәре, төлке, диләр,
Койрык болгый белә, диләр,
Авызын-борынын кыйшайткалап
Кет-кет килеп көлә, диләр.
Алай итеп, болай итеп,

Җаен, малай, таба, диләр,
Зуррагын да тәмлерәген
Үзе алып каба, диләр.

Ә үзеннән түбәнгеләр
Аны һәрчак, бүре, диләр,
Явызларның бере, диләр,
Хәзер тетеп ташлар, диләр,
Терелэй тотып ашар, диләр.

Гел җәнлекләр исеме белән
Яшәр өчен туган микән?
Кайсы ягы үзе икән?
Кайсы ягы Кыям икән?

Әл дә син бар әле...

Фатирыбыз иркен,
Идән яланга тиң.
Рәхәтләнеп, әнкәй, ю, әйдә.
Яшьлек үтте, дисең,
Юк, үтмәде,
Яшьлегеңне кабат ку, әйдә.
Син ана каз безнең ояда,
Әл дә син бар әле дөньяда.

«Внучка»ңны үлеп яратасың,
Җан атасың — үзеңә охшаган.
Без диңгездә, ялда.
Бер хафам юк,
Үз әнкәем, сиңа ышанам.
Син — күз-колак безнең ояда,
Әл дә син бар әле дөньяда.

Яшьләрнеке сыман, ак алъяпкыч
Кысып кына тора биленңне.
Ул ашларың,
Пилмән-коймакларың —
Йота гына күрмә теленңне.
Аш остасы безнең оядa —
Әл дә син бар әле дөньяда.

Өй караулы,
Дөнья хәстәрлекле.
Киявең дә әйтә, яшәрдең.
Яшә, әнкәй, шулай,
Гел яшь булып,
Таянычыбыз безнең —
Яшьләрнең.
Син — хәзинә безнең ояда.
Әл дә син бар әле дөньяда.

ЧАЛГЫЛАР ЧАЖЛЫЙЛАР
ЧАЖ ДА ЧОЖ

Утлар

Поэма

1

Туа кеше. Тәүге сүзе
Була «әни».
Ул гомергә шуннан җылы
Алып яши.
Яуда кеше кинәт ава,
Пуля тиеп —
Кочагына ята җирнең
«Әни» диеп.
Буыннардан-буыннарга
Шушы исем
Алып килә күңелләрнең
Иң саф хисен.
Шушы хисне җырга салам,
Көйгә салам.
Колагымда ана тавышы:
«Балам, балам!»

Безнең буын аналары
Ниләр генә күрмәделәр,
Чәчләренә кушып күпме
Кайгы-сагыш үрмәделәр.
Иңнәренә таулар ятты —
Күтәрделәр.
Җирдә яшәү булсын өчен,
Кояшлы көн тусын өчен
Барысын да йөрәк аша
Үткәрделәр.

Бу җырымда җырлыймын мин
Анага дан.
Шул аналар йөзе булып,
Ана күңеле нуры булып
Туа һәр таң.
Шул аналар моңы булып
Туа һәр җыр.
Шул аналар булган өчен
Гүзәл бу җир.

2

Мин тормышның көлеп торган
Чагын сөям.
Кошлар тавышын,
Елга агышын,
Чәчкәләрнең, карашларның
Назын сөям.
Әй, укучым, син дә шуны
Көтәсеңдер,
Җырларымнан шуны өмет
Итәсеңдер.
Тик, гафу ит, сүз башлыймын
Авыр чактан.

Шул авыр чак аналарның
Чәчләренә ап-ак кырау
Булып яткан.
Сүз башлыймын авыр чактан.

...Чалгылар чажлыйлар чаж да чож,
Кырпак кар өстеннән чаж да чож.
Иң алдан Газизә кар ера.
Чалгысы чаж да чож, чаж да чож
Игенне тезмәгә бөтерә.
Җил улый,
җил җылый,
сызгыра,
Карларны туздырып йөгерә.
Җил бүген назламый, көйдерә,
Салкынын җилеккә җиткерә.
Чабата-оеклар шыгырдый:
Катканнар укмашып, бозланып.
Сизелми аякның сызлавы.
Ишетелә нибары ак карда
Чаж да чож чалгылар чажлавы.

Көндезен өстәлләр тутырып
Тукмачлар җәюче хатыннар,
Кичләрен, мунчалар булдырып,
Ирләрен көтүче хатыннар,
Ян тәрәз каршына утырып,
Чигүләр чигүче матурлар,
Бер сыйпап арыган беләкне
Баһадир итүче матурлар
Басуда тырышып, тырмашып,
Игенне тезмәгә чабалар,
Игенне тезмәгә салалар.
Чалгылар чажлыйлар чаж да чож,
Кырпак кар өстеннән чаж да чож.

3

Басу, басу!
Арысландай ирләр белән бергә
Иелеп урак урган басу син.
Әпекәең белән кешеләргә
Яшәү көче биргән басу син.
Самат һәм Газизә
Шул ызаннан
Бергә кайтты —
Язгы кич иде.
Икәүсе дә эштә арыган иде.
Ә йөрәктә
Җирне урап үтәр көч иде.
Сөю иде, кайнар хис иде...

Илдар туды.
Үсте шул басуда,
Көлтә булды ятар мендәре.
Онытырлыкмы алар — аталы-уллы
Җир тырматып йөргән көннәрне.
Тәүге тракторны гөрелдәтеп
Тәү буразна сызган ул иде,
Самат иде.
Бу буразна безне мул тормышка
Җитәкләгән яңа юл иде.
Кулак пулясыннан канга тузып
Самат ятып калды шушында,
Каны тамды менә шушында.
Яп-яшь гомер кинәт өзелсә дә,
Яңа буразналар өзелмәде,
Тракторлар һаман гөрелдәде
Газизәнең уңган кулында.

Басу, басу!
Нәрсә булды сиңа?

Бүген синдә нинди ачу соң?
Башакларың җиргә сыгылып төшкән,
Шуңа, ахры, басу, ярсу син.
Илнең йөзе бүген тыныч түгел,
Күкрәгендә туплар ярыла.
Илбасарга ләгънәт, нәфрәт булып
Җир өстенә кан-яшь сарыла,
Җирнең йөзе бүген тыныч түгел,
Яуга китте асыл ир-атлар.
Машиналар китте.
Китте атлар.
Җыелмый шул калды чайкалышып
Шаулап үскән алтын башаклар.
Канлы сугыш бара яу кырында.
Алыш бара монда, басуда.
Ир-ат анда,
Ә хатыннар монда.
Җил сызгыра башак арасында,
Кар өерелтә кырда, ярсына.
Алыш бара:
Һәрбер бөртек бирсен
Яшәү сутын солдат ашына.
Һәрбер бөртек барсын ядрә булып
Явыз гитлерчылар башына.

Газизә күңелендә шул уйлар.
Хатыннар чалгылар яныйлар.
Хатыннар кар ярып баралар.
Ак карда тезмәләр, тезмәләр.
Ах, салкын — түзәләр, түзәләр.
Сизелми тәннәрнең сызлавы.
Авыр шул җаннарның сызлавы.
Ишетелә ак карда нибары
Чаж да чож чалгылар чажлавы.
Ә уйлар урыйларерактан.
Куркытмый аларны салкыннар.

Әйтерсең лә уйлар — йөрәкне
Гомергә җылыткан ялкыннар.
Газизә хәтерли барын да:
Ялкынын, салкынын — барын да.

4

...Кич иде.
Июньнең бер киче.
Ай нурын ябынган тугайлар...
Таллыкта серләшә тургайлар.
Таудагы чишмәнең тавышы
Урамнар буенча йөгерә.
Шаян җил, каенга сыенып,
Тасмалап-тасмалап чәч үрә.
Бакчада тавышлар:
— Яратам, яратам!
Тавышлар танышлар.
Ах, бик танышлар!..

Ананың йөрәге тетрәде.
Нигә соң ачты ул тәрәзне?!
Сөенеч һәм сагыш ялкыны
Яңагын кыздыра, яндыра:
«Улым бит, Илдарым,
Күрше кыз янында!»
Тавышлар ишетелә тагын да.

«Эх, еллар, үттегез йөгереп.
Үсте бит, җитте бит Илдарым.
Яңа бит үземнең тилереп
Сөешеп йөрешкән елларым...» —
Сөенде, көенде Газизә,
Карашын тын айга текәде:
Ул аннан йотлыгып-йотлыгып
Саматның карашын эзләде.

Илдарның дулкынлы чәчләре,
Чем-кара бөркеттәй кашлары,
Ак йөзе, буй-сыны, атлавы —
Торганы ул инде, атасы.
Тәрәздән ике күз
Тын айга эндәшә.
Күңел бит,
Күңелнең үз теле,
Эндәшмәс ай белән сөйләшә.
«...Тик шушы минутта, әй, Самат,
Терелеп син кабат,
Ишетсәң иде тик бер кабат
Улыбызның мәхәббәт сүзләрен...» —
Яшь юды ананың күзләрен.
«...Саматым, бу синең сүзләрең.
Саматым, бу синең тавышың,
Бу синең тавышың!..»
Керфектән мендәргә тәгәри
Сөенечләр,
  көенечләр,
    сагышлар...
Бакчада тагын да тавышлар:
— Яратам, яратам!..

5

Минутлар, минутлар...
Кайчакта аргамак шикелле,
Уйнаклап, ашкынып үтәләр.
Кайчакта телгәләп бәгырьне,
Көйдереп, яндырып китәләр.
Минутлар, минутлар...
Таң ата офыкны ал итеп,
Нурларын өләшә наз итеп.
Офыкта ал тасма — таң юлы,
Тәрәзгә сарылган таң нуры.

Тәрәзнең пәрдәсе охшаган
Балланып тулышкан кәрәзгә.
Ананың күзләре — тәрәздә.

Илдары ишекне чак кына
Ачты да, атлады сак кына.
Әнием йокласын, дигәндер,
Әнием сизмәсен, дигәндер.
Ана соң йоклармы, сизмәсме.
Уйлары гомернең давыллы,
Таш-таулы юлларын гизмәсме?!

Таң һаман яктыра, яктыра,
Елмаеп үзенә чакыра.
Офыктан, бәй, кара, кабарып
Бер болыт күренә каралып.
Коточкыч бер ерткыч шикелле
Ул таңның ал төсен кимерә.
Дөм-кара шәүләсе тәрәздән
Балланган кәрәзне җимерә.
Бу таңда шул кара болыттай
Бер хәбәр таралды Илемә,
Кәрәзле бал сыман җиремә:
— Сугыш! Сугыш!
Өзелде бәгырь.
Кысылды сулыш.

6

Июньнең кояшы кыздыра.
Яктысы төшми шул йөзләргә.
Кояшның шат, көләч нурлары
Кучми шул күзләргә.
Газизә сохари тутыра.
Сохари кипшенгән, коп-коры.
Эчә ул ананың күз нурын.

Эчә ул ананың улына
Мәңгелек сөюен.
Эчә ул ананың фашистка
Нәфрәтен, ләгънәтен.
Газизә сохари тутыра.
Керфектән тәгәри тамчылар:
Нәфрәтләр,
ләгънәтләр,
ачулар...
Газизә сохари тутыра.

7

Кыш. Мич яна.
Чытырдый утыннар.
Юллыкка ашыга төтеннәр.
Өй караңгы.
Мич якты.
Җылыта аякны.
Тик җанны
Мич кенә җылыта алмый шул.
Җаннарың өшегән чакларда
Җылысын йөрәккә салмый шул.
Газизә күзләрен текәгән
Мичтәге ялкынга.
Күршеләр утыра янында.
Юк, күрми Газизә һичнәрсә.
Күзләре мичтәге ялкыннан
Нәрсәдер эзлиләр.
Бәгырьне өзәрлек шул хәбәр.

Оегын алдылар кубарып,
Туңган ул бозланып, укмашып.
Сизелми тәннәрнең сызлавы,
Авыр шул җаннарның сызлавы.

Мич яна.
Утыннар чытырдый.
Кулында ут-кәгазь кыштырдый:
«...Улыгыз батырларча...».
Күк кәгазь кыштырдый.
Ялкыннар әйтерсең тереләр.
Ялкыннар ул булып пышылдый:
«Әнкәй, әнкәем!
Ышанма, мин исән!..»

Ә кәгазь кыштырдый:
«Соң ни хәл итәсең ышанмый...»

...Җир һәм күк тоташкан мәл иде.
Таулар да күккә ашкан мәл иде.
Танклар киләләр ажгырып,
Фашистлар киләләр кан ерып.
Алда — гарасат.
Артта — башкала.
Йә үлем, йә җиңү! —
Баш ияр идеме
Ул шуннан башкага, —
Йөрәген ут итеп атты ул,
Үлемнең авызын япты ул:
Танкны ут-ялкын ялмады.

Ут-ялкын — күз алды.
Ут-ялкын — йөрәктә.
Ут-ялкын таралды
Йөрәктән-йөрәккә,
Төяктән-төяккә.
Бу, ана, ул иде.
Синең дә йөрәгең
Бит шушы минутта:
«Нәкъ шулай бул!», — диде.
Кем бирде Илдарга бу көчне?!

Кем бирде бу хисне?!
Кем аның күңеленә нур чәчкән?!
Син, ана.
Син, ана!

8

«...Улыгыз батырларча...»
Шушы хәбәр
Телеп үтте ана бәгырен.
Көйгән ирен ялкыннарга карап
Пышылдады:
«Балам, кадерлем!..»
Эштән кайткан иде.
Аяк туңган,
Аяк гөбе кебек шешенгән.
Шатлык кына түгел, зур кайгы да
Куәт бирә икән кешегә —
Чалгы алып ана кырга чыкты.
Ана алдан бара кар ярып.
Ә җил җылый.
Басу буйлап үтә
Кар туздырып, ярсып, сызгырып.

Ана күз алдында — кичәге мич.
Чатыр-чотыр килә утыннар,
Сөйләшәләр сыман ялкыннар.
«Әнкәй, әнкәй,
Ышанма, мин исән...»
Ут-кәгазь кыштырдый:
«Соң ни хәл итәсең ышанмый...»
Чалгылар чажлыйлар чаж да чож,
Кырпак кар өстеннән чаж да чож...

Әй, тормыш!..
Иңнәргә тауларны саласың,

Җаннарны туңдырып аласың.
Ә йөрәк көчле шул:
Сөюне,
  нәфрәтне,
            ачуны —
Җыр итә. Газизә җыр көйли.
Җил улый,
  җил җылый,
            җыр сөйли:
«...Каз бәбкәләре лә сары икән.
Тезелеп-тезелеп суларга бара икән.
Йөрәк башларына кан саудырган
Йөрәк ярып чыккан бала икән...»

Аксылу

Баллада

Ак толымын тузгытып,
Күңелдә моң кузгатып,
Кояш нурында уйнап,
Урал итәге буйлап,
Агыйдел ага, ага,
Ниләрдер сөйләп ярга.

Борын-борын заманда
Менә шушы урында,
Тау-урманнар куенында
Яшәгән, ди, бер халык,
Кайгысын я шатлыгын,
Йөрәк дәртен, сафлыгын
Курай моңына салып.

Бу тарих булган күптән,
Телдән-телләргә күчкән.

Бардыр әкияте дә,
Бардыр хакыйкате дә.
Миңа сөйләде җилләр,
Ә җилләргә — үләннәр.
Үләннәргә — йолдызлар
Җемелдәп сөйләгәннәр.
Ә мин сезгә сөйләдем,
Гадәтемчә көйләдем.

1

Күкне каеп алсуга,
Сызылып кына таң атты.
Бөгелә-сыгыла таллыклар
Сандугачын сайратты.
Чылтыр-чылтыр чишмәләр
Һәр якка җыр таратты.
Менә шулай бер мәлдә
Урал батыр өендә
Бер кыз дөньяга килде:
Бер бите кояш иде,
Ә бер бите ай иде,
Күзләре йолдыз иде —
Ай-һай чибәр кыз иде.

Таң аша туды ак көн,
Шундый чуаклы саф көн.
Урал батыр кызын да
Атадылар: Аксылу.
Шулай диде бар халык:
«Юлдаш булдың ак көнгә,
Шундый аяз, саф көнгә,
Аксылукай, Аксылу,
Кешеләрнең күңеленә
Ак нур булып бак сылу».

Курай көйләр көйләде,
Чәчән шигырь сөйләде.
Җыр суздый асыл уллар,
Биеде сылу кызлар.
Ак кымыз торды пешеп.
Куаныч баштан ашып,
Бәйрәм булды җиде көн,
Җиде көн һәм җиде төн.

2

Ай үсәсен көн үсеп,
Аксылу буйга җитте.
Кояш иде бер бите,
Тулган айдай бер бите.
Зифа талдай буй-сыны,
Камышмыни толымы.
Күзләре йолдыз иде —
Шундый чибәр кыз инде.
Эшкә дисәң, кулларыннан
Гөлләр түгелер иде.
Җырлаганда, сандугачлар
Туктап, тын калыр иде.
Аның юмарт күңеленә
Чишмә сокланыр иде.
Тик сылу кемне сөяр?
Мондый яр кемгә тияр?

Аксылуның бер карашы
Күңелләрне тетрәтте,
Елмаюы йөрәкләрдә
Гыйшык уты дөрләтте.
Гыйшык утыннан хисләнеп,
Егетләр шагыйрь булды,
Үзәгемне өзәсең, дип
Җырлар чыгарып булды.

Тик Аксылу барына да
Сеңелкәш булып калды.

Юк, вәгъдә итмәде ул
Берәүгә дә йөрәген.
Бер олы бәйрәм таңында
Бөтен җәйләү мәйданында
Әйтте үзенең теләген.
Әйтте: «Ирек сөямен.
Ирек сөйгән халкым өчен
Ялкын булыр йөрәгем,
Алкын булыр йөрәгем».

Урал әйтте: «Дөрес, балам,
Син халыкның нур-йөзе.
Син — матурлык. Синең белән
Горурланыр җир йөзе.
Һичберәү дә сине күреп,
Сине сөеп туялмас.
Тик берәү дә, үземә, дип
Сине бикләп куялмас.»

Һәм шуннан соң бар гашыйклар
Тынычланды, күнекте.
Барысы да Аксылуны
«Сылуым» дип йөртте.
Исемен кушып җыр итте.

3

Ерактамы, якындамы —
Бер кабилә бар иде.
Ул кабиләнең башлыгы
Сылу батыр шаһ иде.
Кыюлыгы, җитезлеге
Тирә-якка дан иде.

Теләгенә каршы килгән
Беркем булмаган иде.
Аксылуның сылулыгын,
Горурлыгын, кыюлыгын
Бермәл яшь шаһ ишетте.
Әйтте: «Эзләдем шул кызны,
Хыялымдагы йолдызны.
Тик шул миңа иш», — диде.
Күк тулпарын ашкындырып,
Яшь йөрәген талпындырып,
Шаһ менә килеп җитте.
Бар авылны таң калдырып,
Баскан җирдә ут яндырып,
Урам буйлап шаһ үтте.
Зифа талдай сылу кызлар:
«Эх, егет!» — дип аһ итте.
Кипаристай буе-сыны,
Алтын-көмеш кылычы-кыны.
Иңендә аучы бөркет,
Карашлары — утлы хәнҗәр,
Үзе гаярь, үзе зәһәр —
Арыслан иде егет.

Аксылу да аны күргәч,
Үз-үзен аңламады.
Шаһның сылу буй-сыныннан,
Һәрбер кыю кылыгыннан
Күзләрен алалмады.
«Нәрсә булды бүген миңа?
Йөрәгем яна нигә?
Шул мәхәббәт дигәннәре
Килдеме әллә миңа?
Бөтен көчем, ялкын хисем
Халкым өчен, дидем лә.
Беркемгә дә гашыйк булмам,
Ирек сөям, дидем лә...»

Аксылукай гашыйк иде,
Көн-төн шаһны уйлады.
Ә шулай да шаһ алдында
Горурлыгын җуймады.

4

Шаһ таң калды бер күрүдә
Аксылуның ак йөзен:
«Шушы, — диде, — мәхәббәтем.
Шушы, — диде, — йолдызым».
— Әйдә, — диде, — киттек, — диде.
— Калдыр илең-җиреңне.
Учым төбендә йөртермен
Сине, бердәнберемне.
— Мин Аксылу, — диде сылу, —
Чишмәләр, таулар кызы.
Тау-чишмәне алга манып
Аткан ал таңнар кызы.
Мәхәббәтем — халкым, диеп
Вәгъдә иткән сүзем бар.
Тәүдә, егет, җирем, халкым
Рөхсәтен ал, сүзен ал.
— Рөхсәт, имеш! —
Тирә-якны
Яңгыратып көлде шаһ.
— Халык, имеш!
Мин теләсәм,
Биеп торыр бар җиһан.
Гайрәтем бар, гаскәрем бар,
Инде сөйгән ярым бар.
Халык нәрсә?!
Икебез бар.
Син бар — бердәнберем бар...

— Бик ашыкма, — диде сылу, —
Әнә, тауларга кара.
Алар сиңа ачулана,
Тауда болыт кабара.
Ни булыр дип, ни көтә дип,
Чишмә тора тын калып.
Җәйләү мәйданына кара,
Безгә баккан бар халык.
«Сылуыбыз» диеп йөргән
Егетләргә күзең сал.
Иң беренче син аларның
Рөхсәтен ал, сүзен ал.
— Кайсы егет миңа каршы?
Әйдә чыксын алышка.
Әйткәнем бер, әмерем бер.
Киттек, җаным, карышма...

5

Шулвакытны Аксылуны
Иң яраткан бер егет
Сикереп чыкты, кыядагы
Ярсу яшь бөркет кебек.
— Үлсәм үләм, сиңа бирмәм.
Аксылу ул безнеке.
Ата-баба ырысын саклар
Тау-чишмәле җирнеке.
Аксылу ул — матурлык ул,
Матурлык ул җиһанга.
Матурлыкны бикләтмәбез
Таш тирмәгә — зинданга.
Шулчак һәркем хәйран калды,
Ни эшли, дип, бу бала.
«Харап була, кем генә соң
Шаһка каршы тора ала?!
Гайрәте бар, гаскәре бар,

һәммәбезне изәр бит...»
Пәһлевандай ирләр әйтте:
«Куй, балакай, кире чик.»

Яшь егетнең күзләрендә
Очкыннар уйный иде.
Үз җанын түгел, ул илен,
Намусын уйлый иде.
Алыш китте.
Кылычларда
Ялт та йолт уйный очкын.
Башка егетләр кайда соң? —
Ярдәмгә чыкмый һичкем.
Алыш кыза.
Яшь егетнең
Кылычы сына бермәл.
Кылычсыз җанны җәзалый,
Шаһ өчен ни-нәрсә җәл?

6

Бу вәхшилек Аксылуның
Йөрәккәен тетрәтте.
Сөю тулы күкрәгендә
Нәфрәт утын дөрләтте.
Шаһка әйтте:
— Әнә юлың!
Сөюеңне таптадың.
Халкым-җирем мыскыл итеп,
Намусыңны тапладың...
Шаһ аптырап аңа бага:
— Бу сине сөйгән өчен.
Күз алдында гайрәт-сыным,
Кодрәтем, дәһшәт-көчем...
— Югал күздән!
Мәхәббәтем

Бетте ул, китте, китте.
Яшен кебек ялтлап үтте,
Таңгы чык кебек кипте.
Халкым йөзендәге кояш
Балкыса гына бары,
Шатлык җырлап саф чишмәләр
Алкынса гына бары,
Мәхәббәтем яшәр минем, —
Мин чишмә-таулар кызы,
Тау-чишмәне алга манып,
Аткан саф таңнар кызы.

7

Зәһәрләнде тәкәббер шаһ,
Күзләре янды уттай.
Аксылуга арыслансдай
Ташланды шул минутта.
Карчыгадай эләктерде
Аның нечкә биленнән.
Тулпарына салып кызны
Алып качты иленнән.
Кан калтырап калды халык,
Зар елады әнкәләр.
Егетләрне яуга өндәп
Оран салды чәчәннәр.
Ачу белән, нәфрәт белән
Киерелде җәяләр.
Карак җилә, карак оча, —
Ерак калды җәйләүләр.

Шаһ җәһәтләп, ашыктырып
Камчылады тулпарын.
Кем ишетсен, кем тыңласын
Аксылуның моң-зарын.
Юк, ишетте.

Кем эндәште?
Тау чишмәсе түгелме?
— Сикер минем янга, сылу,
Үткән чакта бөгелне...
Кыз ычкынып шаһ кулыннан,
Очты менә таллыкка.
Тал эндәште:
— Ашык, сылу,
Тугайлыктан таулыкка.

Ачуыннан ярсыды шаһ:
— Минме калдым хурлыкка?! —
Кылычында яшен уйный,
Шаһ кулына юлыкма!
— Йә минеке, йә — һичкемгә! —
Тешен кысып ант итә.
Тал-камышлар яра-яра
Сылуны куа китә.
— Менә җиттем. Менә тотам! —
Ярсып бара шаһ-карак.
— Әткәй! — диеп тавыш бирә
Сылу тауларга карап.
Ерак юлда була Урал,
Ә ишетә шулай да.
Эһ, дигәнче тау-таш үсә
Тал-камышлы тугайда.

8

Арада тау.
Кая туктау, —
Үтә шаһ тауны урап.
Ак күбеккә баткан тулпар
Бөгелдә кала колап.
Кала тулпар.
Кая туктау,

Шаһ бара, бара ярсып.
«Менә җиттем. Менә тоттым.
Китә алмассың качып.»
— Әткәй! — диеп аваз бирә
Өзәләнеп Аксылу.
Урал әйтә:
— Шаһка булма!
Ак су булып ак, сылу...
Ак су булып агып китә,
Чабып китә Аксылу.
Шаһ үзәнгә ятып елый:
— Яңадан кайт, кайт, сылу!.. —
Күкрәгеннән йөрәген алып,
Ташлый елга алдына.
Ә ак елга таш йөрәккә
Туктап ала аз гына, —
Таш йөрәктән ни соң файда —
Елга ары йөгерә,
Сусап кипкән кара җиргә
Шифалы дым бирергә.
Матурлыкны югалттык, дип,
Таулар үксеп елады.
Ә чишмәләр ашыга-ашыга
Куа китте елганы.
— Нигә безне матурлыктан
Мәхрүм иттең, Аксылу?
Кайт яңадан, — дигән алар. —
Ак кыз булып бак, сылу.
Ә ак елга елмайган да
Әйткән:
— Сезне ташламам.
Матурлыкны, сафлыкны бит
Мин һаман сездән алам.
Әткәемнең сүзләренә
Тугры булырмын мәңге.

Халык җырлар гомер буе:
«Агыйдел буе ямьле...»

9

Стәрлегә барган чакта
Сул як кулга күзең сал.
Күккә ашкан бер тау булыр:
Үзе как ул, үзе чал.
Бу тау — Шаһтау.
Ә арырак
Йөрәктау да күренер.
Урап алган ак томаннар
Болытларга үрелер.
Таш булса да, йөрәк бит ул, —
Алсу булыр таңнарда.
Шул тәкәббер шаһ исеме
Калган как таш тауларда.
Ә Агыйдел — Аксылукай
Шуннан ага чылтырап.
Кояш чыга.
Агыйделкәй
Алтын сыман ялтырап,
Көлеп ята.
Буйлап үтә
Уралтауның итәген.
Тынып тыңла, —
Таулар аша
Дәртле бер җыр ишетәсең:
«...Агыйделкәй кайда? Ай, тугайда.
Агыйделкәй сыман су кайда?
Агымсу, Агыйдел буйлары.
Агыйделкәй суның, ай, буйлары.
Ямьле чагы аның язгы айда.
Агымсу, Агыйдел буйлары.
Агыйделкәйләрнең, ай, буенда

Сандугачлар сайрый муелда.
Агымсу, Агыйдел буйлары.
Идел суын эчкән ир-арыслан
Яман теләк йөртмәс уенда.
Агымсу, Агыйдел буйлары...»

Шулай җырлап ата моңда
Шат йөзле нурлы таңнар.
Җыр ярата, җыр тарата —
Бу яклар — җырлы яклар.
Җыр тарала үзәннәргә,
Калаларга, авылга.
Җырны тыңлап,
Чылтыр-чылтыр
Агып ята Ак елга...

Каен суы

Поэма

Ап-ак башы ята ак мендәрдә.
Ап-ак башы Каен бабайның.
Гомер буе исеме Каен булды,
Җисеме каен булды Юлайның.

«Мендәргә дә салды менә дөнья.
Гомеремнең, бәлки, соңыдыр.
Мәңгелеккә сиңа төяк, диеп,
Чуактауга кабер уелыр.
Үпкәләп тә булмый дөньясына.
Аш ашалган,
Яше яшәлгән.

Әнә урман шаулап яфрак яра,
Тагын яшелләнгән, яшәргән.
Ә мин инде менә ак мендәрдә.
Юк, бирешмә, Юлай, бирешмә.
Дөнья имин, тормыш матур чакта
Болай ятуларың килешми.
Урман чакыра сине, урман чакыра,
Җыр тыңларга чакыра кошларың.
Чакырса да, барып булмый икән,
Мендәрләргә салгач башларың...»

Оча-куна килеп, аккош сыман,
Ак халатлар кереп әйләнә.
— Каенсылу килсен, Каенсылу...
Шулай ди ул кызы Ләйләгә.
Врач Ләйлә керә:
— Әткәй! Нәрсә?!
Кызы үзе дәва күңеленә.

Йокымсырый Юлай.
...Төшендә дә
Ак каеннар килә өенә.
Бәйрәм, имеш.
Менә каен-кызлар,
Бөркәнешеп яшел шәлләрен,
Биеп йөри
Идән уртасында,
Өе киткән шундый ямьләнеп.
Менә бермәл
Барлык каен-кызлар
Аккош булып канат җилпиләр.
Иңбашына килеп куналар да
Ак чәчләрен сыйпап китәләр.
Көтмәгәндә явыз бер Каракош
Арасына керә аларның:

— Мин Әҗәл! — ди, —
Кайсыгыз аның җаны?
Җанын ала килдем Юлайның.
Тоттырмаска теләп әй аккошлар
Урап-урап оча һавада.
Ә Каракош: «Әҗәл! Мин Әҗәл!» — дип,
Аккошларны йөри куалап.
Күзен ача Юлай ыңгырашып:
«Ә шулай да Әҗәл сагалый.
Күтәр башың, Юлай, югарырак,
Бирешергә алай ярамый...»

Булмадымы Илнең алышканы
Кара эчле Каракош белән?!
Булмадымы аның язмышының
Охшаш чагы шушы төш белән?!
Килмәдеме фашист: «Мин — Әҗәл!» — дип,
Яшел җирне җимереп, көйдереп?
Булмадымы аның дөмеккәне
Үз канына үзе төелеп?!
Булмадымы, Туган илне саклап
Өзелеп калган япь-яшь гомерләр?!
Алар төсе, әнә, каеннарда.
Тыңла гына,
Каеннарны тыңла —
Барысын да сөйләп бирерләр.

Кар шикелле ап-ак тәннәрендә
Кара тимгел саклый каеннар.
Юлай өчен алар — кайтмый калган
Коралдашлар,
Шулай мәңгелеккә
Тимгел булып күчкән кайгылар.

Гомереңең бөтен кайгысын да,
Шатлыгын да саклый каеннар.
Аның өчен шушы ак сыннарда
Йөрәк тетрәтерлек моңнар бар.

«Ә шулай да юкка яшәлмәде.
Төсем кала җирем йөзендә.
Шуны күрү үзе бер юаныч,
Бер юаныч гомер көзендә.
Юкка яшәлмәде...»
Күз алдыннан
Йөгереп үтте бөтен тормышы.
Уйлап торсаң, аның бар гомере
Яшәү белән Әҗәл сугышы.

...Юлай кырды фашист козгыннарын.
Пулеметы кызды ут булып.
Соңгы гранатасын ташлаганда,
Аяк асты гүя убылып,
Җиргә ауды.
Тоташ дөнья әйләнде.
Хәтерләми Юлай башкасын.
Аңына килде бермәл:
«Кайда соң мин?
Нинди урман? Кайда ятам соң?»

«Тере икәнмен әле...
Су булсачы!..»
Исен җуйды Юлай тагын да.
Тып-тып итеп тамган тамчы тавышы
Колагына килеп чалына.
Тамчы тамды.
«Әллә төш булдымы?
Юк, төш түгел,
Тама: тып, тып, тып...»
«Әллә үлем шулай тарткалыймы,

Бер йоклатып, берчә уятып?!»
Тып-тып, тып-тып...
Тамчы тама, тамчы.
Баш очында гына, якында.
«Тик бер генә уртлам су!
Су йотсам,
Үлем алмас иде алкымнан...»

«Ут-давылда калган шул урман бит...»
Ята Юлай каен янында.
Яшәү булып,
Яшәү җыры булып
Тамчы тама икән каеннан.
Яраланган каен.
Ярасыннан
Суты тама,
Тама тып та тып.
Тамчы түгел,
Йөрәк, йөрәк тибә,
Йөрәк тибә, тибә дөп-дөп-дөп...
Көйгән иреннәрдә — каен суы.
«Там, там, тамчы,
Там, там тагын да.
Әй, каенкай,
Сутың тәнем буйлап
Яшәү уты булып тарала...»

Сөялде ул менә ак каенга.
Кан эчендә иде аягы.
Каны ага һаман
Ярасыннан —
Хәлсезләнгән икән кан агып.
Изаланып,
Хәлсез кулы белән
Ул бәйләде аяк ярасын.
Ашыкма әле, әҗәл,

Бар минем, бар
Яшәү уты белән янасым...»

Урман аръягында,
Көнбатышта
Снарядлар ярыла гөрселдәп.
Тоташ урман гүя
Шартлау саен
Калтыранып куя, дерелдәп.
«Безнекеләр анда.
Фронт алда.
Мин дә хәзер анда булсамчы,
Фашистларның өнен туздырганчы
Дуслар белән юлны узсамчы...»
Калкынмакчы булды.
Ул егылды.
Ыңгырашып аңын югалтты.

— Тып-тып, тып-тып, тып-тып...
Тамчы җыры
Тагын килеп, аны уятты.
«Миләүшәмне кайтып күрсәм иде.
Кочагыма алсам Ләйләмне.
Исән кайтсам, каен урманына
Күмәр идем бөтен тирәмне...»
Тагын йотты Юлай каен суын,
Җиңеләйде бераз сулышы.
Уйлар акты,
Ерак-еракларадан
Ишетелде яшьлек тавышы.
Яшьлек, яшьлек...
Алар җыелыр иде
Чуактауга кичке уенга.
Авыл тавы гөрләп торыр иде,
Гөрләр иде төннәр буена.
Таң атканчы алар уйнар иде,

Биер иде җирне селкетеп.
Юлай курай тартыр,
Миләүшәсе
Җырлар иде йөрәк җилкетеп.
Аһ, ул чаклар,
Бары да хәтерендә:
Уеннан соң икәү кайттылар.
Атладылар сүзсез.
Ә йөрәкләр
Бер-берсенә тәрәз кактылар.
Сүзсез генә кире борылдылар
Чуактауга,
Чишмә ярына.
Тәүге сөю сүзен сөйли, көйли
Таң да, тау да, тал да — бары да.

Шушы сүзне кошлар кабатлады.
Чишмә акты чылтырап, куанып.
Иреннәре бергә кушылдылар,
Кушылдылар ярсып, ут янып...
«Эх, бу минут!
Кабатланмас минут.
Аңа
Сердәш иде каен, ак каен.
Бик күпләрнең йөрәк моңнарына
Сердәштер ул каен, мөгаен.
Уйлый алар бермәл,
Языйкчы, дип,
Исемнәрне:
«Юлай — Миләүшә».
«Юк, язмагыз!» — диеп гашыйкларга
Кушылып типкән йөрәк эндәшә.

Язмадылар.
Калды йөрәкләрдә.
Йөрәкләргә язган җуелмый.

«Ах, каенны киртләп шулвакытта
Әл дә язмаганмын», — дип Юлай
Сөенеп куйды.
Үзе яраланды, —
Яшәү бирде миңа ак каен.
Онытасым юк изгелеген,
Аны
Күз карамдай күреп саклармын...»
Яшәү бирде,
Газиз ана кебек,
Аналар соң шулай түгелме?! —
Типсен өчен сабый йөрәкләре
Аямыйлар хәтта гомерне.
Ана кебек,
Изге ак каеным,
Илем төсе синдә сынлана.
Буыннардан-буыннарга күчеп,
Юккамыни исемең җырлана?

Зәңгәр күзләр бакты зәңгәр күккә:
Томан аша кояш күренә.
Кояш түгел, өмет,
Өмет карый,
Өмет карый күкнең түреннән.

Ул хушлашты изге каен белән.
Ыңгырашып кына шуышты.
Ул шуышты туктап тыңлый-тыңлый
Һәрбер кыштырдауны, тавышны.
Озак барды.
Тәмам хәлдән тайды.
«Үләм микән әллә шушында?..»
Явыз әҗәл белән якалашкан
Ялкын иде аның сулышында.
Күрде бермәл:
Агач арасыннан

Кемдер килә. Дусмы, дошманмы?!
Шәфкать туташ! Килә шәфкать туташ! —
Үз күзенә үзе ышанмый.
Яшәү, яшәү!..
Ап-ак фәрештәдәй,
Әнә аңа бер кыз якынлый.
Шәфкать туташ килде яшәү булып,
Ала алмас әҗәл алкымнан...

Томан аша килгән якты өмет
Алдамады Урал егетен.
Изгеләрдән изге, кадерле шул,
Куәтле шул яшәү өмете.
Шәфкать туташ кебек ярдәмчел дә,
Ярың карашыдай назлы ул.
Болыт ярып чыккан кояш сыман,
Илгә килгән җиңү язы ул.
Мәтрүшкәле көләч авыл тавы,
Бәбкә үлән япкан юллары.
Муенына сарылып: «Әткәй!» — дигән
Ләйләсенең нәни куллары.
Елтырап кына аккан Кәнчишмәсе,
Суларының сихри сафлыгы. —
Ах, ул өмет — яшәү өметләре!
Исән йөреп кайту шатлыгы.
Ай, ул өмет, яшәү өметләре!
Шул булмаса җиңәр идекме?!
Шул булмаса җитмеш үлем аша
Өйгә кайтып килер идекме?!
Аксый-аксый,
Үргә карый-карый
Юлай бара урман юлыннан.
Йөгереп килеп каршы алыр кебек
Ак каеннар урман буеннан.
Сагындырган бары да.
Бара Юлай,

Күрергә дип тизрәк ашыга.
Каеннар соң кайда?!
Нигә алар
Йөгерешеп чыкмый каршыга?!
Каеннар юк,
Әнә пеләш төпләр,
Моңаешып төпләр карыйлар.
Төпләр түгел,
Алар сугыш салган
Төзәлмәслек авыр яралар.

Шул чагында ап-ак төпләр
Кузгалышып алды сыман.
Дөнья куйган бабасының
Тавышы яңгырап калды сыман:
— Олы урман исән, улым,
Яшь каеннар кырылдылар.
— Тауларымның бизәгенә
Кемнәр шулай кул салдылар?
— Монда да бит авыр булды.
Бик кызма әле, Юлай олан.
Бу сугышта катнашмыйча
Калды дисең мәллә урман?
Булдымыни тартыр атлар,
Утын ташыр машиналар.
Сугышларның гарасаты
Килде алар башына да.
Чаналарда шуып төште
Утын булып каеннарың.
Тик шуларның уты белән
Туңмый калды сабыйларың.
Баш әйләнә,
Йөрәк тетри:
Төпләр тәндә яра сыман,
Мыегы да чыкмас борын
Яуда ауган солдат сыман.

«Төзәтергә, уңалтырга
Җир тәненең яраларын.
Яшәртергә, яшәтергә
Болыннарын, далаларын...»
Зур алышка чыкты Юлай —
Солдат Юлай, җырчы Юлай.
Көрәш юлы кешеләргә
Һәрчак җиңел булмый шулай.
Өйдән-өйгә йөрде Юлай
Сөйләп урман әкиятләрен:
Коры җилгә каршы торыр
Үзенең олы ниятләрен.
Кайберләре: «Тиле, — диде, —
Кеше урман утыртамы?
Шөкер итсәң, җитә, — диде, —
Табигатьнең бар урманы».

Икенчеләр шикләнделәр:
«Уең һәйбәт тә бит, Юлай,
Черек картуф ашап кына
Андый эшне җиңеп булмый.»

Әкият-урман атасының
Мәктәп булды терәккәе.
Талу белмәс уң канаты —
Миләүшәсе, йөрәккәе.
Әле дә китми колагыннан
Дөңкелдәве көрәкләрнең.
Күз алдында җир казыганы
Җептәй генә беләкләрнең.
Ул балалар күптән инде
Үзләре дә ата-ана.
Ә эш калды: каенлыкта
Бүген кошлар сайрый, әнә...

Ап-ак башы ак мендәрдә,
Ак мендәрдә Каен бабай.
Гомер үтә аккан судай,
Картаюга көйми Юлай:
«Яшьлегем, — ди, — җиргә күчә,
Яшьлегем бит җирдә кала».
Шаулап үскән һәрбер агач,
Әйтерсең лә аңа бала.
Бала дию генә ансат,
Үстерүе, ай-һай, авыр.
Тып-тын гына түгел гомер,
Килә коен, килә давыл.
Булмадымы бозга катып,
Туңган чагы салкыннарда.
Каеннарым янмасын дип,
Янган чагы ялкыннарда?!
Ямадылар яраларын,
Бары тәндә эзләр калды —
Тәндә калды, җанда калды,
Җөйләр сыман каендагы.
Җирнең дә бит яралары
Уңалмаслык сыман иде.
Ә яралар уңалдылар,
Авыр чаклар ерак инде.
Җир яшәрде, яшелләнде.
Менә тагын җитте язлар.
Ак каеннар ясанышып
Яз каршылый гүя кызлар.

«Ә мин ятам монда ак мендәрдә.
Юк, бирешмә, Юлай, бирешмә,
Дөнья имин, тормыш матур чакта
Болай ятуларың килешми...»
Тәрәз ачып, менә килеп керде
Салкынча җил.
Урман исләрен

Алып килде.
Саф җил сыйпап үтте:
«Бирешмә», — дип аның чәчләрен.
Күк күкрәде.
Юлай дертләп куйды.
Тамчы тамды:
Тып-тып, тып-тып, тып...
«Каен суы мәллә?..»
Тамчы тама
Хәтер учакларын кузлатып.
«Каскагамы тама?!
Юк, тәрәзгә.
Яңгыр ява чиртеп тәрәзгә.
Шундый чакта, Әҗәл, йөрмә әле,
Мин яшәргә тиеш, яшәргә...
Тәүге күкрәү.
Ява тәүге яңгыр.
Әйдә, яусын җирне яшәртеп.
Яшьнә, яшен.
Яшәү яшеннәре
Урманымны үтсен яшьнәтеп...»

Яңгыр узды.
Әнә, кояш чыкты.
Ак мендәргә төшә нурлары.
«Биесеннәр иде нурга коенып,
Кайда минем каен кызлары?!»

Күзен йомды. Тагын төш, саташу:
Ак каеннар килгән җыелып.
Бизәнешкән алар,
Иңнәреннән
Көмеш тәңкә тора коелып.
— Каен бабай,
Сиңа килдек, — диләр. —
Синнән башка безгә күңелсез.

— Килгәнсез лә икән...
Һәйбәт булган.
Әйдә, кызлар, өйгә үтегез.
— Без бит күмәк,
Анда сыялмыйбыз...
— Каеннарым килгән, кызларым.
Чыгыйм әле, кызым Ләйләм, яме?
— Каеннарың көтәр, савык әле.
— Бик күрәсем килә үзләрен.
Төркем булып килгән алар әнә.
Нинди яшьләр, нинди гүзәлләр...
— Без донорлар булып килдек сиңа,
Коткарырга килдек Әҗәлдән.
Бары каен суы шифа, диләр,
Килешә, диләр, синең чиреңә.
Савык кына — барыбыз да әзер
Сутыбызны бүлеп бирергә...

Күзен ачты Юлай.
— Ләйлә кызым,
Ак мендәрдән мине алыгыз.
Түшәккенәм булсын яшел чирәм,
Урманыма алып барыгыз.
Савыгырмын сыман шунда барсам,
Соңгы үтенечем, балалар...

Дәваларын тапсаң, уңала, ди,
Хәтта уңалмаслык яралар.
Ак халатлар Каен бабайларын
Яшь урманга алып баралар.
Яфрактагы яңгыр тамчылары
Җемелдәшеп озатып калалар.
— Яшәрә бит урман, балалар...
Карашлары картның очкынланды.
Бәреп чыкты шатлык яшьләре.
Яшь каеннар шулчак хөрмәт итеп

Иелеп үпте аның чәчләрен.
— Балаларым, сезне бер күрүем —
Күңелемнең тиңсез дәвасы.
Каен суы калсын каеннарда,
Яшел яфрак булып яралсын...

Авырулар да, хәтта әҗәлләр дә
Җиңә алмас җирдә яшәүне.
Табигать һич белми картаюны.
Ничек урман килә яшәреп.
Яшь бөреләр әнә ярылалар:
Тамырлары җирдән сут ала.
Бу мәңгелек яшьлек.
Яшәр өчен,
Янып яшәр өчен ут ала.
Моны сөйли әнә ак каеннар.
Аңла гына, аңла телләрен.
Алар яши тере сыны булып
Җирдән киткән миллион-меңнәрнең.

Юлай бабай басты аягына:
— Каеннарым яфрак яралар,
Гомер дәвам итә, балалар.
Җирнең сутын алып, утын алып,
Ак каеннар яфрак яралар.

Онытмагыз безне, тереләр…

Поэма

Аткан таңнар кабат атмыйлар.
Аккан сулар кабат акмыйлар.
Үткәннәр дә кире кайтмыйлар.
Моңа инде күптән күнегелгән.
Күнегелгән дә, әмма исемен, төсен
Кем генә соң икән ала алыр,
Ала алыр аның күңеленнән.
Бүген таң алдыннан Хәмитҗанын
Җамал күрде тагын төшендә.
Үлгән кеше төштә сөйләшми, ди.
Ул сөйләште, тере кешедәй.
Утыра, имеш, мәҗлес түрләрендә.
Яннарында яшьтәш дуслары.
Бергә-бергә кырда сабан сөреп,
Яргаланып беткән учлары.
Изүләрен, имеш, чишә биреп
Утыра ул бераз елмаеп.
Иңнәрендә — гармун.
Гармун тып-тын.
Гармуны да калган моңаеп.
Эргәсенә җыеп җан дусларын,
Хәмит сөйли,
Сөйли, туктамый.
Гармун тып-тын,
Гармун уйнамый.
Ул сөйләште.
Тик Җамалга карап
Сүз әйтмәде,
Бер сүз катмады.
Егет чактагыдай, керфек сирпеп,
Зәңгәр күзләр аңа бакмады.
Ул сөйләде Мәхмүтҗанга карап,
Кагылып-кагылып аның иңенә:

— Эх, Мәхмүтҗан,
Безнең кебек якын
Дуслашалыр икән кем генә!
Яланаяк Чуактау буенда
Атлар саклаганнар дисеңме,
Син — Мокамай, ә мин Такташ булып,
Шигырь ятлаганнар дисеңме, —
Исеңдәдер бары да.
Каршыгызда
Кушлап үскән имән бар иде,
Безнең кебек шундый пар иде.
Яннарында ике каен иде,
Имәннәргә алар яр иде.
Безнең дә бит ярлар бар иде...

Исеңдәме, тәүдә урам буйлап
Узар идек гармун сыздырып.
Узар идек,
Җамал чыкмый торса,
Өй артыннан барып, кар ерып,
Тыңлар идек.
Тәүдә ишетер идек
Икебезнең йөрәк тибешен.
Көтәр идек —
Таныр идек атлап килешен.

Түбән очтан Зилә чыгар иде,
Нечкә билең, кара кашкаең.
Карчык-корчык: «Ах, бу дүртәү!» — диеп,
Калыр иде кагып башкаен,
Сагына-сагына үткән яшь чагын.

«Сарман» җырын җырлап узар идек,
Узар идек дүртәү урамнан.
Булды микән, Мәхмүт, безнең кебек,
Безнең кебек урам ураган.

Булды микән минем Мәхмүтҗансыз
Чыккан чагым кичке уенга,
Булды микән синдәй биегәннәр
Җамал белән минем туемда?!

Шушы гармуннарны җырлатып,
Сөйгән яркайларны җылатып,
Киттек, Мәхмүт.
Киттек ил белән.
Үксеп калды кышкы бураннар.
Отып калды җырны урамнар:
«Исән булсак, бер кайтырбыз,
Сау булыгыз, туганнар...»

Коралдаш та булдык
Һәм юлдаш та.
Тәннәр янды, җаннар янмады.
Безнеңмени тирләр канга кушылып,
Окоп төпләренә таммады?
Үле гәүдәләрнең арасыннан
Сине тере таптым, Мәхмүтҗан.
Шинель чабуымны чана итеп
Сине сөйрәп кайттым, Мәхмүтҗан.
Көнбатыштан аткан үлем угын
Күкрәгемә әгәр алмасам,
Сиңа тияр иде.
Янар идең,
Янар идең, әгәр янмасам.

Бик көткәндер,
Әйе, бик көткәндер
Гармунчысын моңлы урамнар...
Үксеп елагандыр бураннар.
Еласа да,
Сагынып еласа да,
Кайтып булмады шул, туганнар.

Исемеңне синең,
Нәселеңне
Онытмамын, менә аш, диеп,
Мәхмүтҗан дус, антлар биргән идең,
Кабер туфрагыма баш иеп.

Безнең каберләрне үлән басты.
Күпме гөлләр үсеп шиңделәр.
Күпме күзләр китеп, язлар кайтты,
Күпме кошлар кабат килделәр.
Ядрә сызгырышкан болыннарны
Сандугачлар моңга күмделәр.
Күпләр килеп сәлам бирделәр.
Күпләр килеп башлар иделәр.
Син... килмәдең.
Нигә килмәдең?!
Кайда синең биргән антларың?!
Юк, көтмимен сәлам-хатларың.
Каберләргә хатлар килмиләр.
Үлгәннәр, юк, көтә белмиләр.
Баш очымда тере чәчкәләр тик
Иртән-кичен кешеләр арасыннан
Синең йөзне, сине эзлиләр.

Безме, Мәхмүт, ерак йолдызларга
Хыялларны сөйләп ятмаган?
Без түгелме, хыял-тулпар менеп,
Белем тауларына чапмаган?
Сине бүген зурлап йөртәләр бит,
Йөртәләр бит түрдән-түрләргә.
Икәү хыял иткән сукмаклардан
Үрлисең син һаман үрләргә.
Һич сүзем юк,
Тормыш баскычларын
Тиеш идең шулай үтәргә.

Вакыт тардыр, дөнья мәшәкатьтер,
Мәшәкатьтер шулай күпләргә.
Тик нигә әле авыл очындагы
Йортка, Мәхмүт, керми үтәсең,
Чәчләренә инде чаллар төшкән
Хатынкайны күрми китәсең?
Бер бәйрәмдә уздың каршыбыздан
Зилә белән бергә парлашып.
Уртагыздан барды кызың, улың,
Пар сандугач кебек сайрашып.
«Күрикче әле, — дидең, — Җамалны да».
Зилә китте шулчак үпкәләп:
«Тол хатыннар күреп йөрер булгач,
Нигә, — диде, — сиңа мин кирәк?»
Авызыңны кабат ачалмадың,
Атладыгыз бергә гөрләшеп.
Пәрдә аша Җамал карап калды,
Күз яшьләре белән серләшеп.
Кызыгызга туйлар ясадыгыз,
Чакырмадың анда Җамалны.
Авыз ачтың: «Әллә...»
«Тол хатынны?!» —
Диеп Зилә ачты җәнҗалны.
Шул сүзгәме,
Үзең оныттыңмы —
Хәзер аны күрми үтәсең.
Беләсеңме,
Әллә белмисеңме
Аның күңеленә «Нихәл, яшьтәш!»
Диеп әйтер бер сүз җитәсен?
Уйлыйсыңмы әллә ваксыну дип,
«Малай түгел, самай Мәхмүт» дип?
Соң үзең бит һаман шул ук Мәхмүт,
Сүзләрең дә шул ук, йөзләрең дә,
Күзләрең дә шул ук Мәхмүт бит.

Үпкәләмәс Җамал — күңеле сабыр,
Сиздермәс ул, алчак елмаер.
Ә, бәлки, ул, авыл тынып калгач,
Дүртәү йөргән чакны сагынадыр да
Сулык-сулык килеп елыйдыр.
Ялгызлыкка күптән күнеккән ул,
Мәхрүм түгел әмма хисләрдән —
Яшьлегебез яши күңелендә.

Мәңгелеккә түгел кешегә тән.
Чирек гасыр менә туфрак булып
Һәр яз саен үлән яшәртәм.
Мин риза якты, яшел җирдә
Килер буыннарны яшәтсәм.

Үпкәли дип, Мәхмүт, уйлый күрмә,
Юк, үпкәли белми үлгәннәр.
Мәхмүт дусың антын оныта, дип
Боегалар чәчкә-үләннәр,
Баш очымда үскән ал гөлләр.
Сиңа сөйләр өчен килдем монда.
Көйләп беттем менә бар моңым...

Бөтен мәҗлес басты аягүрә:
— Тик бер генә уйна гармуның...
Керфекләрен сирпеп шунда гына
Зәңгәр күзләр бакты Җамалга.
Яшьлек көе, Сарман көйләренә,
Әй тотынды гармун сайрарга...

Шулвакытта Җамал күзен ачты.
Юк булдылар кинәт бары да.
Тып-тын бүлмә.
Ә урамнар буйлап
«Сарман» көе генә агыла.
Гармун уйнап яшьләр кайтып бара,

Кайтып бара кичке уеннан.
Гармун сайрый.
Яшьләр җырлап кайта
Стәрлекәй суы буеннан.
«...Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Сарман буйларында тирәктә.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем
Үрелеп чәчәк ата йөрәктә...»

Бер елады,
Бер елмайды Җамал.
Күңеле китте җырга ияреп.
Бергә барды, гүя Хәмитҗаны,
Изүләрен чишеп җибәреп,
Җилгә каршы гармун тартып барды...

Бер көенде, бер сөенде Җамал
Таңда күргән шушы төше өчен.
Гомер буе күңел сагына шул,
Юксына шул якын кешесен.

Яшәтә ул аны юлдаш итеп,
Сердәш итеп йөрәк түрендә.
Кешеләрне кеше күңеленнән
Алып китә алмый гүр генә.
Яши кешеләр
Яшел яфрак булып,
Алкын чишмә булып, ургылып.
Озата бара алар гомерләрне
Күңелдәге тынмас моң булып.

Безнең йолдызлар

(Тәзүче монологы)

Утыр, дускай, ашыкмый тор,
Бер утыру бер гомер.
Учакта да дөрләп китте
Әнә бит тере күмер.
Янсын учак,
Караиделгә
Төшсен алсу яктысы.
Күктә йолдыз,
Җирдә йолдыз —
Безнекеләр кайсысы?
Суда йолдыз,
Тауда йолдыз —
Балкый Уфа утлары.
Безгә сирәк тиде, дускай,
Мондый ял минутлары.
Хәтерендәме, итәк белән
Балык сөзгән балачак?
Ачына да, тугына да
Чыдап түзгән балачак.
Күнелләргә ямау салып
Үтеп киткән балачак.
Әрнү дә ул, бәллү дә ул,
Бүгенгедән карасак.
Сугыш заманнары өзде
Безнең күпме хыялны.
...Җәйге кичләр, татлы хисләр...
Яшел печән. Өй алды.
Аяз күктә, бик биектә
Җемелдәгән йолдызлар.
Сөйләшәбез, аңда, дибез,
Безнең дә бит йолдыз бар.
«Уфа кайда, Уфа кайда?

Уфа биек тауларда...»
Шушы җырга ияра-ияра
Киттек әллә кайларга.
Кайларгамы?
Бик тиз генә
Тауга менеп буламы?
Исендәдер Нижгородның
Салкын, кысан чоланы.
Без — калалар.
Тагын җырлар:
«Нижгородны су баса.
Уфаны да басар иде,
Тау өстендә булмаса...»
Тау өстендә... Уфа шунда.
Безнең йолдыз шул иде.
Ярык көймә, зәңгәр җәймә —
Эшкә йөрер юл иде.
Көймә кала. Алда — кала.
Без үрлибез югары...
Өй хуҗасы апа әйтә:
«Прописка югәле...»
Без — төзүче.
Җырлый-җырлый
Көн дә балчык изәбез.
Без бит кала төзүчеләр,
Ныклы булсын измәбез.
Уба күчә. Уфа үсә —
Күтәрелә яңа йорт.
Дядя Ваня көйли-чөйли:
«Кирпечеңне болай тот...»
Югарыда йолдызлы тау,
Нижгородның юлы тар.
Апа әйтә: «Чолан салкын,
Идәндә дә урын бар».
Менә бәхет: өйгә күчтек,

Прописка инде бар.
Идән булсын, түбә күктә:
Без законный калалар.
Получка көн. Гармун алдык.
Икебезгә бер гармун.
Нижгородның урамында
Үзебезнең тәүге моң.
Нечкә билле, җитен чәчле,
Зәңгәр күзле Наташа
Безнең якка сикереп чыга
Бакча яклап, койма аша.
Таңга кадәр утырганнар
Шул гармунны сайратып,
Исеңдәме, кайткан идек
Авыз-борын канатып.
Озын Нәби: «Дировня», — дип
Ялт бер синең чигәгә.
«Дировнямы?» — тегенең мин
Менеп төштем җилкәгә.
Ул сызгырды — «тар балаклар»
Әллә күктән төштеләр.
Синең белән мине ул кич
Пештеләр тек пештеләр.
Калаларның уты-суы
Шуннан башланды микән,
Үзебез салган олы йортның
Нигез ташлары микән,
Кәбестәсе әчи биргән
Кала ашлары микән,
Җитен чәчле, зәңгәр күзле
Каракашлары микән
Кала егетләре итте
Безне, авыл малаен.
Күпме йортка нигез салдык,
Үзебез яптык калаен.

— Ну, егетләр, Нижгородны
Калдырырга да вакыт. —
Дядя Ваня шулай диде,
Безнең аркадан кагып. —
Гомум торак менә әзер.
— Иртәгәдән күчәбез.
Хуш, Нижгород, Озын Нәби!
Үсәбез тек үсәбез!..
Туйлар булды. Еллар узды.
Әти дә булып киттек.
Узсын еллар — без Уфага
Күпме йорт бүләк иттек.
Өй туйлыйбыз — менә бит әй,
Якты безнең бүлмәбез.
— Әйдүк, әйдүк, авылдашлар!
Гаеп итә күрмәгез.
— Түкмә, әнкәй, яшьләреңне,
Яшь түгәр заманмыни...
— Шатлыктан ул, балакаем,
Яшьне тыяламмыни?
Әтиегез күрсә иде
Шушы җәннәт дөньяны:
Нинди йортлар салып кергән
Колынчагы, оланы.
Кайталмады, явыз Гитлер
Упты шул газиз башын...
Наташа йөри өлтерәп:
— Капкалап утыр ашын...
— Күтәр, дускай, бокалыңны,
Җемелдәсен йолдызлар.
Чыннан да бит, бу дөньяда
Үзебезнең йолдыз бар:
Әнә ничек җемелдәшә
Тауда Уфа утлары —
Бу бит аның үзебез салган

Чибәр-чибәр йортлары.
Караиделкәй җырлап аксын:
«Тарт әле бер гармуның.
Сөйлә, әйдә, йөрәкләрнең
Бар шатлыгын, бар моңын».

ЭЧТӘЛЕК

Шагыйрь-йөрәк сайрамаса

Бер минут . . . 7
Яшәү кадере . . . 8
Ак сөлге . . . 9
Кадерен беләсеңме? . . . 10
Тормыш арбасы . . . 11
«Өлгерермен әле таратырга...» . . . 12
Өмет . . . 13
Әнием фәрештәсе . . . 13
«Яхшылыкны әгәр эзләсәң...» . . . 15
«Стаканда гына су кайнаттым...» . . . 16
«Чыккан чакта ябып ишекне...» . . . 16
Түгәрәклимен дип . . . 17
Бер язмышлы . . . 18
Иртә әле . . . 19
«Бәйләп кенә элгән асыл шәлнең...» . . . 20
Борчымагыз . . . 20
Гомер гөлләмәсе . . . 21
Төн . . . 22
Сабырлык . . . 23
Җыр чакыра . . . 24
«Фани дөньяларданиләр генә...» . . . 25
Самавыр . . . 26
Гомерем, күңелем . . . 27
Шагыйрь-йөрәк сайрамаса . . . 28

Күңел моңым булыр җирем моңы

Минем йолдыз . . . 29
Җырым туды . . . 30
Кайтам, китәм . . . 30
Дөнья юлында . . . 31
Ана күңеле . . . 32
Син әйтәсең . . . 33
Дәвам итә . . . 33
Тояк тавышы . . . 34
Карбыз һәм дус . . . 35
Табигатем шундый . . . 36
Яңа кала коям . . . 37
Тел ачкычы . . . 39
Дәвамым . . . 40

Кар яктысы 40
Тәрәз уйдым, ишек куйдым 41
Серле сандык 42
Тукайга 44
Гаҗәпсенмә 45
Ярый әле 45
Бала 46
«Бүген иртән баксам тәрәз аша...» 47
«Нигә әле болай елларымны...» 47
Озатмадык 48
«Иңемә әнием камзулын...» 49
Йөрәк 50

Тере чишмә булып бар, балам

Чишмәле тау 52
Кечкенә сыерчык оясы 54
Онытгылар, ахры 55
Таң каламын 56
Диңгез көче 56
Үз мизгеле 57
Кар сулары китә 58
Яшьлек төсе 59
Яз башы 60
Кар бөртеге хакында уйлану 61
Күз балкуы 62
Тынлык 63
Туган ягым 63
Акыллырак мәллә 65
Кояш кошы 66
Соңгы яшеллекнең авазы 66
Әби. Кәҗә. Ташлытау. 67

Утлы еллар үтә йөрәк аша

Умырзая белән сөйләшү 70
Сөйлә, әнкәй, әткәй хакында 71
Илдә ир-ат бар 72
Таллар тып-тын 73
Икмәк 74
Хәтерләтә 75
Әниемнең гадәте 76
Төнге авазлар 78
Таштагы чәчкәләр 79

Дулкыннар сөйли 80
1. Олы ярлар буйлап 82
2. «Улым, бүген Волга ни төстә?..» 84
3. Бәвелчәк бәвелгән бакчада 86
4. Исемнәр 87
5. Юлдаштыр гомергә 89

Яндыр якты шәмнәреңне

Сөю сүзе 90
Тик күр генә 91
Нур 92
Ярата — көтә 93
Юлда 95
Нишләтим соң сине 96
Мәхәббәт диалогы 97
Яндыр якты шәмнәреңне 98
Матурлык 99
Телендә кем булыр 99
Асыл затлар 100
Бары сөю дәва 101
Табышу 102
Ялгыз булма 103
Син калдырган бозлар 104
Миләшем 104
Килдең көзге урманыма 105
Канатым 107
Туй көнендә 107
Аларга бит кучкән 109
Гашыйклар дәфтәреннән 110

Аума, аума, туп-туры тор

Бик яшь әле 112
Бишминутлык 113
Бүреклеләр һәм яулыклылар 114
Нокта 116
Белгеч «тәҗрибәсе» 117
Түрә «эш күрә» 118
Шәләй-вәләй 119
Шөреп 119
Бакчада 121
«Үсте» кызлар 121
Шәп булгач ни 122

Автобус 123
Гата, диләр 124
Лифт ябылган арада 125
Улының «хезмәтләре» 125
Гөлнәркәз үтә урамнан 126
Кемнәр боза? 128
Җәннәт йорт 129
Энә — җеп 130
Ике «тиеш» 130
Шул кирәк 132
Төпчек кызга өйләнәм 134
Аума, аума 136
Кыям микән? 136
Әл дә син бар әле 137

Чалгылар чажлыйлар чаж да чож

Утлар *(поэма)* 139
Аксылу *(баллада)* 150
Каен суы *(поэма)* 162
Онытмагыз безне, тереләр... *(поэма)* 177
Безнең йолдызлар *(Төзүче монологы)* 184

Литературно-художественное издание

ШАММАСОВ Равиль Сахиуллович
(Равиль Шаммас)
ОГОНЬКИ ЖИЗНИ МОЕЙ
(на татарском языке)

Редакция мөдире *Сабир Шәрипов*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Бизәүче мөхәррир *Фазлетдин Ислахов*
Техник мөхәррире *Надия Пятаева*
Корректоры *Зилә Адыева*

Лицензия № 0168, 10.04.96. Җыярга бирелде, 14.07.98. Басарга кул куелды 23.02.99. Кәгазь форматы 70x90 /$_{32}$. Офсет кәгазе № 1. Прагматик гарнитурасы. Калку ысул белән басылды. Шартлы басма таб. 7,02. Шартлы буяу отт. 7,31. Исәп-нәшер таб. 7,99. Тиражы 2000 данә. Заказ № 86.

Башкортстан «Китап» нәшрияты. 450001,
Уфа, Левченко урамы, 4а.
Уфа полиграфия комбинаты. 450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.

ПРОВЕРЕНО
07 СЕН 2016
Подпись